
1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 АПРЕЛЬ № 4

Сөембикә

АЛДАНМАГЫЗ!
мошенниклар тозак кора

ИР АЛЫШТЫК...
аның хатыны – иремнең сөяркәсе

АЙГӨЛ ХӘЙРИ СЫЙЛЫЙ
каражиләк десерты

Әсәл ХӘМИТОВА:

«МАРСКА ДА ОЧАР ИДЕМ!»





70

1945–2015

Сугыш язган хатлар

Әти сугышка киткәндә ике яшь ярымлык кына булганмын, аны, билгеле, хәтерләмим. Сугышка кадәр ул агроном булып эшләгән, әни белән йорт салып башка чыкканнар. Өч абыемнан соң көттереп кенә мин туганмын. «Алка тагарга кызым булды, үскәч, мин аны тегүче итәм», — дип әти бик шатланган. Безне укытырга дип хыялланган... Әти китүгә әни фермада эшли башлаган. Кырдан салам ташыганда, аякларының чабатага бозланып катуы бүгенгедәй күз алдымда. Ничекләр түзгәндер?! 1944 елның март аенда әтиебез һәлак була. Украинада, Хмельницкий янында җирләнә. Гомер буе әтиле кешеләргә кызыгып яшәдем. Үзем генә булганда: «Әти», — дип кычкырып әйтеп карый идем...

Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торучы хаJәлегез Садридан хаJәлем Гөлзагыйфага бик сагынычлы сәламнәремне теләп калам вә һәм Заһертдин белән Фәхертдин углыма бик сагынып бик күп сәлам вә һәм Равил белән Рәшидә кызыма бик сагынып бик күп сәламнәр. Үзем мин сау-сәламәт, сезне дә сау-сәламәт дип беләм. Хатыгызны алдым, һәр ни язган мәгълүм булды. Бик яхшы язган.

Нихәл торасыз, танагыз бозауладымы, сөте булдымы? Сарыкларыгыз исәнме? Казларыгыз бармы? Акбай исәнме? Барсын да языгыз. Утыныгыз бармы? Ашарыгызга җитәрлекме? Хезмәт көне эшләп буламы? Заһертдин эшлиме?

Бу хатны яздым, авыр булса да, Заһертдин укырлык булсын дип, ул укырлык итеп. Дөрес язган булсам тагын язармын, Заһертдин, әйтеп яз. Балаларымны кайтып күрсәм иде, бик сагынам. Рәшидә сүләшә торгандыр инде. Рәшидә белән Равилны бик сагынам. Елап йөри торганнардыр. Гөлзагыйфа, авыр булса да түз. Монда синең шикелле солдаткалар, берләре хезмәттә, өйләрен немец ягып киткән, биш-алты бала белән калган, аларга да бик читен. Гыйбрәтләр бик күп. Алла шулай язгандыр.

Бакчага бәрәңгегез бармы? Кырга утырта алмассыз инде? Утыртсагыз яхшы булыр, ач булмассыз. Заданиягә бәрәңге түләдеңме? Бакча киртәсе бик начардыр инде, өйгә яңгыр үтә торгандыр, түбәсе юка ябылды. Акча аласыңмы? Зыя һәм Салихларның хаты киләме? Сафа абыйның хаты киләме? Аның адресын җибәрегез. Сахип һәм Нуретдиннең хаты киләме? Килер айда кемнәр китте? Кайтучылар бармы? Ранный булучылар бармы? Насыйбулла Касыймы белән Заһидулла өйдәме? Мирзаның хаты киләме? Хикмәтулланың үлгәнен ишеткәч, җыладым, безгә дә шул булачак, бүген булмаса, иртәгә.

Сау булыгыз. Хатыгызны күп языгыз. Авыл хәбәрләрен языгыз. Адрес шул искечә. Хатыгызны атна саен языгыз. Хат алгач күңелле була. Якынтирәләр бер дә юк янымда. Күбесе калдылар. Һаман немец чигә, без алга барабыз. Бергә алынган иптәшләр берсе дә юк, хәзер мин генә калып торам. Яңа Арыш Ярмухамметов Хәсән сугышка кергән көнне үк юкка чыкты.

Бәлкем актык хатымдыр. Көн саен үлем көтәбез. Бик бәхетле кешеләр генә кайтыр инде. Сау булыгыз, бәхил булыгыз. Хәер-догагыздан ташламагыз.

Үзем Смоленский областьта. Бу хатны яздым 1 нче Май көнне. Ял итәбез.

Кара бөдрә чәчләреңне,
Шәлең белән каплама.
Юлларыңда чәчәк булса,
Мин булырмын – таптама.

(Садри Шакировның фронттан килгән хатлары Балык Бистәсе районының Бәтке авылында яшәүче кызы Рәшидә Хөсәеновада саклана. Хат кыскартылып, язылу стиле үзгәртелмичә бирелә.)

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сюювмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте





Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова



Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Әсәл ХӘМИТОВА
Фото: Газинур Хафизов

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академия урамы, 2

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 3.04.2015 ел.
Заказ О-837.
Тираж 7327

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сатуда бәясе иреккә.



Валентина Владимировна ТЕРЕШКОВА
1963 | 16–18 июнь | «Восток-6».
Беренче хатын-кыз космонавт
(туган елы: 1937, Ярославль өлкәсе, Масленниково авылы).
Пароле: «Чайка».



Светлана Евгеньевна САВИЦКАЯ
1982 | «Союз Т-5», «Союз Т-7», «Салют-7».
1984 | «Союз Т-12», «Салют-7».
Ачык Галәмгә чыккан беренче хатын-кыз космонавт
(туган елы: 1948, Мәскәү).
Пароле: «Памир-2».



Елена Владимировна КОНДАКОВА
1994–1995 | «Союз ТМ-20», «Мир».
1997 | «Space Shuttle Atlantis», «Мир».
Галәмдә озак вакыт очып йөргән беренче хатын-кыз космонавт
(туган елы: 1957, Мәскәү өлкәсе, Мытищи шәһәре).
Пароле: «Витязь-2».



Елена Олеговна СЕРОВА
2014–2015 | «Союз ТМА-14М», «МКС».
Халыкара космик станциядә Россия ягыннан очкан беренче хатын-кыз космонавт
(туган елы: 1976, Приморье крае, Уссури округы, Воздвиженка авылы).
Пароле: «Тархан-3».

ХАТЫН-КЫЗЛАР ГАЛӘМДӘ

Ирләр белән хатын-кызларның тигез хокуклылыгы идеясе Җир шарында ныклап тамыр җәйде. Җирдән аерылгач, бу тигезлектән нәрсә кала икән?

Валентина Терешкова Галәмгә очкач, Баш конструктор Сергей Королев, имеш, болай дигән ди: «Җитте! Хатын-кыз Галәмгә беренче һәм соңгы тапкыр оча. Стартта хатын-кызлар башка күренеп йөрмәсен!» Ә Терешкова Җиргә исән-имин әйләнеп кайткач, үзе үк «Акчарлак»ны ир-ат космонавтларга үрнәк итеп куя.

Шулай да, ниндирәк соң алар – хатын-кыз космонавтлар?



Ануше АНСАРИ
2006 | «Союз ТМА-10», «МКС», «Союз ТМА-9»,
турист сыйфатында Галәмгә очкан бердәнбер хатын-кыз
(туган елы: 1966, Иран, Мешхед).
Хәзерге вакытта АКШта яши.



ир-ат космонавтларның саны
хатын-кыз космонавтларның саны

Кызык, ләкин факт: Бөекбритания белән Кореяда ир-атларның Галәмгә менеп җитә алганнары юк әле. Ә менә хатын-кызлар очты инде.

Инфографика: asafin

iCC





Статистика буенча,, галәмнең җенес органнарына тискәре йогынты ясавы күзәтелә. Хатын-кыз космонавтлар бу проблемалар белән ешрак интегә.

Организмның күкәй күзәнәкләре һәм сперма эшләп чыгару функциясе киму сәбәпле, киләчәктә баласыз калу куркынычы булмасын өчен, галәмгә очучыларның сперма һәм күкәй күзәнәкләрен туңдырып саклауны кагыйдә итеп алырга уйлыйлар.

Баш мөхәррир сүзе

Фантастика... Хыял һәм акыл. Илһам һәм максат. Әдәбият һәм фән. Шулар кушыла да, әкият чынбарлыкка әверелә. Айзек Азимов, Иван Ефремов, Рэй Брэдбери, Герберт Уэллс, Адлер Тимергалин, Стругацкийлар фантазиясе тудырган китаплар мине Андромеда томанлыкларына, Кешелекнең киләчәгенә алып китә иде. Ерак-ерак, буй җитмәслек киләчәккә. Ә ул менә килеп тә җиткән. Табигатебезне камилләштерүгә алынган генетика уңышлары белән беркемне дә шаккаттырып булмый, көнкүрешебезне үзгәрткән технологияләр белән дә – скайптан инде күптән әбиләр оныклары белән аралаша (әңгәмәдәшеңне экранда күреп сөйләшү дә без карап үскән футуристик фильмнар атрибуты иде бит!). Кичә генә могҗиза дип атарлык ачышлар иртәгәсе гадәти бер күренешкә әйләнә дә куя. Өй кадәр өйне бүген принтердан чыгарып була. Һәм шундый өйләрне инде Марста корырга җыеналар!



Без «Марста тормыш бармы икән?» дип сорау куйдык, ә безнең балалар инде Марска күченеп китәргәме-юкмы дип уйлана. Бер буын дәверендә, ярты гасыр эчендә фантастика чынбарлыкка әйләнер дип кем ышанган? Ышанучылар булган шул. Хыялга канат куючылар, шашкын идеяне тормышка ашырыр өчен нидер эшләүчеләр булган. «Мөмкин түгел!» дип тормаганнар. «Сказка странствий» фильмын караганыгыз булдымы икән балачагыгызда? Андрей Мироновның сокландыргыч герое анда галактикалар түгел, ә чума чире баскан илне җәяү гизеп йөри һәм... кешене җирдән күтәрердәй канатлар ясау турында хыяллана... Тетрәндергеч һәм тәэсирлән-дергеч әкият иде ул! Әбугалисина, Джордано Бруно, Галилей, Леонардо да Винчилар (ул да бит, үз заманын алга этәргән талантлы инженер буларак, канат ясау идеясе белән алгысыган) йолдызларга карап сала башлаган юл безгә бүген ачык!

Әйе, без искиткеч заманда яшибез – мөмкинлекләр заманында. Белем эстәү өчен дә, иҗат өчен дә, сәяхәт өчен дә чикләр юк. Ышанып та бетеп булмый һаман: яше-карты – барысы да галәмгә оча ала! (Монысы да акчага терәлә, әлбәттә – космик туризм әлегә бик кыйммәтле сәяхәт. Әмма – мөмкин бит ул!) Әнә, 180 алтын һәм платина бүләк иясе булган 55 яшьлек британ җырчысы Сара Брайтман да космоска җыена икән. Ул инде, теләге чынга ашса, Галәмдә гизгән икенче хатын-кыз турист булачак.

Марста колония төзүне максат итеп куйган Mars One проектында катнашырга дөньяның төрле почмакларыннан 200 меңнән артык кеше теләк белдергән (ә сүз бит Җирне бөтенләйгә ташлап китү турында бара!). Сайлау барышында калган илле кешенең иң яшенә – 19, иң өлкәненә 60 яшь. Кандидатлар арасында табиб та бар, программист та, балет биючесе дә, космос белән шашкан хыялый кызлар да – алар арасында безнекеләр дә бар («Кызыл планета»га күченергә теләүче биш россиянның дүртесе – кызлар, шуларның берсе Чаллыда туган). Ахыр чиктә Марста тормыш башлап җибәрү өчен дүрт кенә астронавт сайланачак: психик һәм физик яктан иң чыдамнары. Кемдер кызыга, кемдер гаепли: мондый проектларга акча сарыф итәр вакытмыни, үз өебездә тәртип юк әле ди...

Әйе, Кешелек әле, фантастлар хыялланганча, акыл үсешенең иң югары ноктасына җитеп, сугышлардан, вәхшилектән арынган гармонияле камил дөнья төзеп өлгермәгән. Җир шарында проблемалар әле бихисап. Аларны, әлбәттә, хәл итәсе иде. Илебез белән горурланыр өчен дә, Юрий Гагарин исеменнән тыш, башка мактаныр исемнәр, ватанпәрвәрлек уята торган башка гамәлләребез дә күп булсын иде. Алынсак, башкаларны уздырып булдырабыз бит!

«Фантастика!» диярлек идеяләрне тудыручы алга, якты киләчәккә омтылыш кына сүрелмәсен! Каләм ияләрендә «Әкият!» дигән хыялларны ният итәрдәй канатландыру сәләте, ә галимнәребездә «Булмас!» дигәнне чынга ашыру дәрте сүнмәсен! Ә балаларыбыз... яшьләребез галәм иңләрдәй мөмкинлекләрен, Марсны буйсындырырлык дәрт-егәрләрен башта үз планетабызда, Ватаныбызда, Татарстаныбызда куллансын иде. Фантастик фильмнарның барысында да иң гүзәл планетабызны – Җирне, туган якны сагыналар бит. Сагынырлык, сокланырлык, яратырлык, ерак галактикалардан да җирсеп кайтырлык булсын ул – шул хыялны да тормышка ашырыйк әле. Иң мөһиме: теләк булсын, ә мөмкинлекләр бар!

Әдәбият елы барыбызга да кыенлыклардан югарырак күтәрелерлек – илһам, ә Космонавтика көне исә куйган максатларыбызга ирешүгә старт бирсен! Беренче космонавтыбыз әйтмешли, «Поехали!»

Ләйсән ЮНЫСОВА



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





16

АКЫЛЛЫМ ӘСӘЛ
Ф. Мостафина

НӘСЕЛ КАЙТАВАЗЫ
Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ







8

АДЫМ САЕН ТОЗАК...
М. Авзалова

22

Гүзәл Нигъмәтуллина:
КИТАП ДӘВЕРЕ УЗМАС

12



БЕРЕНЧЕЛӘР
Г. Сафиуллина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24

ГОМЕР ТУЙЛАРЫ

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



40

КИЛЕННӘР
Ф. Җамалетдинова

ЯШӘЕШ 

46



НӘФРӘТТӘН МӘХӘББӘТКӘ... МАРАФОН
Г. Зыятдинова



52

ХЫЯНӘТ КАВЫШТЫРДЫ
М. Кашапова

ШУЛАЙ УК: 

СӘРСӘН МАҺИНУР
К. Булатова


28

ПАРТИЗАН КЫЗ ЧӘЧКӘ
Ч. Заһирова

32

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

62



КӨЗГЕМ – ӨЕМ БИЗӘГЕ

ҺӘР САНЫБЫЗДА: 

БЕЗНЕҢ ПОЧТА 6

ДӨНЬЯ ГАМЕ 15

ШИГЪРИЯТ 38

БЕР ҖЫР ТАРИХЫ 44

РӘССАМ СӘХИФӘСЕ 64





Гомер – кешегә бер генә тапкыр бирелә торган иң кадерле мизгел ул. Ниятем – бер кеше гомере, бүгенге көндә Башкортстан Республикасының Салават районы Лаклы авылында яшәүче 80 яшьлек әнием Ләмига Минислам кызы Фәрхетдинова турында сөйләү.

Аның нәсел төбе Татарстанның Саба районы Көек авылына барып тоташа. Әтисе Минислам кибетләр тоткан, атлар асраган хәлле нәсел баласы була. Ярдәмчел бу гаиләгә авылдашларының йомышы гел төшеп торган. Берәүне дә кире бормаган алар. Тик колхозлар оеша башлагач, хәлле кешеләрне кулак дип, читкә сөрүләр китә. Әниемнең ишле нәселе дә пыран-заран килә. Туганнарның бер өлеше Төмән якларына, бер өлеше Башкортстанга юл тота. Караңгы төнне авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булган Минислам бабам гаиләсе белән Салават районы Шәрәк авылына килеп төпләнә. Әнием белән Сөләйман абый инде монда дөньяга килгән. Әмма Минислам бабай балаларының үскәнен күрә алмый, бик тиздән дөнья куя. Өч бала белән тол калган әбием яңадан кияүгә чыга. Иш янына куш булып, уртак балалары туа. Әмма бу ире дә вафат була. Әбием дүрт баласын ялгызы гына үстерә. Ана янында бала ятим булмый. Тырышлыгы, үҗәтлеге сынмаска көч бирә аңа. Тик сынаулар аның сәламәтлеген бик нык какшата. 54 яшендә ашказаны авыртып, мәңгелеккә күзләрен йома ул. Әнием үзе дә 18 яшендә үк гаиләле була. Әмма ирдән кагылып-сугылып яшәүне горурлыгы күтәрми, кызы Гөлнәзирә апаны алып, иреннән китә. Ун еллап ялгыз яшәгәч, әниемне булачак әтием кияүгә сорап килә. Аннан соң сеңлем белән без икәү дөньяга килгәнбез. Тик без әле сабый чакта ук әтиебез вафат була. Әни безне – өч кызын ялгызы үстерә. Таңнан торып, сыер саварга киткән савымчының тормышы һәркемгә дә мәгълүм. Өстәвенә, әллә никадәр чөгендер бүлеп бирәләр. Нәни кулларыбыз белән басуда чүп утаулар, көзен чөгендер йолку, арбага төяүләр мәңге онытылмаслык булып күңелгә сеңеп калган. Ул безне, без аны жәлләп, тормыш арбасын бергә сөйрәдек. Өебез иске, кыйшайган. Әтиле балалар бездән көләләр иде. И күңел рәнҗи иде шунда. Өй салу нияте белән бераз акча җыйгач, Лаклы авылыннан бер йорт сатып аласы иттек. Әниебез бик яхшы кешене – үги әтине очратты. Әтисезлектән зар булгангадыр инде, без аны шулкадәр үз иттек. Өйне дә салырга, безне дә үстерергә ярдәм итте ул. Тик бер булмаган бәхетне тапсаң, чите кителергә генә тора. Үги әтиебез дә яман шеш авыруыннан үлеп китте. Әниебез тагын ялгызлыгын кочаклап калды. Гомер йомгагын үрә-сүтә, язмыш сынауларын үз йөрәге аша кичереп яшәгән әниебез безгә гел әйтә килде:

– Минем кебек катлы-катлы күлмәк кимәгез. Бергә чыккансыз, бер белән гомер итегез.

Булсын, балаларым югары белем алсын, булышыйм, дип, әниебез умартасын да булдырды, малын да асрады. Әле шушы яшенә җиткәнче каз тотты. Бакчасында яшелчәсен үстерә. Үзе ашамый, безнең өчен дип тырыша. Үз үрнәгендә тәрбияләп, безне дә көчле рухлы, үҗәт холыклы итеп үстерде. Югары белем дә алдык, тормышта үз урыныбызны таптык. Бүгенге көндә гаиләбез, яраткан эшебез, ана телебездә сөйләшә ала торган дәвамчыларыбыз бар икән, болар бар да әнинең безгә биргән тәрбия нәтиҗәсе.

Кадерле әниебез! Гомереӊ буена яратып укыган журнал битләре аша сиңа котлау юллыйбыз. Тән сихәтлеге, җан тынычлыгы телибез сиңа. Без гел синең янәшәңдә булырбыз.

Флүрә КОЛАХМӘТОВА-ТАЛИПОВА.
Чаллы.

Әлки районы Базарлы Матакта мәдрәсә төзи башлавыбызга быел биш ел булды. Аллага шөкер, инде бинаның эчке эшләре генә калып бара.

Мондый уку йортының кирәклеген аңлаган, Аллаһның барлыгына ышанган кешеләрнең Ходай ризалыгы өчен дип биргән сәдака акчаларына төзелде мәдрәсә. Әмма эчке эшләр өчен дә материаллар бик күп кирәк әле. Хәзергә газ кертү проектларын ясатабыз. Аларны төгәлләгәч, бүлмәләрне җиһазлыйсы кала.

Мәдрәсәбезне бик матур, бик уңайлы итәсебез килә. Подвал катының бер ягында ашау-эчү бүлмәсе, икенче ягында спорт залы булачак. Өске катларда уку залы, китапханә һәм тәһарәт алу урыннары урнашачак.

Мәдрәсә төзелешен башлаганда бездән: «Табыш кертмәгәч, бу сезгә ни өчен кирәк? Бу эшләрне башкару өчен акча каян аласыз?» – дип сораучылар да булды. Ул бит Аллаһ ризалыгы өчен, бөтен халык ярдәме белән төзелә. Мәдрәсә эшләп торганда, ярдәм итүче кешеләргә әҗер-саваплар өстәләр.

Кайбер кешеләр, мәчеттә дә укырга була бит, аның өчен генә мәдрәсә төзү кирәкме, диләр. Мәчет ул – Аллаһ йорты, анда кергәч, бөтен кагыйдәләрне үтәргә кирәк. Укырга килгән балаларның төрлесе була, алар шукланырга да мөмкиннәр, тавышланырга да. Ә мәчеттә тәртип бозарга ярамый. Шуның өчен дә белем алуны мәдрәсәдә оештыру яхшырак. Мәдрәсәдә хәрефләр генә өйрәтелми, анда әдәп-әхлакка да өйрәтәләр.Җәйге каникуллар вакытында балаларны да җыеп укытырбыз. Төрле фәннәрдән белемнәр бирербез.

Хәзерге заман баласына әхлак тәрбиясе бик кирәк. «Иң яраткан әйбереңнәрсә?» – дип сорасалар, аларның күбесе: «Компьютер!» – дип җавап бирә. Ә бит беренче урында Аллаһы Тәгалә, аннан соң әти белән әни торырга тиеш. Күпләр моны белми дә. Мәдрәсәдә балаларны беркем дә начарлыкка өйрәтмәс. Алар аракы белән тәмәкенең, наркотикларның нәрсә икәнен дә белмәсләр, әти-әниләренә, олыларга хөрмәт белән карарга, дөньяны, кешеләрне яратырга өйрәнерләр.

Мәдрәсә башкара торган барлык эшләр дә Татарстан Республикасының Диния нәзарәте рөхсәте белән генә эшләнә. Укытучылар да эшкә алар рөхсәте белән генә алына. Уку, ашау-эчү бушлай булачак. Киләчәктә экскурсияләр, спорт ярышлары да оештырылачак. Ерак авыллардан килеп укучылар өчен торыр урыннар да каралган. Бу эшләрне башкарып чыгарга безгә Аллаһы Тәгалә ярдәм итә, чөнки ниятебез – яхшылыкта.

Мәдрәсәдә укып алынган белем – бу дөньяда да, ахирәттә дә кирәкле белем. Мәдрәсәбезне бергәләшеп төзеп бетереп, файдасын күрергә язсын иде, дин кардәшләрем. Ярдәм кулы сузарга теләүчеләр булса, телефон номерымны редакциядә калдырам.

Фаик БОРҺАНОВ.
Әлки районы, Базарлы Матак.

Мин 1936 елны Аксубай районы Иске Татар Кармәте авылында туганмын.

Бөек Ватан сугышы башланганда без Молотов өлкәсенең Губаха шәһәрендә яши идек. Әти заводта штамплаучы булып эшләде. 1941 елның 28 июнендә әтиебезне сугышка алдылар. Шул китүдән күрешүләр насыйп булмады. Сугыштан бер генә хаты килде аның. Ул хатта болай дип язылган иде: «...бик каты яңгыр ява, күрешә алмасак, исән-сау яшәгез, балаларны авылга алып кайт.» Губахадан авылга кайтканда юлда дүртенче туганыбыз дөньяга аваз салды. Шулай итеп, әниебез 29 яшендә дүрт бала белән тол калды. Ул инде яңадан тормыш кормады, бар көчен безгә һәм колхозга багышлады. Бүгенге көндә без дүртебез дә исән-сау, арабызда әниебез генә юк – 90 яше тулган көннәрендә гүр иясе булды.

Безгә әтисез үсүләре, яшәүләре авыр булды дисәм, беркем дә гаҗәпләнмәс. Балачакны белмичә, мең җәфа чигеп үстек. Әниебез кыш көннәрендә иртәдән кичкә кадәр – урман кисүдә, җәйләрен кырда булды. Без – иң олыбызга сигез, иң кечебезгә бер яшь булган балалар – үзебезне үзебез карадык. Мәктәпкә укырга кергәч, безне дә колхоз эшенә куша башладылар. Әни белән кырда бәрәңге утыртабыз, яшелчә бакчасында эшлибез, чүп утарга йөрибез. Печән өсте җиткәч, әниләр чалгы белән печән чаба, без печәнне әйләндерәбез, киптерәбез, чүмәләгә куябыз. Болар барысы да бушка эшләнә, хезмәтебез өчен бер тиен дә түләмиләр иде бит. Җитмәсә, барыбыз да ач. Ачтан үлмәс өчен кырда калган башак бөртекләрен җыя торган идек. Әле анысын да җыярга ярамый, атка атланган абыйлар күрсә, безне куып тотып, шул җыйган бөртекләребезне талап алып кала торган иделәр. Кырдан гына түгел, урманнан да җиләк, чикләвек җыярга ярамады. Урманчы күрсә, беттең! Өйдәге бар авыр эш – көрәк белән бакча казу, бәрәңге утырту, кул арбасы белән урманнан корыган ботак ташу, печән ташу, олы балалар буларак, абый белән миңа төшә торган иде. Җан көчләребез белән тырышып, кыш чыгарлык утын, печән әзерләдек. Безнең өчен елына ике көн бәйрәм булыр иде. Шуның берсе – Ураза гаете. Бу көнне әни коймак пешерә торган иде. Икенче зур бәйрәм – Сабантуй. Сабан туен карар өчен район үзәгенә сигез чакрым җәяү бара торган идек. Әни биргән акчага тәмле су эчәбез. Көне буе йөреп, тәмам йончып, көч-хәл өйгә кайтып егылыр идек. Юл читендә хәл алып утырганда әтиле балалар, ат чаптырып, безне тузанга күмеп китә торган иде. Ә без – әтисез ятимнәр – балачак, яшүсмер чак бәхетләреннән мәхрүм үстек. Әнинең тырышлыгы, үзебезнең үҗәтлек белән белемле булдык. Безнең авылда мәктәп җидееллык кына иде. Урта белем алу өчен бездән егерме чакрымдагы авылга йөреп укыдык.

Мәктәпне «бишле»гә тәмамлап, медицина институтына укырга кердем. Көндез укып, төнлә эшләп, йокы хисабына табибә булдым. Укыганда ук кияүгә чыгып, диплом алганда мин инде ике бала анасы идем. 46 ел халкыма хезмәт иттем, «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булдым. Балачакта күргән авырлыклардан исәнлекләр генә бетеп бара менә. Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылаган көннәрдә дәүләт башында утыручыларга бер үтенечем бар. Сугыш елларында балачак, яшьлек рәхәтлекләреннән мәхрүм булганнарга «Сугыш чоры баласы» статусы биреп, безне дә «Тыл ветераны»на тиңләсәгез иде. Бөек Җиңүгә безнең дә көчебез керде ләбаса.

Замирә ГЫЙЛАҖЕВА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru



Фото: Газинур Хафизов



Мәдинә
АВЗАЛОВА

АДЫМ САЕН ТОЗАК...

Беркайчан да мошенниклар корбаны булганым юк дип әйтә алмыйм мин үземне. Акчаның тиенен-тиенгә санап торган студент елларында чегән хатынының бөтен стипендиямне алып калуын да, тиз генә, җиңел юл белән акча отам дип, ниндидер уенга кереп китеп, шактый күп акчамны шунда калдырып китүем дә, инде моңа дистә еллар узып китсә дә, һаман да бер искә төшеп, гарьләндереп куя. Җиңел акчага капканмын инде мин. Үзем гаепле.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының урлауларны ачу бүлеге җитәкчесе Илгиз Миннегаяз улы Габдрахманов белән кырыкалдарлар турында сөйләшә башлыйбыз да, янә шул чаклар искә төшеп, күңелне тырнап куя. Җитәкче сөйләгәннәрдән, ансат котылганмын икән әле ул чагында, дип, үземчә нәтиҗә дә ясыйм. Әнә ничек азу ярганнар, әнә ниләр кыландырып ята икән алар бүген! Әңгәмәдәшем аларны ике төркемгә бүлә: телефоннан «шаяртып» ятучы мошенниклар һәм социаль мошенниклар.

«Улың кеше таптатты...»

– Быелның гыйнвар аенда булган хәлне генә мисал итеп китерәм, – дип сөйли Илгиз Габдрахманов. – Кичләтеп, бик соң гына өйдә телефон шалтырый. Трубканы өлкән яшьтәге апа ала. Оныгы елый-елый бәхетсезлеккә юлыгуын, кеше таптатуын әйтә. Җинаять эше ачтырмас өчен 80 мең акча кирәк ди. «Хәзер килерләр, зинһар, биреп җибәр», – дип ялвара. Карчык, әлбәттә инде, бар булган акчасын теге кешеләргә чыгарып бирә. Ишектән чыкканда каршысына улы (оныгының әтисе) очрый. «Кая киттең?» – дигән соравына да җавап бирми бит ичмасам. Акчасын биреп кергәч кенә, оныгының хәлен сөйләп, хәйранга калдыра. Улы малаена бернәрсә дә булмавы, аның белән хәзер генә сөйләшүе хакында әйтә. Мошенникларның яраткан оныклары өчен җан бирмәктәге карт-карчыкларны алдауның киң таралган ысулы бу. Нигә шунда малайның үзенә шалтыратмаска, үзеннән аның хәлен сорамаска?! Күп вакыт та кирәкми бит моңа. Акчаны хокук саклау органнары хезмәткәрләренә биреп – ришвәтчелек кылып, якыннарын тиешле җәзадан алып калмакчылар, имеш. Үзе үк закон бозу ич инде бу... Күп андый хәлләр, бик күп. Кисәтеп, әйтеп торабыз, һаман шуны эшлиләр. Болары – телефон аша эш йөртүче җинаятьчеләр.

«Социаль мошенниклар»

Кырыкалдарларның бу төркеме бигрәк тә Җиңү көне алдыннан активлаша. Алар ветераннарның ишекләрен ачтыру, күңелләренә үтеп керү өчен төрле хәйләгә бара. Үзләрен йә социаль хезмәткәр, йә торак-коммуналь хуҗалыгы вәкиле, йә банк хезмәткәре дип таныштыра. Янәсе субсидия, кучтәнәч алып килгәннәр. «Банк хезмәткәре» булачак акча реформасы турында сөйләргә килдем, дип ялганлый. Халык ышана, «кучтәнәч китердем» дигән кешегә ничек ышанмыйсың инде? Җинаятьчеләр өлкән кешеләрнең беркатлылыгыннан бик оста файдалана: акча һәм орден-медальләрнең кайда ятканлыгын бик тиз ачыклый.

– Балалары, оныклары әтиәниләренә гел бу хакта сөйләпаңлатып торырга тиеш, – дип дәвам итә сүзен Илгиз Миннегаязович. – Мошенниклар ятьмәсенә эләккәч соң була. Мондый җинаятьләрнең күбесе ачылмый. Чөнки алданучы хокук саклау органнарына атна-ун көн үткәч кенә мөрәҗәгать итә. Ә бу вакытка инде караклардан җилләр искән була. Ник дисәң, аларның күбесе – «гастролер». Бүген ул – Казанда, иртәгә – Мәскәүдә. Газ службасы хезмәткәре дип йөрүчеләр дә еш очрый. Фатир хуҗасы икенче эш белән мәшгуль булган арада, мошенник күз алдында гына яткан алтын-көмешләрне ала да тая.

Соңгы вакытта ачылган җинаятьләрнең иң зурысы, шау-шу куптарганы – Йошкар-Олада яшәп, Казанның Мәскәү һәм Яңа Савин районнарын «дер» селкетеп торган «участок табибы». Кырыкалдар үзен корбаны белән шулай дип таныштыра торган була.

– Ул хатын унбер эпизод буенча гаепләнеп, дүрт елга ирегеннән мәхрүм ителде. – Җитәкче янә узган вакыйгаларга кайта. – Аның әбиләрне поликлиника ишеге төбендә каршы ала торган гадәте була: «Мин – участок табибы, әйдәгез, өегезгә кайтып сөйләшик. Экстрасенс сәләтем – нәселдән. Сезне бозганнар, алтыннарыгызны, акчаларыгызны бирегез, чистартыйм», – дип әйтә дә, тегеләре «байлыкны» кулына тоттыргач, аны кәгазьгә төрә. Һәм кинәттән генә моның су эчәсе килеп китә. Хуҗа кешене кухняга йөгерткән арада, төргәкне алыштырып куя. Аннары әйтә: «Өч көн мендәр астында ятсын, кагылмагыз», – ди. Өч көннән соң әбиең төргәкне алып караса, акча-алтын урынына кәгазь кисәкләре генә... Унбер кешене шулай итеп алдаган. Бармак эзләре буенча эзләп таптык без аны. Үзе күп балалы ана булып чыкты. Шундый юлга басуын: «Урлашырга ирем кушты, эшләмисең икән, урла диде», – дип аңлатты.

Балигъ булмаган яшьтәгеләргә карата җинаять кылган таҗик хатыны да тотыла. Мәктәптән кайтучы кызлар белән танышып, ул өйләренә кадәр озата кайта, фатирларына керә. Төрле сәбәпләр табып, кыйммәтле әйберләрнең кайда саклануын ачыклап, урлап кача. Йә: «Алтын әйберне тагып йөрергә куркыныч», – дип, аларның алкаларын салдырып, сумкаларына тыгарга булыша, ә үзе шул арада алтынны кесәсенә шудыра.

Кеше алдап көн күрүчеләр арасында чегәннәр бик күп. Быелның февраль айларында Казанда яшәүче сиксән яшьлек әбинең акчасын урлап тотылучылар да – чегән хатыннары. Аларның берсе аңа урын җир сатып алырга

> *Таныш булмаган кешеләр белән аралашу, аларга ышану кайчак зур бәхетсезлек-югалтулар белән тәмамлана. Интернет-кибет аша сатып алуларга игътибарлырак булсак икән.*

тәкъдим итә. Карчык хатынны фатирына кертә, аның каршында акча салынган тартмасын тартып чыгара. Һәм товарны карый башлый. Шулчак «сатучы» эчәргә су сорый, һәм әбиебез кухняга чыгып китүгә, акчаны ала да чыгып кача. Карчык югалып калмый. Шундук полициягә шалтырата. Һәм аларның икесе дә җинаять урынында тотыла.

– Бер белмәгән, күрмәгән кешегә ничек ышанырга була? – дип, тора-тора гаҗәпләнәбез. Илгиз Габдрахманов ул аферистларның кыланмышларын тикмәгә генә сөйләп утырмый. Алныартны карап йөрергә, сак булырга

кирәк безгә! Менә тагын ни еларга, ни көләргә белмәслек бер мисал: «Янә өлкән яшьтәге бер ханымга шалтыратып, оныгын җинаять җаваплылыгыннан коткарып калу өчен 100 мең акча таләп иткәннәр, – ди ачуы чыга башлап җитәкче. (Соңыннан белдек: мошенниклар Самара өлкәсеннән шалтыратканнар.)

Җиңү бәйрәме алдыннан сугыш ветераннары аеруча сак булырга тиеш. Чөнки кырыкалдарлар аларны алдауның бер генә төреннән дә чирканмый.

Шалтыратып берникадәр вакыт үткәннән соң, бу апага таксист хатын килә. Кемгәдер зур суммадагы акча тапшырырга кирәклеген белгәч, ул: «Мошенникларга юлыккансың», – дип акчаны алмый китә. Ә әби нишли дип уйлыйсыз?! Туганнарына шалтыратасы урында: «Сезнең кешегез акчаны алмады», – дип мошенникларга шалтырата. Җинаятьчеләр әби янына икенче кеше җибәрәләр. Әлбәттә инде, ул акчаны алуга ук юкка чыга. Берникадәр вакыттан соң тагын телефонга шалтырату килә: «Абонент номерына 30 мең сум акча салыгыз». Тагын чыгып китә терминал эзләп әбиебез. Терминал белән эш итә белмәгәч, янәшәсендә бөтерелгән бер яшь кенә хатынга мөрәҗәгать итә. Ә тегесе: «Монда терминал эшләми, икенчесенә салырмын», – дип, акчаны ала да, тиз генә эзен суыта».

Әйе, ярдәмчесез кешеләрне ешрак алдыйлар. Урамда барганда бер абзый янына ике яшь егет килә. Үзләрен Украина качаклары дип таныштыралар. «Фатир алырга акчабыз җитми. Туганнардан менә-менә акча килергә тиеш. Ә акчаны хәзер үк сорыйлар», – дип, бер олы кешедән ярдәм сорыйлар. Бар инде бездә гадилек, теләсә кемгә булышырга ашкынып тору гадәте. Абзыебызның бу гадәте аны ярык тагарак янында калдыра. Пенсионер өенә кайтып, саклык кенәгәсен алган. Егетләр машинасына утырып банкка барган һәм... 300 мең сум акча алып, мошенникларга биргән дә, әҗәтен аласы сәгатендә билгеләнгән урынга барып, аларны өч сәгать көтеп торганнан соң гына алдануын аңлаган. Ни әйтәсең моңа? Үзебезнең саксызлык, беренче күргән кешегә сабыйларча ышану әнә шундый җинаятьләргә китерә дә инде. Мәсәлән, былтыр гына да 804 шундый очракның 703 ендә кәрәзле телефоннар файдаланылган. Нәтиҗәдә, 691 кеше зыян күргән. Акчага әйләндергәндә ул 20 миллион сум тәшкил итә. Бу шалтыратуларның 70 проценты Самара, Курган өлкәсе һәм Татарстан колонияләрендәге җинаятьчеләр өлешенә туры килә.

Адым саен маҗара булган бу заманда уяулык берәүгә дә комачау итмәс, минемчә. Җинаятьчеләр чит кешенең мөлкәтен үзләштерүнең яңадан-яңа юлларын уйлап таба. Хәзер аларны урам мошенниклары гына димәссең. Алар мәгълүмати технологиядән дә оста файдалана, акча табуның яңаданяңа ысулларын эзли. Хокук саклау органнары хезмәткәрләре әйткәнчә, җинаятьнең бу төренә каршы көрәштә безгә бары, тагын бер кат кабатлап әйтәм, уялык, аңлылык һәм бар нәрсәдән хәбәрдар булу гына ярдәм итәр. Бу җәһәттән, халык арасында зур кисәтү-аңлату эшләре алып барылуын да әйтик. Һич югы торак йортлар, төрле оешмалар, терминаллар, банк учреждениеләре янына эленгән листовкаларга игътибар итегез! Иренмәгез, күз генә булса да төшереп алыгыз. Ул сезне зур бәлаләрдән саклап калыр... Хак Тәгалә сакланганны гына саклармын дигән. Зыян күрүчеләрнең бик азы гына һәм бик аз күләмдә генә акчасын кайтара алуын исебезгә төшерик тә тиешле нәтиҗә ясыйк.

САКЛАГАННЫ САКЛАРМЫН

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы кисәтә:

■ Алдатмагыз, игътибарлы булыгыз! Кәрәзле элемтә операторларыннан, хокук саклау органнарыннан алынган кисәтүләргә җитди карагыз.

■ Телефон буенча үзләрен хокук саклау органнары, радиостанция, кәрәзле элемтә хезмәткәрләре, туганыгыз йә булмаса танышыгыз дип таныштырган кешеләрдән килеп ирешкән хәбәрләрнең дөреслегенә ышанмыйча, алар белән эш йөртмәгез.

■ Өегезгә чит кешене кертмәгез. Таныш булмаган кешеләргә, хәтта алар полиция, поликлиника, торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәрләре дип әйтсәләр дә, ишек ачмагыз. Башта 01, 02, 03, 04, йә булмаса 112 – коткару хезмәтенең номерына шалтыратып, хәлне ачыклагыз.

■ Туганыгыз, якын кешегез бәлагә юлыкты дигән сүзләргә ышанып, аны коткару өчен акча чыгарып бирергә ашыкмагыз. Бу – ялган! Туганыгызда яман чир табылды, дәвалау өчен акча кирәк дип шалтыраткан кешегә дә ышанмагыз. Табиб мондый хәбәрне телефоннан әйтми.

■ Приз уйнатуларда катнашмагыз.

■ «Бозымны алам» диючеләрне якын да китермәгез. Акчасыз калуның иң сыналган юлы – шул.

■ Банк картасын ябып кую турындагы хәбәрне колак яныннан уздырмагыз. Банкның кайнар линиясенә шалтыратып, барын да белешегез. Телефон номеры банк картасының икенче ягында күрсәтелгән.

■ Урамда сезне туктатып сөйләштермәкче булган кешеләрдән сакланыгыз.

■ Алдыйлар дип шикләнәсез икән, кичекмәстән полициягә шалтыратыгыз. Сезгә һичшиксез ярдәм итәрләр.

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА: ҺАМАН ГАМӘЛДӘ



Быелның 20 мартында Татарстан Дәүләт Советы депутатлары парламентында Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» законына үзгәрешләр кертү хакында» закон проекты кабул ителде. Бу яңалыкка куанучылар шактый булгандыр. Күпчелек яшь гаиләләрнең бар өмете — социаль ипотекага фатир алу. Әмма шул программада катнашырга хаклы икәнеңне раслаучы кәгазьләрне җыеп тапшыру кадәресе! Тиздән күңелле үзгәрешләр көтелә.

Яңа канун нигезендә социаль ипотека программасында республиканың теләсә кайсы оешма һәм предприятиесе катнаша алачак. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ кешеләрне исәпкә алу эшен дә оешмалар үзләре башкарачак. Бу исә кабинеттан кабинетка чабуны һәм төрле өстәмә документлар җыюны туктатачак дип уйланыла. Оешмалар фатирга ихтыяҗлы кешеләр исемлеген Татарстан Дәүләт торак фондына үзләре җибәрәчәк.

Берара социаль ипотека программасы туктап калгандай булды. Яңа йортлар төзелмиме әллә хәзер дигән фикерләр дә ишетелгәләде. Юк икән, социаль ипотека программасы бүген дә гамәлдә икән. Залесный бистәсендә төзелеп ятучы «Салават күпере» һәм Казанның М-14 микрорайоннары – моңа дәлил. Үз кибетләре, мәктәпләре, балалар бакчалары булган кечкенә генә шәһәрчекләр болар. «Салават күпере»ндә генә дә быел 22 йорт, 3 балалар бакчасы, 2 мәктәп төзелеп тапшырылырга тиеш.

Адәм баласы үзен бәхетле хис итсен өчен өч нәрсә кирәк. Аның беренчесе – яхшы йорт, икенчесе – яхшы ат, өченчесе – яхшы хатын. Яхшы атын да алырсың, хатынын да табарсың, әмма фатирлы булу дигәне әле кайчан гына акылга сыймаслык хыял иде бит. «Социаль ипотека» программасы булмаса, фатир хыял гына булып калыр иде. Күпме кешене бәхетле иткән бу игелекле программа нигезендә 86 мең 338 гаилә яңа фатирларга күченгән. 2005–2015 елларда 1 мең 416 бина сафка баскан. Боларның барысын да «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә булмаган оешма төзеткән.

Бу фондның барлыкка килүенә быелның март аенда егерме ел булды. Ул Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев Указы белән 1995 елның 30 мартында оешкан иде. Советлар Союзы таркалган, төзелешләр тукталган чор иде бу. Татарстанның Казан, Алабуга, Бөгелмә кебек зур шәһәрләрендә 20 меңнән артык гаилә – 100, хәтта 300 ел элек салынып, инде ишелергә торган иске йортларда яши. Болардан арыну өчен «Татарстан Республикасында тузган торакны бетерү» дигән программа кабул ителә. 1996–2004 елларда торак төзелеше һәм шуңа бәйле эшләр өчен 20,5 млрд. сум акча сарыф ителә, гомуми мәйданы 2 671,7 мең квадрат метр булган 49 мең фатир төзелә. Әмма тузган торакны бетерү программасы тәгәлләнеп килсә дә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар саны гына кимеми. Болар инде тузган торакта яшәүчеләр түгел – әти-әниләре белән кысан фатирларда интегеп көнкүрүче яшь гаиләләр, кеше почмакларында яшәргә дучар укытучылар, табиблар...

2004 елның 27 декабрендә «Татарстан Республикасында торак төзелешенә дәүләт ярдәме турында» яңа закон № 69-ЗРТ кабул ителә. 2005 елдан «Социаль ипотека» программасы гамәлгә ашырыла башлый. Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ булып, яңа программада катнашырга теләк белдерүче гаиләләрнең электрон реестры төзелә. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды төзегән йортлардагы фатирларның 45 проценты – шушы программага акчалата ярдәм күрсәткән оешма хезмәткәрләренә, 45 проценты – бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә, 10 проценты кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә тәгаенләнә. Фатир хакын 28 елга кадәр кичектереп түләү мөмкинлеге бирелә. Түләнеп бетмәгән өлеше исә ел саен 7 процентка арта бара. Килешү төзелгәннән соң гаиләдә бала туса, ул гаиләгә 200 мең сум күләмендә субсидия түләнә.


Социаль ипотека программасы гамәлгә куела башлаганнан алып быелның 18 мартына кадәрге арада программада катнашучы гаиләләрдә барлыгы 30 мең 759 бала туган, республика бюджетыннан аларга 6 052,9 млн. сумлык компенсация түләнгән. Фонд бюджетына иң күп өлешне «Татнефть» оешмасы кертә, шулай ук «ТАИФ», «Генерирующая компания» ААҖ, «Татнефть–Нефтехим» ИК һәм башка оешмалар да читтә калмый. Программада республикабызның 2 меңнән артык предприятиесе катнаша.

Социаль ипотека программасы белән бергә, республикабызда арендалы торак төзү программасы да гамәлдә. Монысы әле яңа юнәлеш. Фондның җитәкчесе Тәлгать Абдуллин әйтүенчә, арендалы фатирларга теләк белдерүчеләр аз икән, кешеләр күбрәк социаль ипотека белән кызыксына, ди. Бәлки, бу программа хакында күпләр әле белеп тә бетермиләрдер. Ул РФ Президенты Владимир Путинның 2012 елның 7 маенда кул куйган 600 нче Указы нигезендә гамәлгә куела. ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды 2013 елда арендалы торак программасы буенча 16 йорт төзи башлаган иде. Шуларның икесе инде тапшырылган да.

– ХӘТЕРЛИМ! НЕФТЬ ЧЫККАН ИҢ БЕРЕНЧЕ КӨННЕ, ӘЛБӘТТӘ, ХӘТЕРЛИМ!

Моңарчы бик күп сорауларыма: «Хәтерләмим инде...» – дип җавап биргән Миңнегаян апа кинәт балкып китә. (Ярты гасыр элек булган вакыйгаларның күбесе хәтер төпкелендә күмелеп калуы гаҗәпләндерми анысы. Аннан соң күпме сулар агып, никадәр җилләр искән бит инде!)





Гөлнур САФИУЛЛИНА

БЕРЕНЧЕЛӘР

«Иртүк эшкә бара идек. Ул чакта мине инде икенче скважинаны борауларга Тимәш авылы ягына күчергәннәр иде. Ә 1 нче скважина Яңа Шөгердән ике чакрымда гына урнашкан. Кинәт шул яктан: «Ура! Ура!» – дип кычкырган тавышлар ишеттек. Мәсгудә белән без дә йөгердек. Ул хәзер мәрхүмә инде... Соңгы көннәрдә гел шул хакта сөйлиләр, нефтьне көтәләр иде. Барсак, фонтан бәрә! Шактый биек. Безнең өскә дә сиптерде. Коендык инде... Кулларны да юдык нефтьтә. Аннан эшкә киттек. Үзебезнекеләргә тизрәк бу яңалыкны сөйләргә. Ул көнне беренче тапкыр эшкә соңга калдык...»

1943 елның 25 июль иртәсе була бу. Татарстан нефть тарихының тәүге сәхифәсе ил өчен иң катлаулы вакытта – Бөек Ватан сугышы барган елларда языла. Нефть – сугышның ипие, Татарстанда «кара алтын» чыга башлавын бөтен ил түземсезлек белән көтә. Бигрәк тә Кубань,

Кавказ якларында стратегик запас дошманга калмасын дип, нефть промыселларын үз куллары белән ватып-җимереп, шартлатып киткәч... Шул көнне үк Мәскәүгә сөенечле хәбәр юллана: «Разведчиклар коллективы, партия һәм совет хөкүмәте җитәкчелегендә, Шөгер районын кыска вакыт эчендә икенче Баку итәргә бөтен көчен куячак». Телеграммага Шөгер нефть разведкасы начальнигы Лукин, өлкән инженер Шеломонов, өлкән геолог Егоровлар кул куя.

Бу көн, ниһаять, килсен өчен 1 нче скважинаның буровой мастеры, бригаданың җитәкчесе Гариф Хәмидуллин көн-төн буровойда ята, алны-ялны онытa, кул астында эшләгән кешеләргә үзенең паекларына кадәр бүлеп бирә: түзсеннәр, чыдасыннар, сынатмасыннар гына! Мәрвия Шәйхетдинова, Зөлхиҗә Гайнанова, Гаян Гаязова, Нурсинә Сөләйманова... Ул иртәне Татарстан нефтенең беренче фонтанында коенучы хатын-кызлар... (Сугышка киткән әтиләрен, ирләрен буровойда алар алыштырмый, кем алыштырсын?!) Әлеге вакыйгага шаһит булучылар шакката: нефть шулкадәр күп була, хәтта аның иге-чиге юктыр кебек тоела. Өлкән геолог Егоров журналга: «Бораулантан 1 нче скважина тәүлегенә 20 тонна дебит белән чиста нефть бирә башлады», – дип яза. Нефтьне Келәүле станциясендәге тимер юл цистерналарына төяп, СССРның төрле төбәкләрендәге нефть эшкәртү заводларына озатырга кирәк була. Беренче нефтьүткәргеч торбалар салу өчен траншеяларны да хатын-кызлар казый... Туң җирне чокып, ач килеш...

Әйе, нефтьнең беренче фонтаны тылдагыларның Җиңү өчен керткән бәһаләп бетергесез зур өлеше була. Ничек сөенмисең?! Болай да барлы-юклы киемнәреннән нефтьне ничек юып бетерәселәрен дә уйламыйча, ул көнне яшь кызлар, хатыннар, яшүсмерләр, ир-атлар – барысы да нефтьтә коена. Миңнегаян апа Харазова: «Хәтерлим әле...» – дип әйтә алучыларның соңгыларыннан.

...Әтиләре Мәннаф аганы сугыш башлануның беренче көнендә үк фронтка озаталар. Өйдә биш бала кала, әниләре алтынчыга авырлы – төпчек сеңелләре Тәнзилә кыш кергәч кенә туа әле. Гаиләнең төп таянычы – олы кыз – уналты яшьлек Миңнегаян була. Буровойга ул парта арасыннан барып керә. Үзеннән шактый өлкән Нурсинә апа Сөләймановaның: «И-и балакаем, әрәмнәр генә булырсың инде! Мондагы авыр эшкә чыдамассың, кулларың калмас!» – диюе әле дә исендә Миңнегаян апаның.

Башта аны кочегар ярдәмчесе итеп алалар. Иртәнге алтыдан кичке алтыга кадәр эшләгән өчен 1 килограмм ипи бирәләр. Каравылда торган әнисенә 400 грамм ипи тия, өйдәге вак бала-чагага – 250 шәр грамм. Чоры өчен, бер карасаң, аз да түгел кебек... Тик табынның бөтен сые шул ипи генә булгач соң!

– Инәй миңа көндез эштә ашарга бер телем ипи кисеп куя иде, – ди Миңнегаян апа. (Боларны ничек онытасың!) – Аннары бәрәңге алып бара идек. Ике-өчне... Аны мичкә салып пешерә идек. Йөрергә ерак. Беренче буровой авыл янында гына иде әле, ә мине бераздан икенчегә күчерделәр. Көн дә иртән уникe чакрым барабыз, кичен шуның кадәр юлны җәяү кайтабыз. Яңгырда да, карда да, буранда да... Тирә-юньдә бер ут әсәре юк! Буранда адашкан чаклар да булгалады. Әмма иң куркынычы бүреләр иде. Әйе, ике-өч тапкыр очрадылар. Язын юл буенда утырып калган чаклары булды. Ярый, арттан иярмәделәр... Шуңа күрә кызлар белән бергәрәк йөрергә тырыша идек. Мәсгудә, Мансуралар белән... Кулыбызга таяк тотабыз да китәбез. Кая ул зарлану – сугыштагыларга бездән күпкә авыррак иде...

Аннан конторага чакырып алып, аларны – ике кыз һәм ике егетне Саратовка укырга җибәрәләр. Өч ай буе танк моторларын сүтәргә, җыярга, төзәтергә өйрәтәләр. Укудан кайткач, аны инде дизелист итеп куялар. Ир-ат эше дә бит, тик сайланып торыр чак түгел... «Миңнегаян сменасында дизельләр бер дә ватылмый, эш туктап тормый», – дип кызны гел мактый торган булалар. «Безнең әни техника, машина двигательләре турында ир-атлар белән гомер буе бер телдә сөйләште», – дип, балалары бүген дә аның белән горурлана әле.

Энесе Мөхтәсәр дә эшкә буровойга килә. Атлар карарга алалар аны. Миңнегаян: «Гел ат арасында йөрмәс, берәр җиргә укырга җибәрегез», – дип кереп сорый. Токарьга укып кайта Мөхтәсәр.

«Без – беренчеләр булачакбыз!» – Гариф ага бу сүзләрне теленнән төшерми.

Ул елларда авырлыкларны ил белән бергә күтәрәләр. Шатлыклар да уртак була. Сугыш тәмамлангач, ирләр кайта башлый. Буровойның ир-ат кына башкарырга тиешле күп эшен алар кабат үз иңнәренә ала. Хатын-кыз икәнлеңне искә төшерер, гаилә корыр, бала табар көннәр килә. Зыя белән Миңнегаян бер кичәдә танышалар. Армиягә 1939 елны ук алынып, туган ягына Япон сугышыннан соң гына әйләнеп кайткан Зыя инде гаилә кору турында уйлап йөри. Кызның да вакыты җиткән дә... Әмма ул: «Йорт салып, инәйне шунда кертмичә, кияүгә чыгу турында уйламыйм да! Яратсаң, көтәрсең...» – ди.

– Әти сугышка киткәндә без Шөгердә ике бүлмәле фатирда калдык. Кечкенәләр үскәч, кысрык була башлады. Мөхтәсәр белән икәү йорт салабыз дип тотындык. Ссуда алдык, бура... Икәү күтәрдек тә без аны. Кечкә күршеләр эштән кайтты да: «Балалар, сез бит бураны дөрес җыймагансыз», – диделәр. Баксаң, өйнең тәрәзәләрен урамга түгел, бакча ягына калдырганбыз икән. Иртәнгә кире сүттек...

Зыя белән кушылып, инде ике балалары тугач, бөтен гаиләне (гаиләне генә түгел, бөтен Шөгерне!) тетрәндергән бер вакыйга була. Сугышта хәбәрсез югалган әтиләре Мәннаф кайтып төшә. Бу хакта Миңнегаян апаның кызы Раилә ханым сөйли:

– 1952 ел бу. Баксаң, безнең бабай әсирлеккә эләккән булган икән. Хатлары килмәгәч, исәндер дип уйламаганнар да. Өйгә кайтып керә бабай. Йортта беркем юк.

Фото: Газинур Хафизов

Каяндыр бала елаган тавыш ишетелә. Бөтенесе эштә икән, ә мине, чыгып йөрмәсен дип, кәрзингә салып, караватастына тыкканнар. Бабай мине шуннан табып ала. Кайсы улы-кызының баласы икәнен дә белми... Нигәдер, иң яраткан оныгы мин булдым аның! «Хәбәрсез югалды», дип, бабай өчен моңарчы пособие алып торган булалар. Ул кайткач: «Акчаны кире түләтерләр инде», – дип бик кайгырышканнар...

...Разведка идарәсе Әлмәткә күченгәндә, Харазовлар Шөгердә генә калырга хәл итә. (Ул чакта нефтьчеләр гаиләләрен гел «чегән тормышы» – күченү арты күченү көткән. Күчмә тормышның бөтен авырлыгын тагын хатын-кыз күтәргән: ирләр көне-төне буровойда эшләгән, ә хатыннар скважинага якын авылларда кемгәдер өйдәш булып, кайда палатка, ә кайда җир өйләрдә бала үстергән. Мондый шартларда ирләренең мазутка чумган киемсалымнарын ничек юып, ничекләр киптереп өлгертте икән алар?!) Олы улы Наилне тапкач, Миңнегаян апа башта депода, аннан кош фабрикасында моторист булып эшли. Ә Әлмәткә барып укып кайтканнан соң, ашханәгә урнаша – нефтьчеләрне ашата. (Хәер, озакламый хатын-кыз һөнәрен кабат ир-атныкына алыштыра ул: «пенсиягә акчасы булыр», дип, нефть-битум заводына кочегар булып күчә.) Бу вакытта алар Шөгердән егерме чакрымдагы нефтьчеләр бистәсендә – Зеленая Рощада яшиләр. «Качалка»лардан нефть бирегә – товар паркына җыела. Әтиләре шунда мастер. Миңнегаян апаның кече улы Равил абый сөйли: «Куян күчтәнәче дип, кичен безгә калган ипи кисәкләрен бирә иде әти, ә аларга нефть исе сеңгән була... Ул ис безгә бик якын, хәзер дә балачакны хәтерләтә. Сагынабыз хәтта... «Качалка»лар арасында уйнап үстек бит».

Өлкән кеше өчен игътибардан һәм җылы сүздән дә кадерлерәк тагын нәрсә бар?!

Шулай булгач, аларның да киләчәкләрен нефть белән бәйләүләре гаҗәпмени?! Харазовларның өлкән уллары Наил абый «Ижевскнефть» идарәсендә озак еллар инженер-бораулаучы булып эшләгән. Бүген аның ике улы да нефтьче. Равил абый да Себердән, нефть табудан 2005 елда гына кайткан. Ә Раилә апа? Нефтьче хатынын нефть тармагыннан ничек аерып карыйсың? Әниләре хәтерендә уелып калган беренче буровойлардан җай белән генә бүгенге көннәргә кайтабыз.

– Минзәләгә безнең бөтенебезне әнинең энесе мәрхүм Мөхтәсәр абый җыйды. Ул разведка идарәсе белән бергә Шөгердән – Лениногорскига, аннан – Әлмәткә, Әлмәттән Минзәләгә күчкән. Күп нефтьчеләр яңа нефть ятмасы ачкан саен, шулай бер төбәктән икенчесенә күченгән. Гаиләдә өч бала булса, шуңа да өчесе өч җирдә туган аларның. Без Минзәләгә килгәндә нефтьчеләр Ижевскида бораулый иде. Абыйлар да, ирем Рөстәм дә эшкә шунда йөрде. Удмуртиягә дүшәмбе китеп, атна азагына кадәр торалар иде. Җомга кичкә таба вертолетлар оча башласа, беләбез: ашны салырга вакыт – кайталар. Ижевскидан Себергә киттеләр... 2004 елга кадәр Минзәләдән Себергә ике меңнән артык кеше вахта белән барып эшләп йөрде. 24 бораулау бригадасы! 17 көн – эштә, 13 көн өйдә була иде Рөстәм. Аннары берәр айга китә башладылар. Өйдә кунак кына булдылар. Яшеренбатырын түгел, нефтьче гаиләләрендә тормышны хатыннар алып барды. Балаларның ничек үскәнен ирләр күрмәде дә: бер кайтуларында көлеп ята торган була сабый, икенчесендә инде йөгерә... Юк, минеке мазутлы киемсалымын бер тапкыр да Себердән юарга алып кайтмады. «Содага салабыз да бер-ике сәгатьтә җеби», – дия иде...

Безне тыңлап торган Миңнегаян апа үзалдына: «И-и, үтте инде гомерләр... – дип куя. Күңелен кузгаттык шул... Аннан кинәт искә төшкән тагын бер хатирәсен сөйләп китә. – Башта вахтага чабатадан йөрдек. Өскә, нәрсәбез бар, шуны кидек. Бер заман галошлар бирделәр. «И-и, нигә шуны озын балтырлы итеп ясамыйлар икән? Пычракта батмас идек», – дия идем. Аннан сырган чалбар, фуфайка бирә башладылар. Спиридоновкада эшләгәндә бер карчыкта фатирда тора идем. Чалбарны тотып карый иде дә: «Бигрәкләр авыр, ничек күтәреп йөрисең моны, кызым?» – дия иде...»

Балалары килеп төпләнгән Минзәләдә Миңнегаян апа да күптән инде үз кеше. Әтиләре Зыя ага мәрхүм булгач та, 1994 елны алып килгәннәр аны бирегә. Моңарчы әле үз өе белән яшәгән. Улы Равил, килене Гөлфинур тәрбиясенә күчкәненә икенче ел гына. Кадердә, хөрмәттә ул! Намазын калдырмый, уразасын әле узган ел да тоткан. Быел менә туксан яшен бәйрәм итәргә җыеналар. «Әнине онытмыйлар!» – балалары бу сүзне беравыздан әйтә. «Безнең «музей экспонаты»ның хәлләре ничек?» – дип, «Лениногорскнефть» идарәсеннән бүләк-күчтәнәчләрен күтәреп, бәйрәмнәргә гел килеп торалар икән. Сугыш вакытында буровойда эшләүчеләрнең хәләхвәлен узган ел «Татнефть»нең профсоюз комитеты рәисе Гомәр Яруллин үзе белешеп йөргән.

Кырык өченең июль иртәсендә 1 нче номерлы скважина янында басып торучылар, бәлки, нинди зур вакыйганың шаһиты булганнарын, тиздән тирә-юньдә бербер артлы шәһәрләр төзеләчәген, юллар салыначагын, меңләгән скважина бораулыначагын, миллиардлаган тонна нефть табылачагын, алар ул көннәрдә башкарган эшләрне бервакыт: «Монысы – хатын-кыз һөнәре түгел!» – дип санаячакларын ул вакытта ахыргача аңлап та бетермәгәндер.

Миңнегаян апа, кытыршы куллары белән күлмәк итәген төзәткәләп, әллә үзен аклагандай, әллә хәтер сандыгының төбенә төшеп җитә алмаганга аптырап, үзалдына һаман бер сүзне кабатлый:

– Хәтерләмим шул инде...

Ул чакта күргән михнәт, авырлык, ачлык, туңуларның «беренчеләр» күңеленнән юып алгандай онытылуы, бәлки, хәерлегәдер. Бүгенге тормышның ямен, рәхәтен тоярга өлкәннәргә ул хатирәләрнең комачауламавы кирәктер. Иң мөһиме – без онытмыйк.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешүенә 5 ел тулды. Россия Президенты Владимир Путин Татарстанның шушы чордагы үсешенә югары бәя биреп: «Соңгы елларда Республика Сезнең җитәкчелектә ирешкән нәтиҗәләр Россия Федерациясендә иң яхшылардан», — дип белдерде һәм Рөстәм Миңнехановны 2015 елның сентябренә кадәр ТР Президенты вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләде.

■ Татарстанда эшмәкәр-мөселманнар ассоциациясе вәкиллеге ачылды. Ул илдәге барлык мөселман эшмәкәрләрен берләштерәчәк. Аның максаты үзара ярдәмәшү генә түгел, ә гарәп илләреннән инвестицияләр эзләү дә. Бу оешмага керергә 150 эшмәкәр теләк белдерде. Ассоциациянең президенты итеп танылган футболчы, бүген спорт функционеры һәм эшмәкәр Марат Кабаев сайланды. «Без, мөселманнар, үзебезне күрсәтергә тиеш. Кыйблабыз нинди, ничек яшибез, нилэр эшлибез», — дип белдерде ул. Төркия һәм Иранның Татарстандагы генераль консуллары Россия мөселман-эшмәкәрләренә чит илләрдәге коллегалары белән элемтә урнаштыруда ярдәм итәргә булдылар.

■ Казанда өч көн дәвамында IV Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыены узды. Анда төрле төбәкләрдән килгән 500 дән артык эшмәкәр катнашты.

■ Казанда Татарстан—Төркия эшлекле форумы узды. Чараларда Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, Төркия икътисад министры Нихат Зейбекче, ТР сәнәгать һәм сәүдә министры Равил Зарипов, Төркиянең «DEIK» тышкы икътисадый элемтәләр буенча совет рәисе Омер Җиһад Вардан катнашты. Болардан тыш, автомобиль төзелеше, җиңел һәм азык-төлек сәнәгате, 20 төрек төзелеш компаниясе килде. Чит ил кунаклары өчен инвестицияләр, сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм төзелеш буенча күргәзмәләр эшләде.

МӘДӘНИЯТ

■ Ингушетия Республикасында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре кысаларында Назраньда Татарстанның Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев урамын ачу тантанасы үтте. М. Шәймиевнең тугандаш халыклар арасындагы дуслыкны ныгытудагы эшчәнлеген Ингушетия Республикасы әнә шулай югары бәяләде.



■ Театраль премияләргә йомгак ясаган «Тантана» бәйрәме Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узды. «Кара пулат» һәм «Хуҗа Насретдин» спектакльләре «Ел вакыйгасы» номинациясендә билгеләп үтелде.

■ ТР Милли музеенда «Бүләк тапшыру атналыгы» булып узды. Ул Милли музейның 120 еллыгына багышланган иде. Әлеге акция тарихи-мәдәни мирасны саклап калуга юнәлдерелгән.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ «ТАТМЕДИА» АҖ республиканың иң яхшы почтальоннарын бүләкләде. «Иң яхшы авыл почтальоны» исеменә Әлки һәм Кукмара районнарыннан Нурсия Хәйруллина, Гөлнара Баһапова лаек булдылар. Минзәләдән Нияз Хәбибуллин «Кече шәһәрнең иң яхшы почтальоны» дип табылды. Яшел Үзәннән Мәдинә Хөсәеновага «Иң яхшы шәһәр почтальоны» исеме бирелде. Почта бүлекләре арасында Олы Кайбыч авыл почта элемтәсе бүлеге иң яхшысы дип билгеләнде.

МӘГАРИФ

■ Казанга WorldSkills International делегациясе килде. Татарстан башкаласы 2019 елда эшче һөнәрләр буенча Дөнья чемпионатын уздыру урыны булыр дип көтелә. «Казан — халыкара класслы шәһәр», — диде Россия президенты. Моның өчен Казанга Бельгиянең Шарлеруасы һәм Париждан өстенлеген исбатларга кирәк.

■ Татарстан укучылары ел саен Россиякүләм һәм Халыкара олимпиадаларда яхшы нәтиҗәләргә ирешә. Берничә ел инде республикабыз җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча ил күләмендә өченче урында тора. Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы олимпиада хәрәкәтен үстерү максатыннан уникаль проектка старт бирде: Казанга республиканың 200 укытучысын җыйды. Алар биш көн дәвамында олимпиада җиңүчеләрен тәрбияләп үстергән остазларыннан «дәресләр» алды.

СПОРТ

■ «Зенит» волейбол командасы өченче тапкыр Чемпионнар лигасы җиңүчесе булды. Рөстәм Миңнеханов котлау телеграммасы юллап, бу җиңү «Зенит» командасының Европада иң яхшы волейбол клубы икәнен расларга ярдәм итте дип белдерде. Чемпионнар лигасында Берлинда җиңү яулау «Зенит»ка Бразилиядә узачак Дөнья чемпионатында катнашу хокукын бирде.

■ 22 яшьлек Казан спортчысы Светлана Липатова Польшада узган спорт көрәше буенча Европа чемпионатында көмеш медаль яулады. Хәзер ул Рио-де-Жанейрода узачак Олимпиадага сайлау ярышларында катнашырга әзерләнә.

НӘСЕЛ КАЙТАВАЗЫ



«Мин бик куркыныч кеше: мәкерле, кире, көйсез, эчкерле... Ә иң аянычы – моңа бит мин гаепле түгел! Әби-бабаларым гаепле – үзләрен теләсә ничек тотканнар, һәм менә аларның үткәне өчен хәзер миңа изаланырга. Үзем болай акыллы да, миһербанлы да бит...»
«Обыкновенное чудо» фильмында Король (Евгений Леонов) әйткән бу сүзләрне хәтерлисезме икән? Нәселдән нәселгә күчкән геннарга ишарә итүе бит аның. Геннар чынлыкта безнең үзебезгә сайлау мөмкинлеге калдырамы яки аларны, чыннан да, чикли генәме?
Бүгенге әңгәмәдәшем – Казан федераль университетының Хатын-кызлар лигасы әгъзасы, биохимия кафедрасы доценты (Фундаменталь медицина һәм биология институты), «НПП Казан Юниверсити Вивариум» оешмасының генераль директоры, «Татарстан Республикасындагы иң яхшы 50 инновацион идея» конкурсы (2008) номинанты Әлфия Нурлиман кызы ФӘТТАХОВА.
Аңа Дебюсси һәм Бах ошый. Онытылып ял итәргә теләгәндә ул Моцартны тыңлый. (Кайчандыр музыка мәктәбен тәмамлаган кешенең дуслары арасында музыкантлар шактый булуы да гаҗәп түгел!) Достоевский иҗатына гашыйк. (Аңа әдәбиятның җитдие, саллысы, уйландыра торганы кирәк!) Бары хатын-кыз гына депрессиядән котылуның мең юлын белә дип саный.



Хатын-кызлардагы баш авыртуларның сәбәбен ачыкларга җыенганыгызны беләм. Җавапны озак көтәргәме икән әле?

– Баш өянәге авыртуы күп очракта мидәге яки тире белән ике арадагы кан тамырларының тиз арада киңәюе яки тараюы аркасында килеп чыга. Мигреньнең генетикасы инде 20 еллап өйрәнелә. Нәтиҗә шуны күрсәтә: әйе, аның белән, чыннан да, хатын-кызлар ешрак авырый. Һәм ул, артрит кебек үк, балага күбрәк анадан күчә. Мигрень өчен җавап бирүче геннар да ачыкланды. Әмма һәр ген шундый программа – ул бик яхшы эшләргә дә, начар эшләргә дә мөмкин. Теземдәге геннар бертөсле эшләмәгәнлектән, баш өянәгеннән интегүче хатын-кыз белән аның генотибы арасында бәйләнеш табу авыр. Әнидән шундый патологияле геном кабул итеп алып та, дөрес тормыш рәвеше алып барганда (дөрес тукланганда, кан тамырларын ныгытканда, спорт белән шөгыльләнгәндә, тормышка позитив караганда), берәү авырмаска мөмкин. Һәм, киресенчә, икенче кешедә мондый геннар да юк, ә ул барыбер авырый.

Без мигреньне барлыкка китерүче генны алып ташлау организмга ничек тәэсир иткәнен тычканнарда өйрәндек. Бу генның активлыгын яртылаш киметә алдык. Әмма организмда гормональ үзгәрешләр башланды... Без хәзер биохимия белән генетика арасындагы чиктә торабыз. Бөтен дөнья аптырашта: геннар ничек көйләнә, ничек тәртипкә салына – белмибез. Аларның күп өлеше нәрсә белән «шөгыльләнә» – җавап юк. Элегрәк бу ДНКларны «чүп-чар» дип санау бар иде. Хәзер исә аңлыйбыз: безнең геном «лего»ның бер өлеше генә... Шушы сорауларга җавап булмау аркасында бөтен нәрсә тукталды. Менә петуния гөле бар, аның 130 мең гены да аксым өчен җаваплы. Ә без, кешеләр, петуниядән аерылабыз шул. Шуңа күрә мигрень, инсульт кебек авыруларга һаман дәва табып булмый. Тагын биш елдан, бәлки, геннар сере ачылыр. Ул чакта максатка да ирешербез: һәр яңа туган бала махсус паспорт алыр. Анда сабыйның генетикасы гына түгел, бу геннарның киләчәктә үзләрен ничек тотачагы да күрсәтелер: балага киләчәктә нинди авырулар янарга мөмкин – инфаркт, симерү, сукыраю... Бу паспорт, әлеге чирләр булмасын өчен баланы ничек дөрес тәрбияләү һәм дөрес тукландыру өчен, әти-әнигә һәм табибларга тапшырылачак. Мондый паспортлар 2005 елдан башлап бирелергә тиеш иде инде. Сүз куерткан арада биология бик алга китте. ГМО, синтетик юл белән табигатьтә очрамаган бактерияләр, гөмбәчекләр килеп чыгу начар нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Дөньяда намуссыз галимнәр дә җитәрлек...

Безне дәваларга тиеш булган наномашиналар барлыкка килүне көтү дә шомландыра. Бәлки алар киресен эшләр?

Бер ел элек Бөекбритания кендек каннары саклана торган банкка күзәнәкләрне модификацияләргә рөхсәт итте. Әйе, ясалма орлыкландыру юлы белән бала яралтканда сез, беренче чиратта, аның сәламәт булуын телисез. Ә аннан күзләре зәңгәр булуын теләрсез. Озын буйлы, көчле кирәк диярсез. Музыкант итеп күрергә теләрсез... Геннары модификацияләнгән бала, бәлки, дүрт колаклы булып туар. Кемгә үпкәләр ул чакта? Ахыры нәрсә белән бетәсен белмибез, әмма рөхсәт итәбез. Изге ният белән башланган эш югыйсә. Юристлар, күкәй күзәнәкләр хокукын яклаучы адвокатлар хәзер баш күтәрде... Минем үземне синтетик биология буенча башкарылган эшләр дә куркыта.

Паспорт дидегез. Яңа туган балаларга биреләсе ул документка сез инде бер юл яздыгыз. Сабыйда киләчәктә агрессия буламы-юкмы икәнен төгәл әйтә аласыз.

– 2004 елдан башлап агрессия психик авыру дип санала башлады. Минем мәгълүматлар буенча, безнең



гадәти мәктәпләрдә ир балаларның 5-7 проценты нигезсез агрессия синдромыннан интегә. Әмма бу хөкем карары кебек яңгырамасын иде. Агрессия ихтималы генетик паспортта күрсәтелгән баланы әни кеше 5 яшь тулуга спорт секциясенә җитәкләп китәр иде. Анда инде аңа усаллыгын күпме чыгарса да ярый... Алдагы ун ел эчендә, гормональ системасы тәмам формалашканчы спорт белән шөгыльләнгән бала, арып-талып кайтыр иде дә, йокларга гына авар иде. Башка бернәрсәгә – урамга, наркотикларга, эчүгә вакыты калмас иде...

Фәндә сабырлык кирәк: дөрес нәтиҗә ясау өчен озак вакыт таләп ителә. Монда берүзең генә купкә ирешә алмыйсың.

Агрессивлык кебек геннар тайпылышын тест ярдәмендә ачыклап була, дисез. Әти-әниләр андый тестны кайдан таба ала?

– 4-5 яшьлек балаларны шактый өйрәндек: аларда мондый синдром бармы-юкмы икәнлеге төкеректә инде күренә. Әлеге «тест-полоска»ларны күпләп җитештерү өчен акча гына кирәк хәзер. Әти-әниләр аны даруханәдә сатып алып, балада геннар мутациясе барлыгын яки юклыгын өйдә үзләре ачыклый алачак.

Кияүгә җыенучы кызлар булачак ирләрендә шизофрения кебек чирләр юклыгын да шушындый тест ярдәмендә генә белә алса, никадәр язмышлар җимерелми калыр иде...

– Бу дөрес теләк, никахка кадәр, гомумән, генетикларда тикшерелү кирәк. Сез бит сәламәт бала тудырырга телисез... Дәү әнием Зәйнәп әйтә иде (ә ул Казанда билгеле абыстай иде): «Димчеләр нәселдә кем, нәрсә белән авырганы белән кызыксынмый калмаган. Һәм бу хакта яшермәгән. Ә сез яшьләр бүген бик кызык: ул нәселдә акылы җиңел биш туган бар, әмма барыбер шул гаиләгә килен булып төшәргә җыенасыз». Минемчә, хәзер мондый тайпылышларны ачыклау җиңелрәк тә: интернет бар, ә анда һәркемнең тормышы уч төбендәге кебек күренә. Белү беркайчан да комачауламый. Дус кызым төпле, ышанычлы санаган бер ир-атның ВКонтактеда алтмыштан артык хатын-кыз белән шактый якыннан аралашуын ачыклады һәм, әлбәттә, аралары өзде.

Генетика белгеченә бармаган очракта, сайлаган ярыгызның туганнарына ныграк игътибар итегез. Бигрәк тә әни ягына, булачак кайнанагызның абыйларына – ир балага күбрәк әни ягы геннары күчә. Берәү дә, әйткәнемчә, баласының чирле тууын теләми... Һәм, гомумән, чирләрдән арынырга вакыт инде безгә. Алдагы биш елда моңа нокта куярбыз дип уйлыйм. Әле чума, әле чәчәк, инде менә йөрәк-кан тамырлары чирләре... «Туклану биохимиясе» дигән яңа фән бар: Урта диңгез буе диетасы гына бу чирнең барлыкка килүен киметә икән. Балык, балык продуктлары, зәйтүн һәм зәйтүн мае, сыр, җиләк-җимеш, яшелчә... Бер бит кәгазь алыгыз да, бер якка әниегез һәм аның туганнары нәрсә белән авырганын, нидән үлгәнен, ә икенче якка әтиегезнекен языгыз. Тышкы яктан кемгә күбрәк охшагансыз, шуның 50 процент чирләре сезгә күчү ихтималы бар. Чирләргә каршы алдан аяк киенү хәерле... Хәзер «яшәү сыйфаты» һәм «үлем сыйфаты» дигән төшенчәләр турында күп сөйләнелә. Әйе, барыбызга да китәсе, әмма китү белән китү арасында да аерма бик зур. Дәү әниемнең намаз артыннан кылган догалары гел бертөсле тәмамлана иде: «Соңгы минутка кадәр аяк өстемдә йөри алсам икән», – дия иде. Һәм ул, чынлап та, нибары 15 минут кына авырды! Шул вакыт эчендә күзен ачып: «Миңа җиде фәрештә аш пешереп ашатты», – диярга дә өлгерде әле. Бик бәхетле елмаеп җан бирде. 92 яшь иде аңа. Минем дә дөньядан шулай китәсем килә... Шактый катлаулы тормыш юлы узган, бик күп югалтулар кичергән, әмма яшәү ямен, тәмен җуймаган кеше иде дәү әни. Мин аны бик сагынам...

Соңгы вакытта сезнең лаборатория ни белән шөгыльләнә?

– Кызык эшләрнең берсе – тычканнарга кешеләрдән яман шеш өлешләрен алып урнаштырдык. Дарулар белән төрле тикшеренүләр үткәрү өчен модель үстереп алырга кирәк иде. Ә безнең тычканнар бер атна гына авырды да, шеш юкка чыкты... Шактый зур шеш кисәкләре иде алар, аны кеше тәненә китап тегеп кую белән генә чагыштырып була. Әлеге яман шешләр белән авыручылар үзләре инде мәрхүм булды... Хәзер тычканнарда аның кая киткәнен ачыклыйбыз. Әгәр организм аны ялкынсыну кебек кенә кабул итә икән, бу процесс ничек бара? Яман шеш белән авыручыларның, IV стадиягә җиткәч, кинәт терелгән очраклары бар. Гален – бөек рим табибы: «Шеш ул – кара меланхолия», – дигән. Тик безнең тычканнарда депрессия юк иде бит! Кызларның берсе хәзер ремиссиядән соңгы гистологияне тикшерә, икенчесе – биохимияне... Бер-ике айдан соң уртак бер картина туар, бәлки.

Кешенең кылган яхшылыгы да, начарлыгы да үзенә әйләнеп кайта, дип санаучыларның берсе Сез.

– Мин инде күп еллар эзотерика белән мавыгам. Ислам, христиан дине тарихы белән кызыксынам. (Миңа суфилар бик якын: хакыйкать серен төшенә алмаячакларын белгән килеш тә алар аңа таба атлаганнар.)

Фән белән шөгыльләнүне, белем алуга омтылышны Аллаһы Тәгалә исламда гына хуплый – башка бер диндә дә юк бу. Исламда гына барлык хәдисләр кешенең тәненә түгел, ә җанына юнәлтелгән. Мәктәптә укыганда ук бер нәрсәне аңладым: биолог булсам, үземне кызыксындырган башка нәрсәләрне дә өйрәнә алам, ә диннәр тарихы белгече генә булсам, биолог була алмаячакмын. Без җиргә сынау узарга килгән, аны лаеклы итеп узу кирәк.

Язмышларны кеше үзе яза дип санайсыз инде алайса.

– Күпмедер дәрәҗәдә – әйе. Кешенең геномы сере ачылгач, башта ул генотип буенча гомер итә дип уйланылды. Аннан: «Юк, генотипка бәйлелек 40 процент кына, 60 процентны әйләнә-тирәлек, мохит хәл итә», – диделәр. Мин үзем кеше яшәгән әйләнә-тирәнең аңа тәэсире 80 процент тирәсе дип саныйм. Без социумнан башка яши алмыйбыз: бер-беребезгә үзебез уйлаганнан да күбрәк бәйләнгәнбез. Молекуляр генетика аксыл тәнле кешеләрнең барысы да 50-60 мең ел элек туганнан туган ике сеңелдән килеп чыккан ди әнә. Сүз уңаеннан, молекуляр генетика белән шөгыльләнгәндә без хәтта кафедрада да шактый кызык нәрсәләргә тап булабыз. Төрле анализлар өчен еш кына үзебезгә дә кан бирергә туры килә. Тикшерүләр исә кайберәүләребез арасында туганлык җепләре барлыгын ачыклады! Ә эзли башлагач, уртак тамырлар, чыннан да, табылды. Безнең халык элек юкка гына шәҗәрәләр төземәгән.

Сезнең тәүлек егерме дүрт сәгатьтән генә тормый кебек тоела. Вакытны ничек җиткерәсез?

– Үзең өчен кызык булган нәрсәгә вакыт табасың ул. Аннан, биолог буларак, мин бер нәрсәне беләм: баш мие гел үсештә, гел мәшгуль булырга тиеш. Вак моторика белән (бармак очлары белән нидер эшләү) шөгыльләнү дә аны ныгыта, үстерә: бәйләү, тегү, чигү... Фортепьянода уйнау. Катлаулы әдәбият уку (сүзлек белән укысаң бигрәк тә әйбәт).

Телевизор карыйм икән, болай гына утыра алмыйм: миңа һәрвакыт бәйләргә кирәк. Туганнарым: «Эшсез калсаң, акчага аптырамаячаксың», – дип шаярта. Күбрәк бүләккә дип бәйлим. Соңгы вакытта тегү белән мавыгам әле. Бер дус кызым тегүче – ул инде пальтога, тунга кадәр җитте. Минем әле күлмәктән, итәкчалбардан узганым юк. «Күз курка, кул эшли», диләр – кыйммәтле тукымадан нидер кияргә теләсәң, бүген үзең тегү отышлырак. «Нинди кул эшләре беләсез?» – дип кайчак студентлардан да сорыйм. Юк, белмиләр. Югыйсә хәзер моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. «Кулы күбрәк эш белсә, хатын-кызга тормышта яшәү җиңелрәк. Кемнәндер көткәнче, үзегезгә күбрәк ышаныгыз», – дим аларга. Бәйләү, мәсәлән, релакс ул. «Тынычландыра», – дип, табиблар хәтта йөрәк чирле ир-атларга да бәйләргә куша. Бер танышыма, ире белән аерылышкач, кемдер: «Депрессиядән качу өчен сөйләнбелән чигеп кара», – дип киңәш биргән. Башта ул песи рәсеме чикте. Матур килеп чыкты. Аннан кемгәдер икона кирәк булды – шуңа тотынды. Хәзер ул чиркәү өчен зур иконалар чигә, шуның белән акча эшли.

Сез тагын ювелир да икән бит әле.

– Бизәнү әйберләре иң элек башымда туа. Аннан «Леонардо»га китәм: хыялымдагы муенса яки колак алкасын, беләзекне ясау өчен нәрсә кирәк, шуны сатып алам. Ул кибеткә 8-10 яшьлек кызлар күп йөри – сиңа бөтен киңәшне бирергә мөмкиннәр. «Сәйлән ярдәмендә чигү нәрсә ул?» – дигәч, бер кыз минем үземә шундый әйбәт итеп аңлатты... Сабын ясау өчен наборлар сатып алучы ир-атлар да очрый анда. (Мин үзем сабын кайнатуга барып җитмәдем әле, әмма теләк бар!) Чигәргә яраткан ирләр дә күп икән. Узган ел Эрмитажга «Урта гасырлардагы Испания, Англии һәм Франциядә чигү үрнәкләре» дигән күргәзмә килде. Фотога төшерергә ярамый иде. Шунда игътибар иттем, ир-атларның күбесе смартфон белән йөри һәм сиздермичә генә чиккән бала күлмәкләрен фотога төшерә.

Берсеннән: «Ә нигә кирәк ул сезгә?» – дип сорадым. «Мин чигәм», – диде ул. Авыр эш көненнән соң кул эшләре белән шөгыльләнү һәркемгә файдага гына.

Безнең баш миенә, димәк, гел яңа тәэсирләр кирәк...

– Әйе! Шуңа сәяхәт итәргә яратам да мин. Испаниядә, Италиядә, Франциядә, хәтта Австралиядә дә булдым. Быел, мөгаен, Кырымга барырмын дип торам.

Әти хәрби кеше булгач, озак еллар Германиядә яшәдек – немецча укый алам. Инглизчә укыйм да, сөйләшәм дә. Быел үземә җәен итальян телен өйрәнергә сүз бирдем. Бик матур тел! Алай ук авырга да охшамаган.


Телләр өйрәнү дә безгә геннар белән күчә.

Әгәр кеше телне «ишетми» икән, аны җәфаларга кирәкми: андыйлар әйбәт укыячак, тәрҗемә итәчәк, әмма сөйләшмәячәк.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



2012 елда КФУ каршында Хатын-кызлар лигасы барлыкка килә. Университетта хезмәт куючы гүзәл затларны берләштереп торучы, аларның җәмгыятьтәге урынын яхшырту юнәлешендә эшләүче бу иҗтимагый оешманың рәисе – КФУның өзлексез белем бирү институты җитәкчесе урынбасары, социология фәннәре кандидаты Ирина Васильевна Терентьева. Лига университет хатын-кызларына юридик һәм психологик ярдәм күрсәтү, иҗат кичәләре һәм хәйрия чаралары уздыру, фәнни-танып белү семинарлары оештыру кебек эшләр белән дә шөгыльләнә. Бүген Лигада 124 хатын-кыз санала.



АКЫЛЛЫМ ӘСӘЛ

АНЫҢ КЫСКА РЕЗЮМЕСЫН УКЫП ЧЫККАЧ, ТЕЛ ШАРТЛАТЫП КУЙДЫМ. БУ КЫЗ ЯНЫНА ИКЕ КУЛНЫ СЕЛТӘП БАРЫРГА ЯРАМЫЙ!

Интернетка чумдым. Булачак әңгәмәдәшемнең кызыксынулары исемлегендәге чит илләр сәясәте, поляк һәм каталон телләре, Испания, «Формула 1» буенча белемемне арттырырга дигәннәре тәмам шаккаттырды мине...

Фәнзилә МОСТАФИНА

«Кичә «Барселона» белән «Реал Мадрид» уйнады. Без җиңдек!» – дип килеп керде ул. «Барселона» өчен җан ата икән. Мин футбол матчын карамаган идем. Блокнот читенә «ичмасам, футбол дөньясында нинди командалар барлыгын булса да карап чык!» дип төртеп куйдым. Әңгәмәдәшем: «Мин сиңа Фернандо Алонсо турында да сөйләрмен әле, яме?!» – дип елмайды. Әсәл белән танышлыгыбыз әнә шулай башланды.

Әсәл Хәмитова – Үзбәкстанда туган татар кызы. Гарәп, фарсы, үзбәк һәм кыргыз телләрендә «бал» дигәнне аңлаткан сүзне карт әбисе белән бабасы аңа исем итеп кушкан. Оныкларының да бал кебек татлы булып үсүен теләгән алар. Ә мин Әсәлне күрүгә исеменең үзенә килешеп торуын аңлап алдым.

Кыз кечкенә вакытта ук әнисе Мәскәүгә күченгән, Әсәлне әбисе белән бабасы тәрбияләгән. «Шулай булуы яхшы да, зур шәһәрдә тиз олыгаер идем, ә болай мин әле хәзер дә бала», – дип елмая 23 яшьлек Әсәл. Бераздан кыз әнисе янына Мәскәүгә күченә. Әсәл бишенче сыйныфта укыганда Хәмитовларның Казан чоры башлана.

Мәктәпне тәмамлагач, сәясәт белән кызыксынган Әсәл ике дә уйламый – КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтына гариза бирә. Ул керергә теләгән бүлектә ике юнәлеш була: инглиз-алман һәм инглиз-төрек. Алман теле тирәнтен өйрәнелә торган мәктәпләрдә укыган Әсәл, инглизчә ике сүз оештырып әйтә алмаса да, беренче юнәлешне сайлый. Һәм, инглиз телен су урынына эчкән төркемдәшләрен куып җитү өчен, ел дәвамында көненә алтышар сәгать тел өйрәнә. Күз яшьләре юкка түгелми – Әсәл икенче курска килгәндә инглизчә пулеметтан аттырган кебек сөйләшә.

Инглиз теле белән беррәттән, испанча да өйрәнә кыз. Мәктәптә укыганда ук бу телгә мәхәббәт уянган (анысының сере бар! – *Ф. М.*) булса да, әнисе: «Башта укырга кер әле», – дип, аны тыеп килә. 1 сентябрьдә студент билеты алгач, Әсәл беренче эш итеп КФУ каршындагы испан теле мәктәбенә язылып кайта.

Болардан тыш поляк һәм каталон телләрен дә өйрәнә әле ул. Әсәлнең: «Чиратта француз, гарәп һәм итальян телләре», – диюенә аптырамыйм да инде.

«Ә хәзер испан теленә мәхәббәтнең сере турында...» – дип әйтә генә башлыйм, Әсәл елмаеп җибәрә, ул елмаю бөтен йөзенә, күзләренә күчә. Һәм Әсәл ялкынланып 14 еллык мәхәббәт тарихын сөйли башлый: «Миңа тугыз яшьләр булгандыр, кулыма бер журнал килеп эләкте. Бер битен ачкан идем, анда – автоузышчы Фернандо Алонсоның фотосы. Булса да булыр икән бу кадәр чибәрлек, дип уйлап куйганым хәтердә. Шул вакыттан мәхәббәтем башланды да инде. Фернандоны күрер өчен «Формула 1»не карый башладым. Нельсон Манделаның бер фикере бар: «Кеше белән ул белгән телдә аралашсаң – аның акылы белән, ә кешенең туган телендә аралашсаң, аның йөрәге белән сөйләшәсең». Шуннан соң испан Фернандоның туган телен өйрәнергә карар кылдым».

Узган җәй студентлар алмашу программасы буенча Германиянең Регинсбург университетында укыганда

кумирын якыннан күрү бәхетенә дә ирешә Әсәл. Узыш барган дүрт көн дәвамында машинада куна, сакчылар күрмәгәндә законсыз рәвештә генә юынып ала, автограф алырга 34 градуслы эсседә амбал кадәр ирләр арасында сәгатьтән артык чират тора ул. Аның каравы, хәзер бүлмәсенең диварын Фернандоның автографлы плакаты, социаль челтәрдәге битен икесе бергә төшкән фото бизи.

Бәләкәй генә буйлы Әсәл 23 еллык гомерендә ярты дөньяны әйләнеп чыгарга өлгергән инде. Күптән түгел тәрҗемәче вазыйфасында «Космик технологияләр» компаниясенең Мексикада су эзләүче төркеме белән шул илгә барып кайткан. «Анда кактус ашыйлар! Согы тәмле, тик башка ризыклары әллә нәрсә түгел. Әллә кактус икәнлеген белгәнгә тәмле булмады», – дип көлә кыз.

Гәпләшә торгач, киләчәк турында сөйләшүгә дә килеп җиткәнбез. Ялындырып тормый Әсәл, уй-ниятләре белән уртаклаша: «Якын киләчәккә максатым – 21 километрга йөгерү ярыммарафонында катнашу. Ә укуны тәмамлагач, Россия Тышкы эшләр министрлыгында эшлисем килә. Аның өчен башта имтихан тапшырырга кирәк. Тик барысы да барып чыгар дип уйлыйм».

Җирдә башланган әңгәмәбез Галәм киңлекләренә барып тоташа. «Мин яңалык яратам, – ди Әсәл. – Әйтик, көннәрдән бер көнне Марска очарга тәкъдим итсәләр дә, уйлап карыйм әле, дияр идем. Кире Җиргә кайтмаячаксың дисәләр дә! Башта әнине ризалатырга туры киләчәк, әлбәттә. Һәм белешергә: Марста «Формула 1»не карар өчен телевизор бармы икән?»

Әсәлнең тормыш сәхифәсендә КФУ гына түгел, Германиянең Регинсбург һәм Испаниянең Овьедо университетлары да бар бит әле. Регинсбургка студентлар алмашу программасы буенча барып эләккән кыз. Көннәрдән бер көнне ул күңеленең (һәм акылының да!) Казанга гына сыймавын ачыклаган. Китәргә, яңа дөнья күрергә, яңа гыйлем тупларга! Ә кайсы илне сайларга? Алман телен мәктәпкә тәүге тапкыр атлап кергәннән бирле өйрәнгән кыз өчен җавабы да тиз табылган – Германиягә. Тиешле имтиханнарны җиңел генә үтеп, тормышының яңа этабына атлый Әсәл.

Германиядә алты ай, ягъни алардагы система буенча бер семестр укыган ул. Шуңа күрә чагыштырып карау мөмкинлеге дә бар. «Бездә университетта күбесенчә теорияне өйрәтәләр, аеруча түбән курсларда. Ә анда беренче-икенче курс дигән нәрсә юк. Германия югары уку йортларында бер юнәлешне сайлыйсың да, шуның буенча дәресләргә йөрисең. Ошамаса, башкасына алыштырасың. Бер юнәлештә төрле яшьтәге яки, безнеңчә әйтсәң, төрле курстагы кешеләр була. Шуңа күрә анда беренче көннән үк практика башлана», – ди Әсәл.

«Нишләп әле очмаска? Марстан башка планеталарга да ерак түгел бит. Ә мин сәяхәтләр яратам!»

Овьедо исә әлеге дә баягы Фернандо Алонсо белән бәйле, ди кыз. Автоузышчының туган шәһәре икән ул! Шуңа күрә Әсәл Овьедо университетына барып, испан телен ныгытып кайтуны үз алдына максат итеп куя. Максатына ирешә дә! «Овьедо – искиткеч матур шәһәр! Һәм чиста! Анда җирдән ризык алып ашарга була – бер тамчы тузан юк, пычрак турында әйтмим дә инде!» – дип елмая ул. Кызыктыра белә Әсәл. Мексика турында сөйләгәнен тыңлаганда күңелдә кайчан да булса кактус татып карау теләге уянды. Менә инде хәзер Испаниягә барасы килә!

«Ә Казан?..» – соравымны әйтеп бетермим, Әсәл мине ярты сүздән аңлап ала. «Казанны яратам мин. Бу шәһәр балалык һәм үсмерлек чорын уздыру өчен яхшы. Бөтен мөмкинлекләр бар, шул ук вакытта баланың индивидуальлеген дә «йотмый». Хәзер мине бүтән шәһәрләр, зуррак дөнья кызыксындыра. Ә җитлегү чорын узгач, 35–40 яшьтә мин Казанга кайтып төпләнер идем».



Татарстанда «Президент белән бергә» дигән Иҗтимагый инициативалар үзәге ачылды. Аның төп максаты — республикада яшәүче һәр кешегә Татарстанны үстерү юнәлешендәге идеяләрен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр ачу.

Әлеге үзәкне оештыручылар арасында – «Сәләт» республика яшьләр иҗтимагый фонды, Татарстанның иҗат яшьләре академиясе, Аграр яшьләр берләшмәсе, эзтабарлар отрядларының «Ватан» берләшмәсе, студентларның хезмәт отрядлары һәм яшьләрнең башка иҗтимагый оешмалары. «Берләшү безнең өчен бүген аеруча мөһим. Һәр фикерне кабул итәргә һәм аны үсешебездә дөрес файдаланырга кирәк», – дип, бу идеяне Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов та хуплады.

Республиканың киләчәгенә битараф булмаган, гомер кичергән җирлегенә файда китерергә теләгән кешеләр – олысы-кечесе – үз тәкъдимнәре белән моннан соң Иҗтимагый инициативалар үзәгенә мөрәҗәгать итә алачак. Тәкъдимнәрне «Сәләт» фонды бинасына килеп әйтергә яки интернет аша да юллап булачак.

Бүгенге көндә бигрәк тә авыл хуҗалыгы белгечлекләрен үзләштергән яшьләрне авылда калдыруга кагылышлы проектларга өстенлек бирелә.



КИТАП ДӘВЕРЕ ӨЗМӘС

Бүгенге әңгәмәдәшебез — Татарстан мәдәният министры урынбасары Нигъмәтуллина Гүзәл Азат кызы. Ике югары белемле (Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, Казан федераль университеты — *ред.*) зыялы кеше, фәлсәфә фәннәре кандидаты буларак, Республикадагы мәдәни һәм әдәби вазгыятькә әтрафлы бәя бирә алды.

2015 ел Россиядә Әдәбият елы дип игълан ителде. Үзебезнең дә меңьеллык әдәбиятыбыз бар. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Сәйф Сараи, Кандалыйлар башлаган зур әдәбият Каюм Насыйриларга барып тоташа... Димәк, әдәбият елы тарихыбызны барлар өчен әйбәт сәбәп.

– Әйе, безнең мәдәниятебез бик бай. Казан XVII–XIX гасырдан башлап төрки дөнья өчен мәгърифәтчелек үзәге булды. Ә халкыбыз алдынгы карашлы, укымышлы булуы белән һәр заманда аерылып торган. Узган ел «Казан – төрки дөньяның мәдәни башкаласы» Программасы кысаларында оештырылган иҗат һәм фән әһелләре очрашуларында төрки дөнья язучылары, шагыйрьләре, галимнәре халкыбыз белән горурланырлык сүзләрне еш кабатлады.

Татар халкы ата-бабалар оеткысын салган «китаплы халык» дигән мәртәбәле исемгә тугры калды. Халык тормышында китапның урыны турында мәшһүр галимебез Әбрар Кәримуллин берничә китап язды, гаять кызыклы мәгълүматларны дөньяга чыгарды. Әйтик, йөз ел элек Казанда 26 басмаханә эшләгән, анда ел саен меңнән артык исемдәге китап басылган.

Әдәбият, китаплар дөньясына күз салсак – бу үз сафларына 304 әгъзаны берләштергән Язучылар берлеге дә, гомуми китап фонды 66 миллион данәгә җиткән 3300 китапханәбез дә. Республика үз иҗат әһелләрен Габдулла Тукай, Муса Җәлил исемендәге дәүләт премияләре, Гаяз Исхакый, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Җамал Вәлиди, Абдулла Алиш исемендәге дәрәҗәле әдәби бүләкләр белән зурлый. Ә бит әле ел саен уздырыла торган Боратынский, Аксенов, Лихачев әдәби укулары да бар. Быелдан башлап болар рәтенә Пастернак укуларын да өстәргә кирәк. Пушкин, Державин, Тукай туган көннәрендә зурлап үткәрелә торган шигырь бәйрәмнәре, «Ел китабы» бәйгеләре... Күп, бик күп алар!

Россиядә бара торган Әдәбият елы Мәдәният елының матур дәвамы булып кабул ителә...

– Узган елда бик күп файдалы эшләр башкардык. Матур вакыйгалар тезмәсе яңа мәдәният биналары корып кую, мәдәни һәйкәлләр тергезү, матди базаны ныгыту кебек матур эшләр белән баетылды. Без хәтта «Авыл клубы» проекты кысаларында Казанның Тынычлык бистәсендә дә Мәдәният йорты салып куйдык. Мәдәният белән әдәбият – игезәкләр. Әдәби әсәрләргә нигезләнеп кинофильмнар төшерелә, спектакльләр куела. Әдәбият көннәре, язучыларның әдәби сәфәрләре, ишегалды шигырь бәйрәмнәре, Республика районнарында үткәрелә торган Милли китапханә көннәре, китап ярминкәләре – болар барысы да әдәбиятны халыкка якынайтуга юнәлтелгән чаралар. Соңгы елларда республика җитәкчелегенең мәдәniяткә һәм каләм әһелләренә игътибары тагын да арта төште.

Әле бит бихисап юбилейлар да бар.

– Әйе, Каюм Насыйриның – 190, Таҗи Гыйззәтнең – 120, Шәйхи Маннурның – 110, Атилла Расихның – 100, Гариф Ахуновның – 90, Роберт Әхмәтҗановның 80 еллыклары! Әдип-драматург кына түгел, дәүләт эшлеклесе дә булган Туфан Миңнуллинның тууына да быел 80 ел! Әлеге даталар барысы да югары дәрәҗәдә уздырылачак: иҗади очрашулар, теле- һәм радиотапшырулар булыр. Китаплар нәшер ителер. Конкурс, фестивальләр үткәрелер. Һәйкәлләр дә куелыр...

Татарстан Милли китапханәсе дә 150 яшен билгеле дип беләбез.

– Китаплар гына түгел, Республикабызның мәдәни һәм фәнни



казанышларына мөнәсәбәтле документлар да саклана анда! Җәмгысы 3,2 миллион данәдән артык документ. Татар китабын һәм республикабыз турындагы әдәбиятны саклаучы дөньяда бердәнбер халык китапханәсе ул! Татарстанның төп китапханәсенең 150 еллык юбилеена багышланган чаралар, әлбәттә, барлык китапханәләрдә дә узачак. Ә октябрь аенда Милли китапханәбез юбилеена багышланган халыкара фәнни-гамәли конференциягә илебезнең китапханәләр җәмәгатьчелеге, чит ил кунаклары килер дип көтелә.

Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән берлектә, халыкның китаплар, басма матбугат укуы белән кызыксынып, сораштыру уздырган иде. «Сөембикә» журналының татар басмалары арасында иң яратып укылганы булуын белеп сөендек.

– Сүзне журналлар рейтингына анализлаудан башласак, лидерлыкны саклап кала һәм ныгыта алган «Сөембикә» журналы өчен мин дә сөенәм. Мониторинг-күзәтү нәтиҗәләренә тукталсак, әлеге басма соңгы җиде елда 6 тапкыр беренчелекне яулады. Китапханә укучылары арасында узган ел уздырылган сораштырулардан күренгәнчә, халыкның 34 проценты аны яраткан журналы дип атый (2004 ел белән чагыштырганда, 6 процентка күбрәк бу). Татар укучысы «Идел» журналын да үз итә, «Казан утлары» журналы да укучыларын саклый. Әлеге өч журнал – укучылар мәхәббәтен казанган басмалар. 2004 һәм 2014 елларда рейтинглар җәдвәлендә нәкъ менә алар беренче дистәдә.

Китапханәгә йөрүчеләр арасында сораштырулар шуны ачыклады: вакытлы матбугатны укучылар әдәби-нәфис язмаларга өстенлек бирә икән – очерклар, хикәяләр, шигырьләр яратып һәм теләп укыла.

Халык бүген укыса да, сай эчтәлекле, җиңел матбугатны гына теләп укый дигән фикер дә бар...

– Чыннан да, китап-журналны күңел юанычы өчен укыйлар. Бөтен даирәгә дә хас күренеш бу. Безнең китапханәчеләр проблеманы укучылар саны кимүдә түгел, приоритетлар үзгәрүдә күрә. Эшлекле, мәгълүмати-файдалы уку да бар. Бу китапханәчеләрнең эш тәҗрибәсендә дә, соңгы елларда Татарстан китапханәләре уздырган тикшеренүләрдә дә чагыла.

Файдалы әдәбиятка, нигездә, мәктәп, көллият укучылары, вуз студентлары үрелә. Алар укыган әдәбиятның яртысыннан күбесе уку йортында бирелгән биремнәргә бәйле. Бу төр укучылар китапханәләргә, гадәттә, биш елдан да озаграк йөрми, укуларын тәмамлауга, саубуллашалар. Бик азлары гына даими укучылар рәтендә кала. Илебездә китап укымаучы югары белемлеләрнең артуын ишарәләүче күрсәткеч бу.

Ә бит безнең халык гомер-гомергә зыялы, укымышлы, исемен йөрткән. Сөлгегә төрелгән китапның урыны түрдә булган. Кызганыч, китап кадере югала бара... Үзегез нәрсәләр укыйсыз?

– Бер заман телевидение барлыкка килгәч, китап дәвере бетәчәк, дигәннәр иде. «Гутенберг дәвере» узса да, китап яшәвен дәвам итә. Китап гомерен интернет белән бәйләү дә үзен акламас кебек. Барлык мәгълүмат каналларның берләшеп эшләве җәмгыятьтә укуга, китап уку әдәбен үстерүгә, иҗтимагый фикер формалаштыруга менә дигән мисал була ала, минемчә. Ф. Достоевскийның «Идиот», М. Булгаковның «Мастер и Маргарита», Д. Браунның «Код да Винчи» әсәрләре экранлаштырылганнан соң, укучыларның әлеге китапларны эзләп укый башлауларын күреп тордык! Мин үзем, мәсәлән, Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын кабат укый башладым, шул рәвешле премьерага әзерләнәм.


Уку культурасы гаиләдә тәрбияләнергә тиеш ул. Мин ул яктан бәхетле, әнием – китапханәче, мин китап киштәләре арасында үстем. Мөгаен, шуның тәэсиредер, улымны да 3 яшеннән үк атнага ике мәртәбә китапханәгә ияртеп йөри идем, хәзер ул «библиофил»га әйләнде.

Сүз дә юк, китапханәләр бүгенге көн укучысын җәлеп итәрлек булырга тиеш. Россия китапханәсе бүген яңарыш чорын кичерә. Эш алымнары алышына. Китапханә бүген, опера һәм балет театры кебек, югары технологияләргә бай урын булырга тиеш. Китапханәгә килеп кергән кешегә күптөрле һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтелсен, шул ук вакытта кеше үзен Мәдәният сараена килеп эләккәндәй хис итсен. Киләчәктә, һичшиксез, шулай булыр, без бу юнәлештә инде эш алып барабыз. Мәсәлән, Милли китапханәбез базасында, Казан шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 45 нче филиалында «Әдәби кафе» оештырылды. Хәзер бу эшкә Чирмешәннәр алынды.

Беләсезме, нәрсә сөендерә мине? Бүгенге гаять көчле мәгълүмати ташкынга эләккән кешеләр китапханәнең сыйфатлы әдәбиятны бушлай тәкъдим итүен һәм төпле киңәш бирә алуын, ниһаять, аңлый башладылар. Яки менә Милли электрон китапханәне алып карыйк. Интернет ярдәмендә хәзер (бездә китапханәләрнең зур күпчелеге интернет белән тәэмин ителгән, актив рәвештә Wi-Fi кертелә) Татарстанның иң ерак авылында яшәүчегә Татарстан Милли китапханәсе фондындагы сирәк һәм кыйммәтле китаплар да барып ирешәчәк. Бүген электрон хәзинәдә 3 меңнән артык документ исәпләнә. Ун ел элек Аксубай балалары Тукайның үзе исән чагында басылган китапларын кулга төшерү турында хыяллана алырлар иде микән? Ә бүген андый мөмкинлекләр бар.

Эшем шундый – яңа китаплар, китап дөньясы яңалыклары мине читләтеп узмый. Соңгы елларда миндә укуга яңа бер караш барлыкка килде – берьюлы берничә китап укыйм. Мәсәлән, бүген Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр», Федор Шаляпинның «Маска и душа» һәм Стефан Цвейгның «Исторические портреты» циклын укыйм. Көн саен укырга тырышам – һәм кәефемә карап йә Сафа белән Сәҗидә, яки Гөлшаһидә белән Мансур, яисә Стендаль геройлары янында калам...

Киң җәмәгатьчелек татарның олуг мәгърифәтчесе, галим Каюм Насыйриның 190 еллыгын билгеләп уза. Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын һәрьяклап өйрәнгән һәм туплаган галим-мәгърифәтче Каюм Насыйри – халыкны белемле итүдә, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерүдә зур эшләр башкарган шәхес. Аның «Кырык бакча», «Китап-әт-тәрбия», «Кабуснамә», «Әбугалисина кыйссасы» әсәрләре, фольклористикага, төбәк тарихына, татар этнографиясенә караган хезмәтләре бүген дә өстәл китабы булырлык.
Укучыларыбызга Каюм Насыйри туплаган йолаларыбызны шул чор телендә кыскартып тәкъдим итәбез.



ГОМЕР ТУЙЛАРЫ

Файдаланылган чыганак: Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 3 нче том. «Йолалар». 241–252 нче битләр.

Бала тумак

Инде бала туар вакыт җиткәч, бер карчык китерәләр. Аны кендек әбисе диләр. Ул әбинең ярдәме белән бала туа. Бала сәламәт тугач, аны бал-май белән авызландыралар. Биләүгә салалар. Туган көнне үк балага ат кушмыйлар, берничә көннән соң кушалар.

Балага ат кушмак

Бала тугач, берничә көннән соң балага ат кушмак өчен аш хәзерлиләр: бер көнне билгеләп, тиешле муллаларны вә карендәшләрне вә һәм тиешле кешеләрне, күршеләрне, мәхәлләнең чибәррәк кешеләрен чакыралар. Бу ашны бәби ашы яки бәби мае дип йөртәләр. Шул мәҗлескә тәмам халык җыелып җиткәч, баланы, бер мендәр өстенә салып, мулла алдына китереп куялар. Балага исем биргәндә, атасы-анасы үзләре кайсы исемне ихтыяр кыйлса, шул исем белән мулла ат куша. Инде бу заманда күбрәк кеше исемнәре гарәпчә була. Моннан соң мулла, баланың аякларын кыйблага таба куеп вә һәм баланың баш очында аягүрә торып, аның уң ягында азан әйтә вә һәм сул ягында торып камәт (намаз алдыннан аягүрә укыла торган дога – *ред.*) әйтә, аннан соң баланың йөзенә иелеп, кычкырыбрак әйтә «исме шәрифең фәлән булсын» дип, өч мәртәбә. Моннан соң фатыйха укып, дога кыйлып, баланы алып китәләр. Аннан соң бал-май китерәләр. Һәркем мәҗлестәге кеше үзе теләгәнчә бал-майдан кабып, һәркем хәле кадәренчә акча салалар.

Бишек туе

Балага ат кушкач, аны бишеккә салалар. Әүвәл мәртәбә баланы бишеккә салганда бер мәҗлес буладыр – хатыннар мәҗлесе. Моны бишек туе да дип әйтәләр. Бу мәҗлескә хатыннар җыела. Һәркайсы хатын хәле кадәренчә акчадан яки гайре заттан бүләк алып киләләр.

Гакыйка корбаны

Вә дәхи шәригатьтә сөннәт булган бер гадәт бар: бала тугач, җиде көннән соң бер корбан чалалар. Моны гакыйка (яңа туган балага чыга башлаган чәч, төк – *ред.*) корбаны дип әйтәләр. Ул корбанның тиресен

садака итеп бирәләр; итен һәм яртысын садака бирәләр тиешле кешеләргә һәм әбигә. Ул корбанның сөякләрен бер дә ватмыйлар, җекләреннән генә кисәләр. Корбанның бер ботын кендек әбисенә бирмәк кирәк, калганын садака бирмәк кирәк. Әмма ул гакыйка корбаны ир бала өчен ике куй, кыз бала өчен бер куй чалмак тиеш. Бала тугач, берничә көннән соң баланың чәчен китәреп, шул чәч авырлыгы алтын яки көмеш садака бирәләр.

Сөннәткә утыртмак

Вә дәхи кайсы кеше, бала тугач, җиденче көндә сөннәткә утырталар. Әмма шәригатьтә җиденче көннән егерме яшенә чаклы мөмкин, мөстәхәб (яхшы табылган эш – *ред.*). Бу сөннәткә утыртучыны баба дип әйтәләр. Аңа бабалык атадан-бабадан кала килгән булмак кирәк, нәсел буенча. Баба кисә, кечкенә баланы алдына утыртып. Баланың күзен каплый. Бала еглаclаса, аны көйләп: «Егълама, углым, сиңа кызыл ыштан бирәм, тукта, сиңа ыштан үлчим», – дип, ул арада гамәлен кыйла.

Кыз яучылатмак

Кыз-хатын арасында бертөрле карчыклар бар, кемдә өйләнәсе егет бар, һәркайсының өйләренә кереп иснәнеп йөри: кемгә кыз кирәк, кемнең кыз бирәсе килә. Әгәр берәүнең өйләнергә нияте барын сизсә, кызлы кешегә барып, бик кечкенә генә сүз сала. Әгәр бирергә ниятләре барын сизсә, янә шул өйләнәсе егеткә барып җитештерә, егетнең атасына-анасына, яки гайре башка карендәшләренә, яки егетнең үзенә. Аннан соң егетнең атасы шул кызның атасына яучы җибәрә кызын сорап. Әмма күбрәк кызның атасы-анасы яучыны егетнең атасына җибәрә ишарәт белән аңлатып, әгәр кызымны сорасалар, бирер идем, дип.

Яучы дигәннәре ике өйнең арасында байтак көннәр йөреп ике коданы килештерәдер, мөмкин кадәр берсенберсенә мактап. Аннан соң вәгъдәләшеп, берничә микъдар мәһәр салып, кызны килешкәч, колак сөенчесе бирәләр, вә һәм туй шартларын шунда сөйләшәләр, ягъни мәһәр күпме, бирнә күпме, егет ягыннан кызганиләр биреләсе, кыз ягыннан егеткә ниләр биреләсе, вә һәм егет ягындагы кардәшләргә, кем-кемгә бирнә бирәсе, һәммәсен шунда тәгаен кыйлалар.

Аннан соң бер кечкенә генә мәҗлес ясап вә һәм имамны чакырып иҗабы кабул (өйләнешүчеләрнең үзара ризалыгы – *ред.*) итәләр. Әмма бу никях мәҗлесе түгел. Бу иҗаб кабул мәҗлесеннән соң туй мәҗлесенә чаклы туйга хәзерләнеп берничә көн уза. Туйның кирәгенярагын хәзерләп бетергәч, туй буласы көннең алдыннан бер көн мөкаддәм өндәү чыгаралар яки записка тараталар. «Фәлән-фәлән углы үтенә фәләненче числода, фәләненче сәгатьтә никях мәҗлесенә рәхим итәсез...»

Иҗаб кабул мәҗлесе үткәч, берничә көннән туй мәҗлесе буладыр. Туй булмастан борын, егет өендә бер мәҗлес буладыр: хатыннар мәҗлесе. Ул мәҗлескә хатыннар җыелалар, кызга биреләсе бүләкләрне карыйлар. Һәрбер хатын үзенең хәленә күрә ул мәҗлескә бер зат яки акча алып киләдер; кызга биреләсе күлмәкне котлап салалар ситсадан, ефәк затыннан, акчадан. Бу мәҗлестә җыелган нәрсәләр һәммәсе кызга китә.

Туй мәҗлесе

Никяхны кыз өендә укыйлар. Никях буласы көн туй алдыннан бераз элгәре егет өеннән кыз өенә берничә төрле нәрсәләр җибәрелә. Бу көнне кызга җибәрәләр бүләк һәм мәһәргә хисап бер яхшы сандык, яхшы зур көзге, яхшы штуф яки хәтфә, берничә күлмәклек ефәк материя, берничә күлмәклек ситса, шәл, яхшы калпак, читек, башмак вә һәм разный фрукта вә һәм бүләкләр өчен йөзекләр, пәкеләр, вак көзгеләр вә иннек-кершән, вә һәм мәһәргә тәгаен кыйлынган акчаны шул сандыкка салып бикләп җибәрәләр. Вә дәхи җибәрәләр берничә первый сорт күмәч, ярты пот бал, ярты пот май, һәркемнең хәленә һәм мәҗлесенә күрә.

Бистә халкы арасында, егетнең тәүфыйгы вә һәм һөнәре яхшы күренсә, мондый егеткә һәркем үзенең кызын бирәсе килеп тора.

Инде егет өендә туйга барырга дип дәхи берничә кешеләр җыела. Мәҗлес була. Егет ягыннан кода булып баралар кыз өенә; һәм бу туйга барасы кодаларга егет өендә берәр төрле аш була. Кыз өенә туйга барасылар әүвәле егет өенә җыела, байтак була, мәҗлесенә күрә. Кыз өендә һәм егет өендә халык җыелып җиткәч, егет өеннән барасы кодаларны алмага кыз ягыннан атлар килә. Кодаларны алмага килгәч, берничә төрле ашны тәнавел кыйлып (авыз итеп – *ред.*) дога кыйлып, шул атларга утырып кыз өенә китәләр. Кайсы кеше үз аты белән бара.

Моннан барган кодаларны кыз өенә кабул итәләр: «Хуш киләсез, кодалар!» – дип каршы чыгып торалар. Хәзерләнгән урыннарның яхшырагына егет ягыннан килгән кодаларны утырталар. Халык җыелып тәмам урнашып беткәч, бер догаи фатыйха кыйлалар. Урта гына хәлле кешеләрнең туйларында ун-унбиш табын кеше була. Муллаларны вә голяма җәмәгатен үз алдына бер табын итеп утырталар. Әмма кияүнең атасы яки вәлие (вәкиле – *ред.*) шул муллалар табынында була. Кияүнең атасын һәм кызның атасын төп кода дип әйтәләр. Шул ике кода муллалар табынында була. Моннан соң мулла кызның атасын яки вәлиен чакырып сорый: кызы ничә яшьтә, ни исемле, мәһәр күпме, кызы ризамы, һәм шәригатьчә шулай кирәк. Мулла шәригатьчә бу хосуста кызның атасын яки вәлиен җибәрә кыз катына, ике кеше гуаһ (шаһит – *ред.*) кушып, кыздан ризалык сорарга. Шул ике гуаһ белән кызның атасы сорый кызыннан: «Кызым, сине фәлән кешегә бирәм, син ризадыр?» Кызы җавап бирә: «Риза». Ул ике гуаһ ишетеп тора (шәригатьчә шулай тиеш). Әмма мәһәрнең билгеле хисабы юк, һәркемнең хәле

кадəренчə. Мəһəр салынадыр йөз тəңкə, ике йөз тəңкə, өч йөз тəңкə һəм моннан артык та була, хəтта биш меңгə чаклы. Мулла, бу эшлəрне сорашып бетергəч, никях укый, кычкырып, гарəпчə гыйбадəт белəн. Никях мəҗлесендə кияү буласы кеше булмый. Əгəр карт кеше булса, никях мəҗлесенə үзе бара, гаеп итмилəр.

Кияү ягыннан ата булып утырган кешегə мəҗлестə бер мендəр бирəлəр штуфтан, яки бер гайре төрле кыйбатлы материядəн, яки яхшы ситсадан, мамыктан. Əмма бу никях мəҗлесендə ата булып утырырга кызның һəм кияүнең атасы булырга тиеш. Инде əгəр аталары булмаса, ага-энесе ата булып утыра...

Туй мəҗлесендə туй ашы ун-унбиш төрле була. Əүвəле бал-май китерəлəр, аннан соң гадəти ашларны: пылау, гөбəдия, бəлеш, бөккəн яки пилмəн, үрдəк бөккəне (əмма туй мəҗлесендə бөккəн төбен кисмəк юк, хəтта гаеп итəлəр)... Һəркем хəле кадəренчə бераз котлап, подноска акча салып җибəрə. Əмма муллалар вə голяма җəмəгатенə, фəкыйрь-фөкарəгə һəр ике яктан акча өлəшəлəр. Байларда бу туй өч көнгə чаклы була.

Кыз өенə барган кодалар, кечерəк кенə туй булса да, ун-унбиш ат була.

Бүлəк багу

Бу туйдан соң һəм туй мəҗлеслəре тəмам булгач, кияү кыз катына бармас борын, кыз өендə дəхи хатыннар мəҗлесе була. Моны бүлəк багу мəҗлесе дилəр. Хатыннар кызга кияү ягыннан килгəн нəрсəлəрне карыйлар. Хəллəренə күрə, котлап бер нəрсə салалар, бүлəк: күлмəклек ситса, материя, əдрəс вə һəм акча вə гайре заттан.

Кыз куенына кермəк

Бу мəҗлеслəр тəмам булганнан соң, кияү кыз куенына керəдер. Бу сүзнең мəгънəсе шул: мөселман татарларының гадəтенчə, кияү булган кеше кыз катына бара, кызның өенə. Егет үзенең яхшы киемнəрен киеп яки бөтенлəй баштанаяк яңа кием тектереп кия. Такыя, казаки, чикмəн, тун, читек, кəвеш – бары да яңа, бүрек яңа. Гадəттə, кияүлəр кыз катына баралар əүвəле мəртəбə кече җомга кич яки дүшəмбе кич.

Кичлəрдəн бер кичне билгелəп, фəлəн кич кияү рəхим итсен, дип, кыз тарафыннан егеткə өндəүче килə. Егетнең дус-ише, агай-энесе җыелалар, кияүне кыз куенына озатып җибəрергə. Лəкин кияү үзенең өеннəн үзенең аты белəн бармый. Кыз ягыннан килеп алалар кияүне бик зур тəкəллефлəр белəн, пар ат белəн, һəйбəт экипажлар белəн.

Кияү кертмəк

Инде бу кыз тарафында бик нəфис итеп кияүне кунак итəр өчен бер бүлмəне хəзерлилəр, бик нəфис итеп җыялар, һəрбер өстəлгə көмеш шəмдəллəр белəн икешəр шəм яндырып куялар, өйне һəйбəт нəфис хуш ис белəн ислəндерəлəр. Шулкадəр нəфис итеп җыялар, кисəктəн барып керсəң, оҗмах микəн диярсең.

Кич булгач, кияүне алмага җибəрəлəр. Кияү өчен хəзерлəнгəн кыз бүлмəсенең ишеге төбендə бер-ике бала тора. Бу балалар монда тормакны ишек бавы басмак дип əйтəлəр. Кияү булып килгəн егет ул балаларга акча бирə, хəленə күрə. Ул кияү яучы хатын белəн анда керə. Кияү белəн кыз күрешə дə, кызның кулына акча сала, моны күренеш, дилəр. Бирелгəн акчаны яки затны күренеш акчасы диерлəр. Аннан соң кияү белəн кызга аш китерəлəр. Əүвəле бергə утырып ашыйлар. Анда икесеннəн башка кеше булмый. Иң əүвəле бал-май китерəлəр. Кияү бал-май табагына акча салып җибəрə. Аннан соң ашны ашап, чəй эчеп булгач, кияү белəн кыз, бераз утыралармы-юкмы, ятарга хəзерлəнəлəр...

Иртə белəн кияү өчен мунча ягалар. Кияү кыз белəн мунчага китə. Түшəккə янə акча салып китə; моны түшəк акчасы дип əйтəлəр. Ул акча түшəк җəючелəргə була. Кияү мунчадан чыкканда мунчага акча калдырып чыга; моны мунча акчасы дип əйтəлəр. Бу акча мунча ягучыга була. Кияү, шул рəвешчə, кыз катына əүвəле мəртəбə кергəндə дүрт кич куна тоташ... Атасына-анасына күрешергə кайтканда, кыз катыннан алып кайта əүвəле үзенə бүлəк: яхшы такыя, сəгать, яхшы чикмəн, күлмəк-ыштан, аякчулар яхшы бүздəн чигеп ясаган. Бу нəрсəлəрне тəмам баштанаяк киенеп кайта. Вə дəхи кияүнең ата-анасына һəм агай-энесенə, кардəшлəренə бирнə; бу бирнə дигəннəре кыз ягыннан бирелə торган бүлəктер. Ул кыз ягыннан бирелə торган нəрсəлəр барчасы күлмəк була: хатын-кызга булса, яхшы ситсадан яки ефəк материядəн, ирлəргə һəм күлмəк яхшы бүздəн, ситсадан, полотнодан вə дəхи карчыграк хатыннарга өрпəк бирəлəр. Вə һəм кияү кыз катыннан как-төш алып кайта. Как-төш дигəннəре шулдыр: миндаль төшен шикəр белəн, бал белəн катырып, бер подноска ясыйлар, өстенə төрле конфет сибəлəр, аның өстенə как җəеп, бер подноска куеп җибəрəлəр. Уртарак хəлле кешелəр как-төшне камырдан ясыйлар: бавырсакны бал белəн катыралар.

Кияү кыз катына кереп чыккач, дус-ишен, күршеколанын, мəхəллə халкын һəм муллаларны җыеп, бер мəҗлес ясый. Бу мəҗлесне как-төш мəҗлесе дип əйтəлəр.

Килен төшермəк

...Байтак кияүлəп йөргəч, кияү кызны үзенең өенə бөтенлəй алып килə. Моны килен төшерү дилəр. Егет өендə килен төшергəн җиргə дип мəҗлес ясыйлар – хатыннар мəҗлесе. Килен төшергəндə кыз артыннан байтак нəрсəлəр килə; мамык түшəк, мамык ястык, дүрт муен мендəре, яхшы ситса яки ефəк юрган, чыбылдык, чаршау, кызның үзенə тиешле затлар, самовар, ике комган, җиз лəгəн, зур ике поднос, ике дюжина чынаяк, бал кашыгы көмештəн, берничə эскəтер, берничə сөлге. Кыз үзенə тиешле нəрсəлəрне атасының өендə бер дə калдырмый...



АВЫЛ КЫЗЛАРЫ МАТУР!

«Авыл кызы». Яшь буында милли гореф-гадәтләрне, татар халкының мәдәни хәзинәләрен саклауны максат итеп оештырылган Бөтенроссия конкурсы әнә шулай атала. Менә берничә ел инде Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Бөтенроссия татар авыллары оешмасы һәм «Сөембикә» журналы әнә шул затлы исемгә лаек булырдай кызларны барлый, сайлый, үстерә. Күптән түгел II Бөтенроссия конкурсының финалына илебезнең төрле төбәкләреннән сылу һәм сөйкемле, уңган һәм чая, заманча һәм милли җанлы чын татар кызлары Казанга җыелды. Араларында – этник тамырларын җуймыйча, мәдәни мирасны бүгенге заманга бәйли белгән студентлар, авылда яшәүче яшь белгечләр: мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар, табибләр, авыл хуҗалыгы белгечләре. Татар хатын-кызларына хас иң күркәм сыйфатларны туплаган ул кызлар инде зона турларында җиңеп чыккан!

Менә алар – ерак аралар узып, мәркәзебезгә имтихан тотарга килгән асыл затларыбыз, татар халкының генофондын тәшкил итәрдәй уңганбулган сеңелләребез – Кәрим Тинчурин исемендәге театр сәхнәсен бизәп басып тора!

Җырлы-биюле музыкаль кичәдә финалист кызлар авылларына кагылышлы чыгышлар ясады, үзләре чиккән кулъяулыклар белән жюрины сокландырды. Җыр-биюгә дә, аш-су әзерләүгә дә оста икән үзләре!

Ниһаять, җиңүчеләр билгеле! Рузилә Мингулова (Оренбург өлкәсе Әсәкәй районы Яңа Солтангол авылы), Гөлшат Әхмәдиева (Свердловск өлкәсе Түбән Серга районы Уфа Шөгере авылы), Динара Хәбибуллаева (Әстерхан өлкәсе Нариман районы Бишттүбә авылы), Резеда Абайдуллина (Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районы Зарыклы авылы), Эльвира Ваһапова (Пенза өлкәсе Неверкин районы Сарбай авылы) – «Авыл кызы» II Бөтенроссия конкурсы финалында җиңүче дипломнары; Лилия Юнисова (Түбән Новгород өлкәсе Сергач районы Кочка Пожарки авылы) – III дәрәҗә, Рәзилә Серениева (Чуашстанның Комсомол районы Урмай авылы) II дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнде. Ульяновск өлкәсе Чынлы районы Кәшә авылыннан килгән Лилия Кәримованың чыгышы I дәрәҗә диплом белән бәяләнде һәм аңа «Сөембикә» журналының махсус призы – модельер Альмира Борһановадан затлы милли жилет тапшырылды. Башкортстанның Илеш районы Исәмәт авылы кызы Эльвира Рәкыйпова Гран-при иясе булды! Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров аңа затлы кыска тун, конкурс сыны, диплом тапшырды. «Алмаз-холдинг» ҖЧҖнең «Алмаз» зәркән заводы, «Пестречинка» ҖЧҖ, «АльРезе» тәмтомнар цехы, Чуашстанның «Жизнь» агрофирмасы әзерләгән бүләкләр кызлар кулына күчте.

Бәйге финалыннан фоторепортажны «Сөембикә» журналы сайтыннан карарга мөмкин.



АВЫЛДА БЕЗНЕҢ ИНӘЙНЕ – КАЙНАНАМНЫ – «СӘРСӘН МАҺИНУР» ДИП ЙӨРТӘЛӘР.

Юк, аның холкы орды-бәрде, җил-зәбәр булган өчен түгел. Аның холкы хәзерге заман кайнаналарының күпчелегендә җитенкерәми, һәм шуның аркасында гаилә эчендәге өлкәннәр белән яшьләр арасында татулык урнаша алмый.





Клара БУЛАТОВА

СӘРСӘН МАҺИНУР

«Сәрсән» кушаматын аңа яшьтән үк җилдәй җитез, өлгер, тынгысыз булган өчен биргәннәр. Чынлап та, бер гаиләдә яшәп, минем әле инәйнең ялгыш та бер тик утырып торганын күргәнем булмады. Без аның белән биана белән килен кебек түгел, ә ике ахирәт – ике дус хатын булып яшәдек. Баштан ук, беренче көннән үк шулай башланды! Без өйләнешкән елларда әле әти дә исән, өйдә ике җитү кыз да бар, шуңа күрә без Әлмәттә үз фатирыбызда, ә әти-әниләр Нәдер авылында тора иде. Әмма мин, юл өстендә булгач, Кәшердән кайтышлый гел Нәдергә сугылам, инәй белән көн саен булмаса да, көн аралаш күрешеп тора идем. Инәй инде колхоз эшенә йөрми, шулай да таңнан торып әтине фермага, кызларның берсен иртәнге вахта белән Мактамага заводка, икенчесен Кәшер урта мәктәбенә укырга озата... Сыерын сава, өен җыештыра, иртән алын, көндез яшелен киеп дигәндәй, өстен алышып, йөгереп кенә чакрым ярымдагы кибеттән урап кайта... Нәдернең Мактама очында яшәүче кайнанасы Миңлегаян әби белән кайнатасы Гариф бабайның хәлен белеп төшә һәм тәкә-мөкәсен пешереп, минем Кәшердән укытып кайтуымны көтеп тора... Әйе, нәкъ шулай: көтеп тора! Мин бүләк итеп алып кайткан тукымадан үзе теккән ал алъяпкычын бәйләгән дә тыкрыкка караган тәрәзә янына баскан булыр.

Көлтә-көлтә дәфтәр тутырылган, инәй әйтмешли, буаз тана кадәр сумкасын сүрәп кайтучы «җирдән дә күренми торган» киленен олы урамнан Күл буе тыкрыгына борылу белән күреп-танып алган Сәрсән Маһинур җәлт кенә алгы якка чыга да чәен куеп җибәрә. Морҗа буена тазын-комганын, җылы суын, чиста сөлгесен әзерләп куя. Өйне тәмле таба ашы исе тутыра. Ашап-эчеп алгач, килен (ягъни мин инде, әмма инәй авызыннан «килен» дигән сүзне ишеткәнем юк минем, ул мине гомер буе «Кларакаем» дип кенә йөртте): «Кая, инәй, суга барып килимме? Ни-нәрсә эшлисе бар?» – дигән булам. (Яхшы атланам, янәсе!) «Куй, булмаганны! Син бит эштән кайткан. Бер эшем дә юк, ел озынлыгы көндә өйдә яткан кешенең үзенә дә эш җитми әле монда. Үз эшеңне кара, әнә бит сумкаң тагын бүселгән». И рәхмәт яугыры! Мин инде сөенә-сөенә эчке якка кереп өстәл башына утырам. Мал-туар асрап, хуҗалыкта эш беткәнме? Инәй инде ишегалдында тегесен – тегеләй, монысын болай итеп эшләп йөри, кергән-чыккан арада ишек пыяласы аша мине карап ала, тикшерелгән дәфтәрләрне мин яңадан сумкага сала башлагач: «Беттеме әллә? Бетсә, әйдә аулаклап кына чәй эчеп алыйк атаң кайтканчы. Бер-ике җыр да җырлап бирермен үзеңә», – дияр иде.

«Кызым, сиңа әйтәм! Киленем, син тыңла». Анастасия Бузенеева эше.

Инәй җыр ярата. Мин моңа кадәр беркайда да ишетмәгән, укымаган әллә никадәр җыр белә иде ул. Колшәриптә кукуруз басуларында ат атланып йөргәндә үзем язган шигырьләрне искә алмаганда, гомергә бер җырлап карамаган башым белән мин дә инәйгә кушылып рәхәтләнеп җырлап утырам: Алъяпкычыңның чигеше / Кемнәрнең күчергече? / Тату гына гомер итик / Адәмнәр көлдермичә.

Иллә дә рәхәт шундый вакытларда! Әти кайтыр минут җитүгә инәй кулындагы бәйләвен (җырлаганда ул оекбашмы, бияләй-мазармы бәйли, мин яулык читеме шунда, тастымалмы чигеп-бөгеп маташам) тиз генә шкаф башына ата да үзе канат ала, миңа себерке тоттыра: «Кларакаем, бар капка төбенә, кайтты теге җен, холкы холык кынамы, дулый башласа...»

Мин себерке тотып ишек төбендә йөргән булам. Капка ачып әтине кертәм. «Ни хәлләр, әти? Исән-сау гына кайттыңмы? Теге байталың рәтләндеме соң? Фураж ягы ничек?»

Әтинең кәефе яхшы булсын дисәң, аның белән атлары турында, элеккеге председатель Һади абый Рахманов турында, аннан соң инде Нәфискә фәлән вакыттан соң тагын бер йолдыз өстәлү ихтималы һәм Марсның бөтен кешегә: «Мин – Мавс, бабай Бвот-Хавис», – дип йөрүе турында сөйләшергә кирәк. Һәм мин шулай эшлим дә. Ә болай эшләргә, әлбәттә, инәй, әлеге дә баягы Сәрсән Маһинур өйрәтә. Әйтергә кирәк, мин, мәсәлән, «холкы холык кынамы» дип йөртелгән Брот Харисның дулаганын күрмәдем. Әти белән дә бик дус идек без.

Брот Харис, дигәннән... Әтинең ул кушаматы кайдан килгәндер, нәрсә аңлатадыр – анык кына әйтүче булмады. Шулай да инәй аны Ленинградтан ияреп кайткан сүз дип сөйли. Алар сугышка кадәр икесе дә Ленинградта кирпеч заводында эшләгән булганнар. «Гербаушикка язылып китү белән тапкан адәмем инде атагыз. Бөгелмәдә фатир төшкәч үк, юк йомышын бар итеп, янга килгән иде. «Кая, менә бияләемнең бер бармагы сүтелеп китәргә маташа, ләктереп бир әле, кыз», – дигән була. Инде Ленинградта эшли башлагач, тагын юасы әйберләрен дә безнең баракка китергәләп йөрде. Аннан, авылга кайткач, ат җигеп килеп алды Сөләйдән. Кырыгынчы елның башында килен булып төшкән идем, менә, торып маташабыз шуннан бирле кырык ел...»

Әтине җирләгәннең соңында да инәй әле ун елдан артык авылда яшәде. Алты баласы алты якта үз тормышы белән, һәркайсының бала-чагасы, эш-хезмәте... Алай да инәйнең балалары да, аларның «ияргәннәре дә» (бусы да инәй сүзе) инәй яшәгән Нәдер нигезенә «тузан төшермәделәр». Без барыбыз да бергә шунда җыелып, язын бәрәңге утыртабыз, җәен утыйбыз, өябез, көзен алабыз. Сәрсән Маһинурның «Илләҗан явы» кадәр токымы кайтып җыелган көннәрдә безнең урам гөж килеп тора! Нәсел-ыруның әнә шундый бердәмлеге минем өчен бик кадерле. Мин үзем дә биш баланың берсе булып үстем. Ишле балалы гаиләдә кеше ничектер җанлыклы, игелекле булып үсә. Без, менә шуңа күрәдер, һәр ике як белән гел күрешеп, йөрешеп, ярдәмләшеп яшибез. Туганнарыбыз арасында да мөнәсәбәтләр гадәти кода-кодачаларча гына түгел, кан-кардәшләрчә тыгызрак, җылырак дияр идем мин.

Монда да тагын инәйгә кайтам: шушы якынлыкның туганлык тоткасы һаман да аналарга килеп тоташа. Инәй бездә торды. Безнең белән бергә Әлмәттә яшәде. Яше олыгайганда да Сәрсән Маһинур өлгер, җитез, булдыклы һәм кешелекле булып кала бирде. Мин эштән кайтуга чәен куеп, бәрәңгесен пешереп торды, улыбызны карады. Кодагыен (анысы минем әни була инде) көйли-тәрбияли (вакыт-вакыт аларга бергә бер бүлмәдә дә яшәргә туры килде), кодагыеның бөтен балаларын җыеп кунак итә, хәтта аның оныкларының балаларына ни дә булса бәйләп кигерергә өлгерә иде.

«Бәхет башы – җәмәгать» дигән сүзне инәй еш кабатлый. Улларына ул: «Киленем әйбәт», ә кызларына: «Киявем әйбәт», – дип туглап тора.

Инәй киленнәре турында һәрвакыт һәркайда гел уңай яктан сөйләде, тормышының кайбер кытыршы якларын «күрми» дә яши белде, ә кирәк чакта кайбер нәрсәне күтәреп-үстереп тә күрсәтә торган иде. Без үзебез дә әле һаман көлеп искә алабыз: шулай бервакыт ялга каршы көнне инәй мунча ягып йөри икән (дөрес, суын Нәфис белән икәү ташыган идек). Мин, үзе әйтмешли, аның янында «пытан-пытан киләм». Күрше Фәүзия апа килеп керде. Инәй тиз генә кулындагы йомычкаларын миңа төртте дә: «Ярар, шулай ит шул. Ыһы, ягып җибәр соң алай дисәң, була торсын», – дигән булып, мине мунчага таба этәрде. Мунчаны килен яга, янәсе! Ә минем, кулымдагы йомычкаларны учлап, мунча алдында инәй килеп ягып җибәргәнне көтеп утыруымны авыл кайдан белсен! Күрше хатыны «укымышлы уңган килен»нең мунча ягып йөрүен үз күзләре белән күреп чыкты бит!

Инде яшьрәкләрнең кайберсе кайниш-кайнана дигән кешеләрдән җиксенү-мазар сиздерә калса, инәй: «Бер кияү дә инкубаторда үсмәгән, аналар табып үстергән бит аларны да», – дип аңлатып җибәрә. Балалары исән-сау булып торып та, олыгайган көннәрен картлар йортында үткәрергә дучар кешеләрне инәй бик кызгана һәм гаҗәпләнә: «Ничек алай булырга мөмкин?»

Дөрес, бик киеренке чорда яшибез. Сәгатькә-минутка бүлгәләнгән эш көне, сәгать шалтыравы белән өзелгән таң йокылары, планнар, отчетлар белән тулган баш авыртулары, вакытында ашамау нәтиҗәсендәге эчке авырулар, тәгәрмәч өстендә дистәләрчә чакрымнарга текелдәп эшкә йөрүләр – болар барысы да кешенең психикасын талкый, нервыларны теткәли торгандыр! Әмма нәкъ шуларны оныттыра, бушата, җанны-тәнне ял иттерә торган – өй җылысы тулы, шифалы булсын өчен «бәхет башы – җәмәгать» икәнлеген искәртептөшендереп, гаилә нигезен тотып-саклап яши белүче Инәйләр кирәк икән!

Казанлылар өчен иң кадерле урыннарның берсе булган Черек күл бакчасы Казан шәһәренең үзәгендә урнашкан. Чернышевский, Дзержинский, Лобачевский урамнары белән чиктәш бу бакча элеккеге Черек күл һәм Мунча күле урыннарын биләп тора.
Элегрәк заманнарда күл буенда морзаларның һәм гади халыкның мунчалары тезелеп киткән, бар юынтык су шунда ага торган булган. Сабынлы судан күлнең суы бозылып, авыр исләр аңкытып торган. «Черек күл» дип аталуы да әнә шуннан.
Бакчаның барлыкка килү тарихы исә XIX гасыр башына барып тоташа. 1829 елда күлнең ярлары нығытыла, агачлар утыртыла.












1840 елда Казан губернаторы С. П. Шипов кушуы буенча Мунча күле күмелеп, аның урынында җәмәгатьчелек бакчасы булдырыла,
Никитиннар циркы төзелә.
Кайчандыр бу бакча бөек рус язучысы Л. Н. Толстойның да иң яраткан урыннарының берсе булган. Университетта укыган елларында ул монда бик еш ял иткән. Бу хакта язучының көндәлегендәге юллар да сөйли: «Берсендә шулай Черек күлдә утырам – имтиханнарга әзерләнәм, катехизисны ятлыйм һәм кинәт кенә зиһенем ачылып китеп, боларның барысы да ялган булуына төшенәм».
1847 елда Черек күл территориясе хәзерге көнгәчә сакланып калган чуен рәшәткәләр белән әйләндереп алына.






ЧЕРЕК КҮЛ БАКЧАСЫ



1889–1891 елларда Черек күл дә күмелә. Бакча уртасындагы түгәрәк мәйданда фонтан эшли башлый. Паркта Ожегов рестораны, А.П. Вяткина фотосалоны, купец Кваснинның үсемлекләр һәм орлыклар сата торган кибете, тир, бильярд, кегельбан, кышын
газ фонарьлары белән яктыртылган туләүле шугалак эшли. Бакчага төп керү капкасы Лобачевский урамы ягыннан була. 1890 елда Черек күл бакчасында Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсе павильоннары ачыла.
1925 елда монда туплы хоккей уйный башлыйлар. Казан «Динамо» хоккей клубының тарихы шул елдан башланып китә. 1930 елда парктан Лобачевский урамына чыгу юлында «Гашыйклар капкасы» куела. 1940 елда бакча Бауман районының Балалар бакчасы итеп үзгәртелә. Биредә волейболчылар өчен күнегүләр мәйданы, балалар мәйданчыгы, су коену, бәйрәмнәр оештыру урыннары булдырыла.



Хәзерге вакытта Черек күл бакчасы – казанлыларның һәм шәһәребез кунакларының яраткан ял итү урыны. Яшьләрне ул очрашу, танышу, кавышу мәйданы буларак үзенә тартып тора. Монда балалар өчен бәйрәм чаралары уздырыла, һәр ел Яңа ел чыршысы бизәлә, шугалак эшли.
Чыршы, юкә, каен, миләш, имән агачлары ял итүчеләрнең күзен иркәләп, яз һәм җәй көннәрендә рәхәт җиләслек биреп тора. Болардан тыш, монда әле безнең тирәлек өчен ят булган себер карагае, савыр (туя), чәнечкеле чыршылар да үсә. Шәһәр үзәгендәге бу яшел утраучык киләчәктә тагын да матураер, шәһәребез халкын һәрвакыт үзенә җәлеп итеп торыр.

Сәхифәне Татарстан Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.
Фотолар: Татарстан Республикасының
Милли музей фондыннан.



Чәчкә ЗАҺИРОВА

ПАРТИЗАН КЫЗ ЧӘЧКӘ

(Ахыры. Башы 3 нче санда.)

...Шулай итеп урман юлыннан барам. Бер заман урман бетте. Мин әле урманнан чыкмаган килеш кенә күзәтәм. Каршыда яңа йортлар күренә. Аларны саныйм. Бу бистәдә кешеләр яшәми бугай дип, шул якка таба атлыйм. Кинәт куаклыктан кулларына автомат тоткан өч таза немец аерылды. «Хальт!» И яратмыйм шушы сүзне. Мин катып калдым. Якын килделәр, тентеделәр. «Геге, марш!» – алып киттеләр. Берсе алдан, икенчесе арттан бара. Үзара сөйләшәләр. Тиздән алар мине бистәдәге иң зур йортка алып килделәр. Баскычтан менеп, озын коридор буйлап киттек, бер олы бүлмәгә кердек. Өстәл янында майор утыра. Озатучыларым китте. Диварда Мәскәү өлкәсенең картасы эленеп тора. Мине картага аркан утырттылар, өстәлгә җәелгән картаны да җыеп куйдылар. Майор миннән немецча беләсеңме дип сорады. Юк, дидем. Ул икенче офицерга дольмейчер (тылмач) чакырырга кушты.

Тиздән бүлмәгә урта яшьләрдәге таза гына ир-ат килеп керде. Майор аңа утырырга кушты. Миннән сорау алу башланды. Бик озак тоелды бу миңа. Җавапларымны яза бардылар. Гәрчә сораулар гади тоелсалар да, майорның тавышында усаллык сизелә иде. Әмма тәрҗемәченең тыныч, ипле сөйләшүе беркадәр тынычландыра төште. Мин аларга үземнең часть штабында ук уйланылган әкиятемне сөйләп бирдем. Бу әкияттә дөресе белән ялганы аралаш иде. Мәскәү авиация институты студентымын, сентябрь аенда ук Смоленск тирәсенә окоп казырга барган идек, дидем. Ниндидер авылның исемен атадым. Менә бер айлап инде кире кайтып барам, Мәскәүгә булмаса, Истрага – апам янына кайтып җитә алсам иде дип мескенләнәм.

Сорау алу бер сәгатьләп барды. Ул, мөгаен, исем-фамилиямне ачыклаудан башлангандыр. Мин үземне Маргарита Григорьевна Захарова дип атадым. Милләтем рус дидем. Безнең часть командиры Спрогис, милләтегезне әйтмәгез, яһүдләрне шунда ук аталар, татарларны хезмәттәшлек итәргә үгетлиләр, дип кисәткән иде. Сорау алуның уртасындарак майор мине партизан түгелме икән дигән шик белдерде. «Һич тә охшамаган», – дип, тылмач аны тынычландырды. Аннары, бу кыз яһүдә түгел микән дип, линейкалар алып үлчи, тикшерә башладылар. Тикшерүләр тәмамлангач, мине штабта эшләтергә дигән карарга килделәр. «Обер-лейтенант Гюнтерга илтеп тапшырыгыз», – дигән сүз чыккач, тылмач белән мине

чыгарып җибәрделәр. Әкрен генә барабыз. Кинәт тылмач туктап калды. Үзенең Казан янында утары булганлыгын әйтте. Мин, Казанда бер дә булганым юк, дидем. Аның кәефе кырылды. Кабат кузгалып киттек. Мин бераз алдарак, ул арттарак калды. Мин шунда әкрен генә татарча әйтелгән сүзләрне ишетеп калдым: «Сез татарча беләсезме?» – диде ул. Дошман армиясендә якташымны, җитмәсә, татар кешесен очрату башыма балта белән суккандай тәэсир итте. Мин ишетмәгәнгә сабыштым. Ул да шунда ук, берни булмагандай: «Штаб территориясеннән чыгарга маташмагыз, шунда ук атып егачаклар», – диде. Мин бу кешегә рәхмәт әйтергә тиеш булганмындыр. Яшь һәм катгый идек шул. Дошман армиясендәге кеше фәкать сатлыкҗан гына була ала дип уйлый идек».

Чәчкә Заһированың штабтан концлагерьга озатылуы, аннан качуы, көздән кышка күчкән урманнар аша кайта-кайта, ниһаять, үзебезнекеләр ягына чыгуы хакындагы хикәяте дә шушы бик озын тоелган дүртбиш көндәге вакыйгаларны эченә ала. Мәскәү янында сугышлар барганда дошман тылыннан килеп чыккан 18 яшьлек кыз «особист»ларда бик каты шик уята. Аны тәмам тинтерәтеп, усалланып сорау алалар. Өмет өзелде дигәндә, кызны танып алучы табыла. Майор Спрогис килеп, 27 кешелек отрядтан берүзе исән әйләнеп кайткан разведчик кызны «особист»лардан йолып ала.



Космодемьянская Зоя Анатольевна – 9903 нче хәрби часть сугышчысы. Гитлерчылар тарафыннан Петрищево авылы янында ерткычларча җәзалап үтерелә. Үлгәннән соң аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

«Спрогис мине каршына утыртып, башымнан кичкәннәрне сөйләтте. Алдына Мәскәү яны картасын җәеп салган иде. Мин аңа 15–20 минутта үзем җыйган разведка мәгълүматларын бәян иттем. Немецлар тора торган авылларны картада күрсәттем. Гаскәрләрнең төрен һәм чама белән санын әйттем. Майор бигрәк тә Можайск тирәсендәге танк часте белән кызыксынды. Бер гаскәрнең Франциядән китерелгән булуы турындагы мәгълүмат аңа аеруча кызыклы тоелды. Бинаһая күпсанлы мәгълүматны, авыл исемнәрен башта тоту чамасыз кыен булган иде. Башым тубал кебек иде эчендәге серләрдән. Мин аларны тапшырып, саннардан котыласы көнемне тилмереп көткән идем. Ниһаять, ул көн җитте. Сөйләп бетерүгә шундый бер җиңеллек тойдым. «Бар, яңа заданиегә кадәр ял итеп ал. Исән-сау кайткан өчен рәхмәт сиңа», – диде Спрогис. Әлбәттә, Мәскәү янындагы фаҗигале хәлләр фонында дошман тылыннан һичьюгы бер кешенең исән кайтуы да уртак шатлыкка әйләнә иде.

Мин югында безнең частька яңа кызлар килгән икән. Мине шуларның берсе – Зоя Космодемьянская белән таныштырдылар. «Сез бер-берегезгә шундый охшагансыз», – диде дустым Клава Милорадова. Мин зәңгәр күзле, озын буйлы (миннән калкурак) кызга карыйм да, нинди охшашлык күрә икән Клава дип уйлыйм. «Юк-юк, тышкы кыяфәтегезне әйтмим. Сез икегез дә бик үҗәт, таләпчән, китап укырга яратасыз һәм сер тота беләсез». Без Зоя белән янәшә бүлмәләрдә яшәдек. Күп сөйләштек, аралаштык. Чыннан да, зәвыкларыбызның охшашлыгын тора-бара үзем дә абайладым. Зоя миннән ай ярымга гына яшьрәк иде. Ул 1941 елның 29 ноябрендә җәзалап үтерелде.

Белоруссия

«1942 елның җәй башында безнең төркемне Белоруссиянең Минск өлкәсенә таркау партизан отрядларын бер зур отрядка туплау өчен җибәрделәр. Фронт сызыгын без Псков тирәсендә кичтек. Фашистлар басып алган җирләр буйлап меңнәрчә чакрым үткәнбездер. Шушы мең чакрымнарны мин җилкәмә карабин элгән, каешка патронташ аскан, гранаталар таккан килеш уздым. Биштәрләребез тулы шартлаткыч тол, миналар иде. Өркәчле дөяләрдән бер аермабыз да булмагандыр. Бик еш кына дошман белән бәрелешеп ала идек. Яраланучылар да була. Кагыйдә буларак, яралыларны авылларда калдырып китә идек. Ашау ягы бик начар иде. Бервакыт немецлар безне сазлыкка куалап керттеләр. Сазлык уртасында утрау бар иде. Атна буе камалышта тордык. Ачлыктан интектек, саз суы эчеп яшәдек. Түзәр хәл калмады. Бер атнадан соң дустым Люда белән разведкага барырга сорадык. Егетләр безгә озын колгалар хәстәрләп бирделәр. Шуларны тоттык та сазлыкка кереп киттек. Башта эчке киемнән калганчы чишенгәнбез икән әле. Аякларны сак кына шудырып, саздан эчкә – каршы як ярга таба барабыз. Кайвакыт саз аяк астына кадәр җитә. Тиздән аяк катыга тиде.

Ачлыктан, саз ерып барудан тәмам хәлдән таеп, ярга егылдык. Торып, тагын күпмедер алга таба атладык. Анда авыл күренә иде. Тик авылга кадәр барыр чамабыз калмаган иде инде. Кире борылып, сазга кердек. Без үзебез тапкан кичүдән отрядны камалыштан алып чыктык.

Мондый хәлләр гел булып торды. Җирле партизан отрядларын очраткач кына хәлләр күпмедер яхшырды. Алар безне ашаттылар, транспорт белән булыштылар. 1942 елда зур партизан отряды оештыра алдык. Аны Фрунзе исеме белән атадык. Инде зур операцияләргә керешергә була иде. Засадалар оештырдык, юлларга миналар куйдык. Мин немецлар тылына шартлатучы сыйфатында җибәрелгән идем бит. Күперләрне шартлатып, баскынчыларның Белоруссия җирләрендәге тормышын чыдап булмаслык итүгә минем дә өлешем керде. Алга таба әле дошман гарнизоннарын юк итү, тимер юл эшелоннарын тәгәрәтү, рельсларда ике сугыш буласы бар иде.

Тагын да активрак эшли алыр идек тә... Безгә үзәктән тәэмин итү җитмәде. Сугыш кирәк-яракларын, азык-төлекне үзебезгә юнәтергә кирәк иде. Бөтенесен сугышта таптык. Җирле халык безгә бәрәңге генә бирә ала иде. Без бәрәңге генә ашап тордык та, ипи дә, тоз да юк иде. Беренче кышны землянкада кышладык. Сәкеләр ясадык, аңа салам, печән түшәдек. Тимер мичебез бар иде. Әлеге дә баягы, шул бәрәңге аркасында разведка взводы командиры Жоржны атканнарын һич онытасым юк. Аның разведкачылары, полицайлар дип белеп, партизан отрядына бәрәңге китерүче олауны утка тоткан икән. Мин ул егетне бик кызгандым. Чыннан да, якын-тирә авылларда полицайлар күп иде. Отряд бу хәлне бик авыр кичерде. Чөнки Жоржны барыбыз да бик ярата идек. Бу чибәр блондин үзе кыю, үзе курkусыз. Иптәшләре өчен үлеп тора торган егет иде. Үзен атарга алып барганда да берни белмәгән миңа хәерле иртә теләп үтте. Аңа мылтык төбәргә йөрәкләре җитмәгән сугышчан иптәшләренә ул үзе: «Пли!» – дип боерык биргән. «Йөрәгемә төбәп атыгыз. Йөземне бозмагыз. Минем итекләрне взвод егетләренә бирегез», – дип киткән батыр командир бу дөньядан.

Аның үлеме мине бик тетрәтте. Бәлки, мин аны яратканмындыр дип уйлыйсыздыр. Юк ла. Аның яраткан кызы бар иде. Ул кыз штабта радист иде. Икенчедән, мин бик горур, сайлана торган кыз идем. Миңа сүз кушып караучылар күп булды. Сугышның буеннан-буена ир-ат арасында яшәдем ләбаса. Тик мин берәүне дә йөрәгемә кертмәдем. Хәер... Бер тапкыр башымны югалттым бугай. 1942 елның июлендә булды бу хәл. Фронт сызыгын кичкән генә идек әле. Витебск өлкәсендәге юлларымда бер партизан отряды белән очраштык. Болар чолганыштан чыккан хәрбиләр төркеме иде. Менә шунда күрдем дә инде мин аны. Аның исеме Гаффар иде. Түбән Новгород өлкәсенеке иде ул. Ул минем яныма килде дә, җилкәмә кулын куеп, «якташым» диде. Шундый назлы, җылы итеп әйтте. Мин күземне күтәреп карадым, карашларыбыз очрашты. Мин зәңгәр күзләрнең назында коендым. Алтынчы тойгым белән сиздем: без шул мизгелдә бер-беребезгә гашыйк булыштык. Ул әле генә хәрби заданиедән кайткан икән. Каравылга басканчы вакыты бар иде. Ә без, Мәскәү төркеме, гомумән дә әле ял итә идек. Үз мәшәкатьләребез белән мәшгульбез: юынабыз, яманабыз, корал чистартабыз. Отрядта үткәргән ике көндә Гаффар минем янымнан да китмәде. Хәтта мин хуҗалык эшләре белән йөргәндә дә һаман яныма килеп, ни белән ярдәмләшим, ди торган иде. Минем тарагымның тешләре төшкәнлеген күреп, матур тарак бүләк итте. Аннары кашык-чәнечке, котелок белән фляга табып китерде. Мин аңа рәхмәт әйтәм: «Зинһар өчен, бүтән бернәрсә дә алып килмә миңа. Болай да биштәрем бик авыр», – дим. Ул минем биштәремне күтәреп карады да: «Авыр икән шул. Ничек күтәреп йөрисең син моны?» – дип куйды. Нәрсә әйтим – капчыгым тулы миналар, шартлаткычлар, димме?

Гаффар миңа назлы карап: «Кал безнең отрядта. Мин командир белән сөйләшермен. Синең командирың белән дә килешербез дип уйлыйм. Мин аңа үземнең автоматымны бирермен. Бик яхшы автомат ул», – диде. Мине автоматка алышырга нияте барлыгын ишеткәч, мин кычкырып көлеп җибәрдем. Гаффар исә үзенекен сөйли: «Сезнең командир мондый алмашуга риза булмас дисеңме? Мин аңа тагын бер автомат бирермен. Иптәшемнекен сорап алырмын. Без үзебезгә табарбыз әле».

Юк, мин аңа үпкәләмәдем. «Гаффар, мондый нәрсә була алмый. Мин дошман тылына партизан отряды оештыру өчен җибәрелгән кеше. Аннары мин – шартлатучы. Безнең отрядта шартлатучылар күп түгел», – дидем. Җавабым Гаффарның кәефен кырды. Ләкин ул миннән читләшмәде. Биштәремнең каешын рәтләде. «Чәчкәгә чәчәк бәйләме», – дип, чәчәк җыеп бүләк итте. Аның тавышы моңлы иде. Без аның белән икәүләп «Зөләйха»ны җырладык әле. Туганнарыбызның адресларын алыштык. Кызганыч, мин биштәрем белән бергә аның адресын да җуйдым. Гаффар да мине таба алмагандыр. Мине сугышта һәлак булып калган дип уйлаган, әниләр авылдан күчеп киткәннәр. Хәзергә мин аның кадерләвен тоеп ләззәтләнәм. Мин яратам һәм яратылам дигән халәттән бик бәхетле идем. Шушы ике көн минем тормышымда әкият кебек гүзәл бер хатирә булып калды. Сугыш уртасында мондый әкият сирәк кешегә насыйп булгандыр. Мин шушы бүләк өчен язмышыма рәхмәтле. Гаффар мине Березина елгасын кичәчәк салга кадәр озатып куйды. Без шунда беренче һәм соңгы мәртәбә үбештек. Шундый назлы һәм татлы булган иде ул үбешү. Бу үбешүнең ләззәте миңа сугышлардан исән чыгар-

га булышты. Ул миңа әрсез ир-атлардан сакланырга көч бирде. Исән кайттыңмы икән син, Гаффар? Бөтен нәсел-нәсәбеңә игелек телим!

Безнең чуар коллективта ирләрнең төрлесе очрый торган иде. Миңа граната-лимонка ярдәмендә үз-үземне якларга туры килгәне дә булды. Бер юньсезе бәйләнә башлагач, гранатаның чекасын алам, дип куркыттым. Бервакыт яңагына чабып җибәрү дә җитте. Әлбәттә, кыз балага ирләр арасында бик читен. Берчак Николай дигән егет миңа мәхәббәтен аңлатты. «Сугыштан соң өйләнешербез, яме!» – дигән иде ул. Сугыш юлларында ул да югалды. Исергеев фамилияле казакъ егете дә Белоруссияне азат иткәннән соң үзенең ата-аналары янына Казакъстанга кайтуымны бик сорады. Партизан отрядында чагында тагын берәү тәкъдим ясады. Монысы да, ул да Урта Азиядән иде, сугыштан соң өйләнешик дигән иде. Кызык бит, өчесе дә «сугыштан соң», диделәр. Тик аларның берсен дә сугыш аямады. Аннары мин үзем дә йөрәгемдә Гаффарны йөртә идем бит. Сугыш эчендәге романтика мизгелләрен искә төшергән өчен гаепләмәгез. Кешеләр өмет белән яшәргә омтылалар иде. Мин алар өчен тыныч тормышка өмет чаткысы булганмындыр инде. Сугыш бетеп, байтак еллар узгач, мине мәктәп мәхәббәтем эзләп тапты. Чирек гасыр бәхетле яшәп калдык. Тик бала табу бәхете миңа насыйп булмады. Сугыш юлларының аяусыз михнәтләре мине ана бәхетеннән мәхрүм иткән иде.

Партизан тормышы бик авыр ул. Хатын-кызга гади генә шартлар да юк. Бигрәк тә мунча юклык үзәккә үтә. Бер заман бет басты. Мин землянкадан ике йөз метрлап урман эченә китә идем дә киемнәремне салып, җөйләргә сырышкан бетләрне сыдырып төшерә торган идем. Ак кар бетләрдән кап-кара була. Аннары эчке киемнәремне беттән тазартам. Урманга көнаралаш бара торган идем. Аңа карап бет саны кимеми иде.

1943 елның 31 декабрендә немецлар һәм җәза отрядлары безгә каршы операция башладылар. Иртә таңнан безнең лагерь бомбага тотылды. Бәхеткә күрә, корбаннар күп булмады. Разведка партизаннарга һөҗүм буласын хәбәр итеп өлгергән иде. Без, тиз генә җыенып, лагерьдан киттек. Ярый әле киткәнбез, чөнки самолетлар, әйләнеп килеп, кабат бомбага тоттылар. Атлы чаналар табып, Полесье тарафына кузгалдык. Ашамый-нитми ике көн чаптык. Чөнки арттан җәза отрядлары куа килә иде. Командир миңа, үткән юлга кире кайтып, мина куярга кушты. Куйдым, кабат үзебезнекеләр артыннан йөгердем. Өч тәүлектән соң гына туктадык. Шулай итеп, өч тәүлек марафоннан соң Зачалы авылына килеп кердек. Бу – сазлыклы урыннар. Анда партизан отрядлары да күп. Шуңа күрә немецлар бу тирәдә сирәк күренәләр. Чанада барган яралылар аякларын туңдырганнар иде. Аларны шундагы партизан госпиталенә урнаштырдык. Миңа шундук яралыларны карарга боерык булды. Аякларын өшетүчеләр 32 партизан булып чыкты. Мин авылга каз мае эзләп киттем. Ничек итеп наркозсыз-нисез операцияләр ясаганны яза башласам, бүген дә әрнешәм.

Ниһаять, 1944 елның 6 июнендә Америка һәм Англия гаскәрләре, Ла-Маншны кичеп, Франция ярларында ныгып урнаштылар. Икенче фронт ачылды. Мин катнашкан сугышчан зур операциянең иң соңгыларыннан берсе – рельсларда сугыш булды. Әлеге операция «Багратион» дип аталган иде. Без һөҗүмнәр белән алга баручы, Белоруссия җирләрен фашистлардан азат итүче совет гаскәрләренә ярдәм итәргә тиеш идек.

Бу юлы Минск–Барановичи тимер юлына чыктык. Безнең отряд Дегтяное тимер юл станциясен, 27 вагонлы тимер юл составын яндырды, 300 рельсны шартлатты, 29 немецны дөмектерде, 28 винтовканы, 5 автоматны, 2 станоклы пулеметны, 3 кул пулеметын, 15 мең патронны трофей итеп алды. Миңа бер вагонга ут төртергә, 4 рельсны шартлатырга кушылган иде. Без якын килгәч, немецлар вагоннардан сикерешеп төштеләр, аларның эшен тиз бетердек. Вагон ишеген көч-хәл белән ватып, эчкә кергәч, бер уч сүсне керосинга манып ут төрттем, аннары тол шашкаларын алып, рельслар буйлап йөгердем. Дөрләп янган вагон юлны яхшы яктырта. Шартлату эшенә дә мин бик остарган идем инде.

3 июльдә безнекеләр Белоруссия башкаласы Минскины азат итеп, алга таба киттеләр. Партизаннарның да күбесе армия составына кушылып китте. Шулай итеп, без, партизаннар, тылда калдык. Сугыш беркайчан да бетмәс кебек иде. Без җиңел сулап куйдык. Һәрвакыт эзәрлекләнгән җәнлек халәтендә яшәү, үзәккә үткән суыклар, даими ачлык тәмам йончыткан иде. Бик тә-бик тә иркенәеп аласы, иң мөһиме – юынасы килә иде.

Тик шулай да немецлар белән тагын бер очрашу көткән икән әле. Дус кызым Клава Зенькович белән елга буена төштек. Безнең отряд якында гына. Бик курыкмыйбыз. Чәчләрне юып, керләрне чайкап алыйк дидек. Отряд башлыгы безгә рөхсәт бирде, тик корал белән берничә граната алырга кушты. «Уяу булыгыз! Урманда адашып калган, яхшы коралланган немецлар бирелергә бик атлыгып тормый», – диде. Шундый җылы июль көне иде. Чишендек, суга кердек. Отряд егетләре безгә немец сабыны табып биргәннәр иде. Мин алтынсу озын чәчләремне юдым да иңнәремә сибеп җибәрдем. Үзем уйлыйм әле: менә сугыш бетәр дә мин чәчләремнең матурлыгына сокланырдай насыйбымны очратырмын, имеш.

Менә без юындык, киендек, аякка гына киеп өлгермәдек. Керләребезне чайкарга керештек. Кинәт куаклыкта немецча сөйләшкәннәрен ишетеп алдым. Клавага әйтәм: «Бу бит немецлар. Тиз генә аягыңа ки. Әйдә, аларны әсир итәбез. Безнең лагерьга таба

баралар бит. Әлләниләр булуы бар». Клава, ризалыгын белдереп, башын гына какты. Чөнки ул тавышсыз кыз иде. Без тиз-тиз аякларыбызга кидек. Сул кулга лимонкаларны, уң кулга пистолетларны алдык та немец тавышлары ишетелгән тарафка йөгердек. Үзләрен күрмибез әле. Йөгереп барып җиттек, куакларны аердык. Өч немец солдаты елгадан чыгып килә. Өскә таба күтәргән кулларында кораллары. Берсендә – автомат, икесендә – винтовкалар. Куркыныч инде. Без – ике кыз, алар – өч таза ир кеше. Ләкин аларны лагерьга таба үткәреп җибәрергә ярамый. Бу – аяусыз сугыш кануны.

Мин усал тавыш белән команда бирдем:

– Верфен, верфен, хенде хох, фершпрехе зи лебен. (Коралларыгызны ташлагыз. Кулларыгызны күтәрегез, үтермәскә сүз бирәбез!)

– Солдат Зенькович, алдан атла. Дойч золдат, шрайтен! (Немец солдатлары, атлагыз!)

Минем дустым шушы сәер төркемне әйдәкләп бара, тегеләр аның артыннан атлый. Куллары һаман күтәрелгән килеш бит әле. Кулларын төшерергә рөхсәт итәм. Үзара нидер сөйләшергә азапланалар. «Шнель, шнель, сөйләшмәскә!» – дип команда бирәм. Шулай да арадан берсе сорау бирергә кыюлык итте: «Партизаннармы, даими армияме?» Аларның партизаннардан курыкканнарын беләбез. Чөнки партизаннар беркайчан да немецларны исән калдырмыйлар иде. Шуңа күрә алдалыйм: «Партизан түгел, регуляр армия, сезне берәү дә үтермәс». Мин вәгъдәмдә торасыма ышана идем. Алар да ышандылар бугай. Инде урманга кердек. Клава алдан, немецлар аның артыннан. Күңел тыныч түгел. Курыкканны сиздермәс өчен мин туктаусыз аларга кычкырам. Лагерьга кайтып җиткәнче мәктәптә өйрәнгән барлык немецча боерык фигыльләрне искә төшереп бетердем бугай.

Ничә минут барганбыздыр, белмим. Ярты сәгать чамасы булгандыр. Чыдап булмаслык киеренке бер халәт иде ул. Ничек тә исән калырга хыялланган өч таза немец солдаты һәм егерме яшьлек ике чандыр кыз. Немец солдатлары теләсә кайсы мизгелдә безнең өскә ташланырга мөмкин иде бит. Без әле, мөгаен, коралларыбызны кулланырга да өлгерми калыр идек. Гәрчә граната бик нәтиҗәле корал инде ул. Ләкин граната безне дә яралар иде. Беренче постка килеп җиткәч кенә иркен сулап куйдык. «Егетләр, каршы алыгыз! Без немецлар алып кайтып киләбез!»

Төрле яктан йөгерешеп килеп җиткән партизаннар шаккатып торалар. Берәм-берәм әсирләрне капшап карыйлар. Чыннан да немецлар бугай шул! Мин тоткыннарны егетләргә тапшырам. Берсе шунда миңа тирән үпкә белән карап ала. Алдадың, янәсе. Мин аны тынычландырам: үтермибез! Шунда үземнең кинәт хәлем китә, җиргә чүгәм. Минем янда Клава белән штаб башлыгы Виктор Морозов басып торалар. Тынычландыралар. Клаваның күзләреннән яшь ага. Штаб башлыгы шелтәләгән була:

– Булдыргансыз, кызлар. Тик ничек шундый эшкә тәвәккәлләдегез. Алар бит сезне буып кына ыргыткан булырлар иде.

Без дәшмибез инде. Фәкать әсирләрнең коралларын барып алырга кирәк, дип кенә әйттек. Безнең керләр дә елга буенда калган иде бит әле.

Немецлардан сорау алдылар. Алар ике кызга ничек итеп әсир төшүләрен аңлаттылар:

– Без башта кызларның үзләрен күрмәдек. Аннары безгә төбәлгән граната белән пистолетлар уен-муен түгел дип уйладык. Немецча командалар биреп торган кыз бик тәвәккәл күренде. Чәче-башы тузган ул кызны без нииндидер җен кызыдыр дип уйладык.

Солдатларга биргән вәгъдәмне үтәдем мин. Аларны хәрби әсирләрне туплау пунктына илттеләр. Аларны илтеп тапшырганлыкка мөһер сугылган кәгазь дә алып кайттылар.

Бу минем немецлар белән соңгы очрашуым булды. Һәм партизан отрядындагы соңгы сугышчан бурычым да иде.

1944 елның июле. Белоруссия юлларыннан өр-яңа йөк машиналары уза. Галя Серафимович белән якын разведкадан кайтып киләбез. Юл читенә бастык та йөк машиналары узганын карап торабыз. Без бу машиналарга шатланабыз, кул изибез. Кинәт бер машина юлыннан тайпылды да безнең өскә килә башлады. Галя читкә сикереп өлгерде. Мин машина астында калдым. Шофер машинасын көчкә генә туктата алды. Мине машина астыннан тартып алдылар. Шунда аңымны югалтканмын. Госпитальдә генә аңыма килдем. Мине кабул итеп алган хәрби табиб: «Кем сезне таптатты? – дип сорады. Янымда басып торган шофер егетне кызганып: «Мине таптаткан машина ары китте», – дидем. Сугыш беткәндә генә кемнеңдер язмышын бозасым килмәде. Без барыбыз да сугыш корбаннары идек. Бер ай буе гипста яттым. Партизанлык тәмам. Безнең егетләр армиягә кушылып китте.

Мин дә Минск шәһәре хәрби комиссариатына барып, Берлинга бара торган хәрби частька теркәүләрен сорадым. Шулай итеп, үз ирегем белән сугышның өченче түгәрәгенә килеп кердем».

«9903 нче гаскәр сугышчылары разведка мәгълүматлары җыюга күп өлеш керттеләр. Шулар нигезендә Мәскәү янында Гитлер армиясе тар-мар ителде». Көнбатыш фронт штабының разведка бүлеге башлыгы, отставкадагы полковник Я. Г. Ильинский.

«1942 елның маенда партизан кадрлары әзерләү мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң, мин немец тылына китеп барам. Әтием Белоруссиядә хәбәрсез югалганга күрә шул тарафны сайладым. Бәлки, анда әтинең эзләренә юлыгырмын». Чәчкә Заһирова – 1942 елның 13 июненнән 1945 елның 22 июленә кадәр Белоруссия партизаны.

Асия ЮНЫСОВА тәрҗемәсе.













«Туфан МИҢНУЛЛИН»

Күренекле драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин – эшгамәлләре белән халык хәтерендә истә калырга лаек булган көчле шәхесләрнең берсе. Халкыбызның күз уңында мәгънәле гомер кичерде, исән чагында ук мәртәбәле бәяләнүгә лаек булды ул. Олуг язучының исеме, аның зирәк сүзе безне бүген дә озатып бара. Китапта гаҗәеп талант иясе Туфан Миңнуллин турында замандашларының истәлек-хатирәләре һәм үзенең кайбер әдәби сәхифәләре туплап бирелгән.

Зиннур МАНСУРОВ

«Тукай белән әңгәмәләр»

Бу үзенчәлекле проектны гамәлгә ашырганда автор үтемле саналган әңгәмә шәкеле файдаланган. Китап шул ягы белән үзенчәлекле: татар халкының иҗтимагый яшәешен төрле яссылыкта чагылдырган тематик әңгәмәләрдә тормыш куйган бик күп сорауларга җавап табарга мөмкин. Күпьеллык эзләнүләр нәтиҗәсендә туган хезмәттә «Тукайча татар кодексы» да моңарчы күрелмәгән яңалык буларак кабул ителер.

Рауза ХӘЙРЕТДИНОВА

«Гомер сәхнәсе»

Алтмыш елга якын татар театры сәхнәсендә иҗат итү чорында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы Рауза Хәйретдиновага театр сәнгате үсешенә зур өлеш керткән күп кенә сәхнә йолдызлары, Галиәсгар Камал исемендәге театрның тарихы булырдай татар артистлары белән аралашырга һәм эшләргә туры килгән. «Бу шәхесләр белән бергә иҗат иткән елларымдагы онытылмас хатирәләремне язып калдыруны үземнең бурычым дип санадым», – ди автор.

Габдулла ТУКАЙ

«Су анасы»

Тукаебызның атаклы «Су анасы» әкият-поэмасы китабын балалар берьюлы дүрт телдә укый ала: татарча (кириллицада һәм латин графикасында), русча, инглизчә һәм төрекчә. Китап рәссам Светлана Ибраһимова рәсемнәре белән бизәлгән. Кайсы телгә тәрҗемә ителсә дә, әкиятнең азагында балаларга җиткерелгән үгет-нәсыйхәт бертөрле яңгырый: «Иясе юк, дип, кеше әйберенә тияргә ярамый!»

Резеда ВӘЛИЕВА

«Йолдызстан батыры»

«Звездный витязь» Китапка шагыйрәнең төрле елларда балалар өчен язылган шигырьләре, җырлары, әкиятләре, поэмалары тупланган. Шаянлыкка, тапкырлыкка нигезләнгән кызыклы һәм гыйбрәтле шигырьләр туган илгә мәхәббәт хисе, табигатькә сакчыл караш тәрбияли, хайваннарны һәм кош-кортларны рәнҗетмәскә, олыларны ихтирам итәргә өйрәтә.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

«Илекәй батыр»

Г. Гыйльманов – татар халык авыз иҗатыннан килә торган әкият традицияләрен борынгы төрки миф, легенда, риваять һәм хикәят мотивлары белән баетып, әдәбиятның бу өлкәсендә өр-яңа иҗат юнәлеше тудырган язучы. Ул үз әкиятләрендә халыкчан алымнар кулланып, геройлар язмышын милли рухта хәл итәргә омтыла. Җыентык – әкият укырга яратучыларга зур бүләк.

ТӘЭСИР



Миләүшә ГАЙНАТУЛЛИНА, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең баш мөхәррире



Инглиз язучысы Джоджо Мойес әсәрләре авторның яшьтәшем, хәтта һөнәрдәшем – журналист булуы белән җәлеп итте бугай. Мин аның иҗатына мөкиббән. Соңгы китабы – «Девушка, которую ты покинул» – көткәннән дә күбрәк ошады. Әсәрне геройлары – икесе ике чорда, ике илдә яшәгән ике хатын-кыз – Софи Лефевр һәм Лив Халстон. Араларында бер гасыр гомер ятуга карамастан, бу яшь хатын-кызлар авыр язмышлары, өмет-ышанычлары, үзләре өчен иң кадерле кыйммәтләрне яклап, ахыргача көрәшүләре белән бер-берсенә охшаш. Софи – Франциядә яши, рәссам Эдуард Лефеврга кияүгә чыга. Яраткан хатынын сурәтләп, ире «Девушка, которую ты покинул» дигән картина иҗат итә. Беренче Бөтендөнья сугышы башланып, ирен сугышка озаткан, ә үзе немецлар басып алган илдә калган Софи өчен ул – үткән тормышының иң бәхетле мизгелләре шаһиты. Ә йөз елдан соң Англиядә яшәүче Лив Халстон өчен әлеге картина – үләр алдыннан яраткан ире сатып алган туй бүләге. Бу ике хатын-кыз язмышы бер сокландырса, Джоджо Мойесның ике чорны бер дәрәҗәдә оста тасвирлавы тәмам таң калдырды. Һәр сүз урынлы, һәр сюжет мавыктыргыч, бер-берсенә бәйләнеп бара, тетрәндерә. Әсәр геройлары икесе дә катлаулы сайлау ясарга мәҗбүр. Автор һәр укучысы алдына: «Ә бу очракта мин нишләгән булыр идем?» – дигән сорау куя сыман. Ач балаларны, барлык авырлыкларны үз җилкәләрендә күтәргән хатын-кызларны, ире белән күрешү өчен җанын фида кылырга әзер Софины кызганудан, күңелем тулып, үкси-үкси туйганчы еладым. Нинди генә хәлләрдә дә мәхәббәтенә тугры калган, гаделлек өчен ахыргача барган Софига гашыйк булдым.



Рафис
КОРБАН

Тукай туган көн, Шигырь бәйрәме, Туган тел көне... Быелгы Әдәбият елында шигъри апрель көне тагын да дәрәҗәлерәк, мәртәбәлерәк узар, әлбәттә. Иң лаеклылар республикабызның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе ияләре булырлар. Кандидатлар арасында язучылар Клара Булатова, Камил Кәримов, Рафис Корбанов, Ләбиб Лерон.

Журналыбызның шигърият сәхифәсендә исә бүген Рафис Корбанның яңа шигырьләре. Алар тирән фикерле, хисле, шаян, сагынулы, яратулы...

И ТАТАРНЫҢ КҮҢЕЛ КӨЗГЕЛӘРЕ!

Татар күзләре

Мин татарны күзләреннән таныйм,
Карашыннан таныйм мин аны.
Карашлары аның мәхәббәтле,
Күзләрендә балкый иманы.

Күзләрендә балкый бар үткәне,
Гасырларның тирән эзләре.
Сагыш аша карый бу дөньяга
Хәсрәт эчкән татар күзләре.

Кайда гына аны очратсам да –
Бер картмы ул, әллә сабыймы –
Күңеленең сихри матурлыгын
Күзләренә карап таныймын.

И татарның күңел көзгеләре!
Укыйм сезгә сәждә сүрәсен.
Бу дөньяда татар күзләренең
Беркайчан да нуры сүнмәсен!

Кайсын иленде

Күреп кайттым Кайсын Кули илен.
Кунак итеп дәште ул мине.
Кичкән чакта Чегем тарлавыгын,
Күргән кебек булдым Кулине.

Карап йөрдем Кавказ тау сыртларын.
Сокландырды Эльбрус мине.
Уйлап йөрдем таулар җырын җырлап,
Тау булалган Кайсын Кулине.

Эчтем учлап тау чишмәсе суын.
Ул да шигырь укый күк иде.
Тау чишмәсе җырын тыңлаганда,
Тыңлаган күк булдым Кулине.

Йөреп кайттым Кайсын эзләреннән.
Аңладым мин Кайсын Кулине.
Ул тауларын җырлап тау булган ич.
Сагындырды туган як мине!

Хатын-кызның яшен сорамагыз...

Сорамагыз хатыннарның яшен...
Шәриф БИККОЛ

Хатын-кызның яшен сорамагыз.
Белалмассыз аның үз яшен.
Гел яшь килеш күрәсегез килсә,
Түктермәгез аның күз яшен.

Хатын-кызның яшен сорамагыз,
Күңеленә шөбһә салмагыз.
Яныгыздан үтеп киткән чакта
Борылып карамыйча калмагыз.

Хатын-кызның яшен сорамагыз,
Төшермәгез хәтта исенә.
Әйтегез тик матур сүзләр генә,
Төреп назлы сөю хисенә.

Унсигездә хатын-кызның яше!
Белмәсәгез әгәр – белегез.
Үзегез дә алар тирәсендә
Яшь егетләр кебек йөрегез.

Начармыни, йөрәк түребездә
Иярләнгән тулпар ат булса,
Яныбызда үзен унсигездә
Хис итүче чибәр зат булса?!

Хәтерлим мин гаҗәп бер мизгелне

К... (Я помню чудное мгновенье)
Александр ПУШКИН

Хәтерлим мен гаҗәп бер мизгелне:
Кичә генә булган шикелле,
Күз алдымда тора синең сының –
Гүзәллекнең гаҗәп мизгеле.

Сагышлардан газапланган мәлдә
Мәшәкатьле тормыш эчендә
Чыңлап торды
синең назлы таушың,
Сине күрдем бик еш төшемдә.

Үтте еллар. Дәртле ашкынулар
Хыялларның барын тузгытты.
Чыңлап торган назлы тавышыңны,
Мин йөзеңне хәтта оныттым.

Мәхбүс булып тормыш зинданында
Тыныч кына үтте көннәрем.
Беркемне дә шашып яратмадым,
Күз яшь түгеп, сөям, димәдем.

Йөрәгемне кабат уяттың син:
Кичә генә булган шикелле,
Күз алдыма килде синең сының –
Гүзәллекнең гаҗәп мизгеле.

Ләззәтләнеп типте ярсу йөрәк.
Аның өчен кабат уянды
Мәхәббәт һәм илһам. Ләззәтләнеп
Сөю учагында ул янды.

Бишек җыры

Бишек җыры. Аны җырлар өчен
Кирәк түгел хәтта гармун да.
Аналарның йөрәк түрендәге
Иң мөкатдәс моңнар бар монда.

Бишек җыры. Иң беренче тапкыр
Ишеткән җыр җиргә тугач та.
Елавыннан туктасын, дип, балам,
Көйләнгәндер безгә ул башта.

Әлли-бәлли, әлли-бәлли-бәү дип,
Газиз әнкәй аны көйләгән.
Шушы җыры белән әниләр бит
Сабыена бәхет теләгән.

Бишек җыры – безнең иң беренче
Җырлаган җыр дөнья йөзендә.
Әнкәемә кушылып бишегемдә
Көйләгәнмен аны үзем дә.

Телебезне ачкан җыр ул безнең,
Әлифбасы туган телнең ул.
Бишек җыры – иң бөек җыр җирдә,
Гомерләрне башлый безнең ул!

Картлык...

Мин яшьлектә сөйгән кызлар
(Эһ, күңел әрни инде!)
Дәү әни генә дә түгел,
Күптәннән әби инде.

Ә үзем соң? Үзем дә бер
Яшьлеккә шәүлә генә.
Күз күрми, колак ишетми,
Йөри тик гәүдәм генә.

Елмаю

Юлыгызда каршылыклар туып,
Кәефегез әгәр кырылса,
Бәхет кошы бүген сезнең якка
Яны белән әгәр борылса,

Борчылмагыз, барыр юлыгызда
Очрамый калмас, мөгаен,
Кояш кебек балкып кем дә булса
Янығыздан үтәр елмаеп.

Таныш түгел үтеп баручының
Елмаюын күңел кабатлар.
Шул елмаю балкыр йөзегездә,
Иңегездә үсәр канатлар.

Куллар төшеп, әгәр гайрәт чигеп,
Эшегезгә теләк сүрелсә,
Канатлары каерылган коштай,
Күңелләргә сагыш үрелсә,
Борчылмагыз, барыр юлыгызда
Очрамый калмас, мөгаен,
Кояш кебек балкып кем дә булса
Янығыздан үтәр елмаеп.

Дөньяларны киңәйтә ул юлда
Бер елмайган кеше очрап.
Елмаегыз, дуслар, кешеләргә,
Елмаегыз, дуслар, ешрак.

Юлдашлар

Шәүкәт Галиев ядкаре

Олы юлга озатып калган
Остазларымның берсен
Искә алам әле бүген,
Әйдә, җырыма керсен.

Балачакның шәп шагыйрен –
Гали Шәүкәт Галиен;
Без бит укып үскән буын
Аның шук Шәвәлиен!

Үзен әле белми идем,
Китабын укысак та.
Дуслар булып китәрбез дип,
Кем уйлаган ул чакта?!

Дуслаштык шул. Дуслаштырды
Балалар өчен язу.
Балалар өчен язу ул –
Энә белән кое казу.

Шактый ук олы булса да
Яшьләребез арасы,
Максатлар уртак иде шул –
Бер үк юлдан барасы.

Юлларыбыз бер дә берен,
Тукталышлары төрле
Була икән. Ул да кинәт
Калды туктап бер көнне.

Калса да туктап юлда ул,
Без бит мәңге юлдашлар.
Юлларда төрле хәлләрне
Күрде инде бу башлар.

Остазлар күрсәткән юлдан
Тайпылмас минем аяк.
Юлдаш кына түгел алар,
Алар шул – якты маяк!

* * *

Илдар Юзеев ядкаре

Китмик әле, дуслар, китмик әле,
Утыраек әле чак кына.

Илдар ЮЗЕЕВ

Кайчак минем, телефонны алып,
Җыясым килә аның номерын.
Ишетергә теләп аның тавышын,
Үтәр инде шулай гомерем.

Шалтырата иде кичкырынлап:
«Алло, Рафис, әле эштәме?
Бер сөйләшеп утырасы иде,
Хәзер килеп җитәм, көт, яме».

Килеп керә берәр сәгать үткәч,
Көчкә-көчкә алып һуш-тынын,
Сулуы кабып, биек баскычыннан
Менгәндә Матбугат йортының.

«Ачуланма бер дә, Рафис энем,
Көчтәнәчсез түгел кунагың.
Суытмыйча алып килдем менә
Тәфтиләнең кайнар коймагын».

Портфеленнән ярты тавык чыга,
Савыт чыга тавык янына.
Алай-болай, кеше кермәсме, дип,
Карап ала ишек ягына.

Коймак белән тавык ярап куя:
Эш беткәндә тамак ач була!
Утыра торгач, шулай җайлап кына,
Савыт бушый, сейф ачыла.

Утырабыз ике байгыш кебек.
Шаһит бары тулган ай гына.
«Кых-хым, кых-хым»
тамак кыра-кыра
Илдар абый сөйли җай гына.

Телефонга кайчак үреләм дә,
Искә төшә Илдар абыйлар.
Кайтмас инде, кайтмас, алар мәңге
Шул кичләрдә торып калдылар.

Язучы, шагыйрә, журналист... Укучылар аны «Яшен күзләре», «Еллар кәрваны», «Догалы корт», «Уйлы җил», «Толымлы ай» китаплары буенча күптән яратып кабул итте инде. Үзе турында:
Бер җепләргә / тезә тормыш / һәр бизәкнең үз ишен... / Югалтма, дөнья! / Асылташ – Фирүзә минем исем, – дип язган Фирүзә Җамалетдинованы исә әдәбият дөньясы чын-чынлап бизәк буларак кабул итте. Тикмәгә генә Мөдәррис Әгъләмов аның яңа шигырьләре белән танышкач: «Шигырьләр уку рәхәтеннән ишелеп төшәсең... Рәхәт! Тоташ, үзмичә укыйсы килә», – дип, Фирүзәгә хат юлламагандыр инде! Фәлсәфи-лирик шигырьләре, замандашлары кичерешләрен сыйдырган ихлас хикәяләре – бар да җылы, җиңел, ягымлы. Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылы кызы университетның журналистика факультетын тәмамлап, Чаллыда мәктәптә укыткан, редакцияләрдә эшләгән. Һәм ул еллар җай гына иҗатында урын ала барган.
Бу көннәрдә Фирүзә Җамалетдинова урамында бәйрәм: укучылары, хезмәттәшләре юбилее белән котлый аны. «Сөембикә» журналы да әлеге котлауларга кушыла, иҗат юлында уңышлар тели.



Фирүзә
ҖАМАЛЕТДИНОВА

КИЛЕННӘР

(хикәя)

Безнең өй каршындагы ак каенга быелгы язда да сыерчык кайтты. Япа-ялгызы кайтты ул. Җылы якларга очканда пары диңгезгә егылып төшкәндер инде, ди әни. Кошлар канатын бер-берсенә терәк итә алмый шул... Кеше язмышлары түгел, кош язмышлары да бер-берсенә охшамаган, ди... Әни миңа кошлар турында сөйли, мин нигәдер ахирәтләремне искә төшереп утырам...

* * *

Әйе, ике ахирәтем бар минем. Аргы очтагысы – Гөлсирин, бирге очтагысы Нурзадә исемле. Алар җай чыкканда безгә килештерәләр. Мин дә юл уңаенда аларга кагыла үткәлим.

Гөлсириннәрнең өе шау-шулы. Дүрт сеңлесе, бер энекәше бар. Абыйсы да үткән язда шушы өйгә, башкорт якларыннанмы соң, килен алып кайтты. Ул килен инде бер ел буена мич алдында бәрәңге әрчи. Көннең кай мәлендә барып керсәң дә, бер үк сурәткә юлыгасың: алап авызлы зур мич; аның каршында алсу чәчәкле яулыгын маңгаена төшереп бәйләп, бөкшәеп утырган килен; кулында әлүмине ялтырап торган агач саплы юка пычак; алдында бер чиләк түбәләмә өелгән карасу бәрәңге...

Бездә туфрак сумаладай чем-кара. Юганда бәрәңгенең сарысы чыкканны көтә-көтә күзләр күгәрерлек. Шуңа аны сарысы чыкканчы түгел, балчыгыннан арындырганчы гына юалар.

Ә мич алдында кайнанасы Кафия апа мыдыр-мыдыр нидер сөйләнә. Һаман кемгәдер ачулы ул. Аңа хәтта «Исәнме, Кафия апа» дияргә дә ярамый. «Брач түгелсеңдер әле», – дип җавап бирә. Ул шулай җавап биргән көннәрдә миңа бик күңелсез була, аларның өендәге хәлләр турында уйлап йөрим, Гөлсиринне, бигрәк тә бәхетсез киленнәрен жәлләп йоклый алмый ятам. Теге ялтыравык пычак та, кыйшайган калай чиләк тә кызганыч булып тоела...

Минем алар өенә килеп керүем була, Кафия апа гадәттәгечә ыңгырашып куя һәм кинәт тавышын күтәреп:

– Сиңа иртәрәк торып әрчергә ярамадымы бу бәрәңгеңне? Юл уртасына җәелеп утырмасаң... – дип такмаклый башлый.

Килен дәшми. Аның кулында үткен пычак. Ул бәрәңге әрчи.

– Чит кеше барында түзеп тор инде бераз, әни, – дип, иннеген сөртә-сөртә, түр яктан Гөлсирин сүз кушып ала.

Ул миннән яхшысынмый инде. Чит кешегә әнисен башкачарак күрсәтәсе килә кебек.

– Ай, кулым сызлый, аягым яна... Хәерсез, иртүк торып эшләп куярмы дисәм... – дип дәвам итә Кафия апа.

Бу мәлдә миңа шушы өйнең тәрәзәләре дә кечкенә, түшәмнәре дә тәбәнәк булып күренә, һава җитми башлый. Үзе килен ягына борылып та карамый ул. Сөт кайнаткан казан төбен кыруын белә. Үзе һаман тавышын күтәрә бара:

– Иртүк торып эшләп куярмы дисәм... Йокы чүмәләсе... Ай, аягым... билем.

Минем яшь киленне жәлләп кычкырып елап җибәрәсем килә башлый. Аны нигәдер үги әнисенә ярарга тырышып, төпсез мичкәгә су ташучы Зөһрәгә охшатам. Үги кызны, ичмасам, Ай тартып алган.

– Син, хәерсез, юл уртасына куймасаң чиләгеңне... Иртәрәк торып әрчесәң ни буладыр. Ай, аякларым... бармакларым... Ай, үләм... каһәр төшкере.

Соңгы җөмләсен киленгә әйтәме ул, чиргәме – һич аңлашылмый. Килен дәшми. Пычагын да тизрәк хәрәкәтләндерми. Урыныннан да кузгалмый. Ни рәвешле утырса, шулай утыра бирә. Чөнки кайнанасы юкка бәйләнә аңа. Мич алдында берьюлы ике кеше үтеп йөрерлек урын бар. Түрдәрәк тә урын җитәрлек. Аннан бу өйдә мич алдына керергә ашкынып торучы да күренми. Анда һәрчак кайнана белән килен кайнаша. Кайнана учакка утын ташлый, килен бәрәңге әрчи...

Кызлар күбрәк түрдәге көзге тирәсендә. Әнә Гөлсирин тып-тыныч кына битенә иннек-кершән тидерә... Минем йөрәгем оясыннан очып чыгарга торган коштай талпына. Куңелсез итеп талпына. Гадәттәгечә, үз-үземә, бу йортка никләр керәм икән соң мин, дип, үкенечле сорау бирми калмыйм. Тик керми кала алмыйм шул. Анда минем ахирәтем Гөлсирин яши. Аңа сернең бөтен төрлесе сыя чөнки. Шат күңелле, һәрчак ачык йөзле, бик әйбәт кыз ул. Әнә Гөлсирин иннек-кершәнен дә сөртеп бетерде. Инде без ишек ягына атлыйбыз. Һәм шул мәлдә ишек ачыла... Аннан, көрәктәй кулын алгарак сузып, Гөлсириннең пычракка-майга баткан абыйсы керә. Тракторчы ул. Басу-кырларны ястыктай йомшак итә, еллык уңышның хуҗасы шушы инде, диләр аның хакында. Көзен ул эшкәрткән басулардагы бәрәңгене һич җыеп бетермәле түгел, диләр. Өйләнү килеште бу Нурга. Өйләнгәнче кырлар өстеннән тудым-судым гына үтә иде, хәзер эш кешесе икәнлеге кулларыннан ук күренә, диләр. Чынлап та күренә икән шул...

Ишек төбендә торсак та, ул безне күрми. Бар ихласы хатынына юнәлгән: елмая-елмая аңа күз кыса. Кинәт түшәмнәр биегәеп, өй эче иркенәеп китә. Тәрәзәләр дә яктыра. Иренә җавап итеп, яшь килен дә елмая. Аның елмаюыннан җылы яктылык тарала. Яктылык шәмен кабызган көе ул, урыныннан кузгалып, мич авызындагы комганга үрелә. Мин аның елмая алуына гаҗәпләнәм. Әллә сокланам дамы соң?

– Ачыктырды, – дип сүз башлый ире. – Торна тавы ягындагы басуны сөреп бетердек...

– Аш та әзер, чәй дә кайнаган, улым, – дип җавап бирә ана һәм янә сукрануга күчә: – Ай, аягым сызлавы, ай, бармакларым... Каһәр суккыры...

Кайнана инде киленне каһәрләми. Шулай да миңа бу килен шушы йортны күрми торса, бу ир-егет ястыктай кырлары белән генә яшәсә, бәхетлерәк булыр иде кебек тоела. Без мәхәббәт белән нәфрәт каршылыгы, яшәү белән үлем тартышы аша атлап чыгып китәбез. Һәм барысын да онытабыз. Чөнки без яшьлектә яшибез. Безнең хыяллар берничек тә әлеге тормыш чынбарлыгы белән бер куышка сыеша алмый.

Авыл уртасына кадәр әле шактый юл үтәсе бар. Якшәмбеләрдә мин, Гөлсирин, Нурзадә, өчебез бергә җыелып, мәктәптә стена газетасы чыгарабыз. Нурзадә юл уңаенда тора. Икәүләп аны алырга керәбез. Без килгәндә, ул, гадәттәгечә, уянмаган була.

– Әкренрәк... Балалар йоклый... – дип каршы ала Нурзадәнең әнисе.

– Йокы чүлмәгенә торырга вакыт, – дип шаяртабыз икәүләп.

– Яшь чакта йокы тәмле була ул. Йоклап калсыннар, – ди пышылдап кына Айния апа. – Әйдәгез, үтегез, үт.

Без Айния апа артыннан тынычлык иленә юл алабыз. Нурзадәнең караватына каршы гына ак җирлеккә алсу роза гөлләре төшкән чаршау эленеп тора. Ярым ачык тәрәзәдән сирин, шомырт, яшь яфрак исләрен эләктереп кергән җил шушы чаршау тирәсендә талгын бөтерелә.

– Килдегез дәмени? – ди Нурзадә, күзен ачар-ачмас киерелеп.

– Килгәннәр дә шул, балакаем, – ди әнисе. – Әйдә, киен дә кухняга чык. Коймак салам хәзер. Чәй дә өлгергән... Абыеңнар йокласын. Шаулама...

Безнең күзләр ак чаршауда. «Торырга кирәк!» дип, серле пышылдый чаршау эче. Шул мәлдә ул тирәгә җан иңә.

– Кит, җүләр! – дип назлы итеп йомшак кына чыелдап җибәрә яшь хатын-кыз тавышы.

Бу аларның киленнәре була инде. Сөмбел исемле. Расих малае чуаш ягындагы татар авылыннан килен алып кайткан дигәннәре искә төшә. Шул арада Нурзадәнең абыйсы, киленне кулларында күтәреп, чаршау эченнән килеп тә чыга. Әкияти матурлыкка күз тимәсен дияргә дә оялып, кухня ягына атлыйбыз. Аннан бигрәк, аларны эчке киемнәрдән күрү дә әллә ничек уңайсызрак тоела. Әниләре алдында бигрәк тә.

– Шаяртма инде, улым... Оялтма инде Сөмбелне, – ди әнисе, безгә ияреп чыгып барышлый.

Иренең учларыннан нәни коштай очарга талпынган килен белән шушы дөньяны күтәреп торуына ышан-

ган әзмәвердәй ир-ат, чырык-чырык көлешеп, икәүдән-икәү генә калалар...

Кухняга чыгып җиткәнче, Айния апа гөлдер-гөлдер көлә. Тынычлык күгәрчене инде ул бу йортта. Аның ире белән гөр-гөр килеп сөйләшүе дә бөтен җиһанны нурга төрә. Ул нур хәтта безнең күңелләргә дә кагыла: әйтерсең, тынычлык күгәрчене ап-ак канат очлары белән сыйпап-сыйпап ала... Хәтта киленне дә...

Коймаклы табын артына иң соңыннан килеп утырган килене белән улы, без чыгып киткәндә:

– Арымый эшләгез, сары май тешләгез, – дип авыз ерып калалар...

Бу мәлдә Гөлсирин ниләр уйлагандыр, белмим. Миңа бер сорау тынгы бирми: мәхәббәткә кызыгасымы, әллә аны кызганасымы?

* * *

Нурзадә белән без күп еллар үткәч очраштык. Яшьлегебезне, мәктәп елларын искә төшердек. Сүз иярә сүз чыгып, мин аннан:

– Абыең киленегезне һаман шулай кулларында күтәреп йөртәме? – дип сорап куйдым.

– Һаман шулай, – диде Нурзадә. – Абый аны хатыны итеп тә, баласы итеп тә яратты. Балалары булмагач инде... Хәер, үзе шундый бит ул безнең килен. Күтәрттереп йөртә белә...

Нурзадә белән үткәннәрне сөйләшә-сөйләшә, елга буйлап киттек. Коляскага утырган үсмер кызын тартып килүче ханым безне күргәч туктап калды. Исәнләшеп үтеп киткән идек инде, ул артына борылып кинәт кенә эндәште:

– Тукта, сез безнең Гөлсириннең ахирәтләре түгелме соң?

– Абау, Равия апа, сезмени бу?

– Мин шул, – диде ул. – Менә кызым белән һава суларга чыктык әле. Таныдыгыз тагын...

– Танымаска... Күп нәрсә истә... Нур абыйның ишектән кайтып керүгә сезгә карап балкып елмайганы да истә калган әле.

– Нур абыегыз китте шул инде... Мине ялгыз итте... Тыныч дөньяга күченде. Яфраклар шаулавы гына ишетелә анда... – Хатын карашын куе яшеллек ягына ымлады.

Равия апага бәйле тагын ниләрдер искә төшерергә тырышып азаплана торгач:

– Бәрәңгеле мич алдыгыз да хәтердә... – дип, мин сүзне янә ялгап җибәрмәкче булдым. – Һаман шулай күп әрчисезме сез аны?

Кеткелдәп бер көлде Равия апа. Көлүендә дә моңсулык хакимлек итә иде кебек.

– Күп әрчергә йортта кеше калмады бит. Кызларым икесе дә Казанда. Терлек-туар да юк хәзер. Менә төпчегем белән яшәп ятабыз икәүләп. Ул бәрәңгене бер дә өнәми шул... Берүземә ике-өч бәрәңге дә җитә минем. – Хатын беразга тын торды. Аннан: – Әнкәй мәрхүмә ярата иде инде аны. Син хәтерлисеңдер әле, сеңлем, – диде, миңа төбәлеп.

– Хәтерләмәскә... Һай тынгысыз иде дә соң мәрхүмә... Җәлли идем инде мин сезне...

– Нишләп җәлләдең икән мине? Авырый иде бит ул безнең әнкәй... Түзалмагач нишләсен инде? Бердәнбер килене ич мин аның. Аннан, үз әнием дә шулай чирләде. Ә мин аның бердәнбер кызы идем. Нур абыең көтте. Әнкәйнең кырыгыннан соң туй иттек без. Чирдән ачу алып булмый бит инде... Аңларга кирәк... Хәер, тыңларга кирәк. Авыруны дим... Башка ярдәм юк бит инде сау кешедән... Көн дә үлемгә табан бер адым атлаганда... Башка ни эшли алам инде мин? Риза-бәхиллекләрен алып калу да кирәк. Безнең яшисе бар бит әле...

Шул мәлдә арбадагы кызы ыңгырашып куйды. Равия апа аны икенче ягына әйләндереп яткырды.

– Нишлисең, Аллаһ мине ярдәмгә мохтаҗлар өчен җибәргәч... Язмышың шул булгач, нишләмәк кирәк...

Мин бу сүзләрдән дертләп киттем. Бер мәлгә өнсез тордым. Сүзне икенче юнәлешкә борып җибәрмәк булып:

– Равия апа, сезнең бакча бәрәңгеләре һаман шулай кап-карамы ул? – дип сорадым.

– Ю-у-у-к. Башка төр орлыклар кайтардылар безгә. Бернинди балчык та ябышмый аңа, комда үскән кебек, сап-сары хәзер безнең бәрәңгеләр, – диде ул, гариплләр арбасын этеп китеп барганда.

Минем күз алдымда әле кап-кара, әле сап-сары бәрәңгеләр тәгәрәште. Кеше язмышлары кебек...



Рәсем: Наталья Васильева

ӘЙЕ, ЫЗАНДАШ КҮРШЕЛӘРЕ БЕЛӘН ТАТУ ЯШИ БЕЛМӘГӘН КЕШЕЛӘРНЕ АҢЛЫЙ АЛМЫЙМ МИН. ЧӨНКИ БӘЛӘКӘЙДӘН «КҮРШЕ» ДИГӘН КЕШЕЛӘРНЕ ТУГАНЫМ КЕБЕК КҮРЕП ҮСТЕМ.

Асия
ГАЛИУЛЛИНА

КҮРШЕ ХАКЫ

«Күрше хакы – тәңре хакы» дигән халык мәкале дә бик борынгы булырга тиеш. «Алла хакы» дип яңартылуы соңрак замандадыр. Авылда һәр тарафтан җиде өйгә кадәр (кайберәүләр кырык өйгә кадәр, ди) сиңа күрше санала. Мин үзем күршелек бер чакрым арадан ерак булмаска тиеш дип уйлыйм.

Нигә шулкадәр хокуклары зур соң ул күрше булып яшәгән кешеләрнең. Җавабын беләм дә кебек. Синең белән янәшә утырып дәрес тыңлаган яки бер табында тәгам җыйган кеше ул әле күрше түгел. Ул нибары партадаш, табындаш, юлдаш кына... Ә күрше ул бер чакыруга (чакрым сүзе шуннан) янәшә атылып-бәрелеп килеп җитә торган кеше. Чакыру, өн салу тәмле ашка да, туйга да, ярдәмгә дә булырга мөмкин. Ә бит әле ут күршеләр дигәне дә бар. Болары инде соңгы сыныгыңны бүлешә, иң яшерен серең сыя, үз учагыннан синең соскыңа кузкүмер алып бирә торган кешеләр.

Без авылда тормышны күршеләр белән алып бардык. Репрессияләр шаукымы тигәнгә күрә туган-тумачабыз юк иде. Аннары элек авыл укытучыларына бер урында озакка тамыр җибәрү өчен юл куелмаган. Шуңа күрә күршеләрнең кадерен белә идек без. Үзебез дә аларның кадерен дә, рәхәтен дә күп күрдек. Хәтеремне күпме генә бимазаласам да, юри генә дә бер начар күршебезне искә төшерә алмыйм. Әй ул авылның күркәм әхлагы! Бер баланы да читкә тибәрмичә үз баласы кебек тәрбия кылуы! Әй ул күршеләрнең ярдәмчеллеге!



Бәрәңге ала башласак, арт урамдагы (бәрәңге бакчасы шунда чыга) күршеләрнең балалары кәрәк тотып кереп җитәрләр иде. Сарык йоны кыркыйсы булса, сарыкларыбызның көтүгә чыкмый калганын абайлаган каршы як күршебез Хәтирә апа без торып чыкканчы ук йон кыркырга керешер иде. Кунак-фәлән чакырсаң, Хәмидә апа мич ялкынында табада төш биетер иде. Хәкимәттәй соң, Хәкимәттәй – үзе бер хәзинә!

Элек бит ул хәзергедәй савытсаба мул түгел иде. Ә күңел киң – кунак күп һәм еш чакырыла. Шуңа күрә өстәл-урындык, савытсаба урам аша өйдән өйгә йөреп кенә тора. Хәкимәттәйнең ак яулыгы белән киң күлмәк итәге дә ике арада бик җәһәт җилферди. Әбекәй кышын-җәен яланөс. Әнә шулай күрше мәшәкатьләре белән дә илһамлана белә иде ул. Күрше хакының олы хак икәнен дә шул Хәкимә әбинең гамәлләре төшендергәндер дип уйлыйм. Бакчасында өлгергән чияне беренче булып авыз итәргә безгә кертә иде ул. Шулай итеп, тәмле әйбер күршең белән бүлешеп ашасаң гына тәмле була икәнлеген төшендерде. Без дә аны коймактан, мунчадан калдырмадык. Минем әти аның армиядәге улы белән хат алышып торды. Иртән, дөньяга күзне ачуга, ул безне Хәкимәттәйнең тәрәзә капкачларын ачарга кертеп җибәрә торган иде. Бу бит бер очтан күрше әбинең исәнлеген белешү дә булган.

Казанда яшәгәндә дә җандай якын күршеләрдән уңдым. Үз кыланышларыбыздан үзебез көлә торган идек. Ике этаж арасында өчпочмаклы тәлинкәләрне алмашу кызыкның да кызыгы бит инде. Балалар да күршеләребез безнең туганнарыбыздыр дип уйлап үсте. Урыс кызы Оляның, чуаш малае Сережаның, татар кызы Ләйсәннең Тәскирә апаны бүлешә, ягъни аның кемнең бертуган апасы икәнлеген ачыклый алмыйча елашып беткәннәрен хәтерлим әле. Тәскирә апага алар барысы да газиз иде. Олясын да, Илшатын да, Ләйсәнен дә мәктәптән каршылый, алар белән утырып рәсем ясый, туган көннәренә бүләк әзерли, аларга багышлап гөл үстерә, күз яшьләрен сөртә, серләрен тыңлый.

Әнә шулай ризык һәм сер бүлешеп, бүтән подъездагыларны көнләштереп яшәдек без. Тәскирә апабыз юк инде хәзер. Без дә таралыштык. Кайда яшәсәм дә, халыкның, күршең үзеңнән яхшы булсын, дигән сүзләрен истә тоттым – күршеләрем өчен яхшы күрше булырга тырыштым.



«БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ»

Әхмәт
РӘШИТОВ

Минем әти белән аның атасы ничек дуслашканнардыр – белмим. Нишләптер, аларга бик еш бара идек без.

Шулай да Нуретдин абый белән бер табында утырганда, әти, көлемсерәп, болай диде: «Бигрәк шаярышалар бу балалар. Әйдә колакларын тешләтик әле. Минем малай – кияү, синең кызың кәләш булып китәр, бәлки».

Шаяру шаяру инде, мин аның кызының колагын тешләгәнмен. Шуның белән эш тә беткән.

Бу хәлгә мин бөтенләй игътибар итмәгәнмен. Әти дә уенга гына санаган. Шунысы бар: без ул кыз белән бер класста укыдык. Тәнәфес вакытында кызлар белән шаярасың инде. Аңа бер заман күзем төшкән бит. Ничектер аңлашырга кирәк. Бусы инде чынлап.

Шулай бервакыт Октябрь бәйрәме уңаеннан дәресләрдән соң икебез дә репетициягә йөрибез. Шунда аңлашырга исәп. Ләкин менә бәла: дәресләр тәмамлануга, сеңлесе килә дә житә – кайда ул сөйләшү-аңлашу! Хатны болай гына тапшырып булмый. Бер көн үтә, ике, өч көн... Аннан тәвәккәлләргә булдым. Хатны, җаен туры китереп, Розалиянең учына салдым. Бер сүз дә әйтмәде. Сеңлесенең генә бик беләсе килә – тыкырдата апасын. Ләкин минем ул мәхәббәт хатлары язуларым озакка сузылмады.

Беренче мәхәббәт

Хәтердә ул тыныч айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы.
Онытылмый беренче саф мәхәббәт,
Онытылмый Агыйдел сылуы.

Ул мине утларда яндырды да,
Тилмертте аерылу газабы.
Нигә соң чәчәктәй саф сөюнең
Кавышу булмады азагы?

Юлларда киртәләр очратсагыз,
Күңелегез булса нык яралы.
Сез искә алыгыз яшьли сөйгән
Беренче яраткан ярларны.

Розалия дә бик ашкынып тормый иде бугай – минем беренче мәхәббәтем бераз гына пыскыды да сүнде. Барып чыкмады, ахрысы.

Инде заманалар үтеп, университетта укый башлагач, бөтенесе башкача булып чыкты. Бер заман дус егет белән кызлар янына киттек. Аңа рәхәт: яратып йөргән кызы шунда. Ләкин ул кыз иптәшләре белән киногa киткән булып чыкты. Ә бүлмәдә бөтенләй башка бер кыз утыра. Дус егет телгә оста – сөйләштерепме-сөйләштерә. Анысы да чая күренә!

– Иптәшең нигә бер дә сөйләшми? – дип ычкындырмасынмы! Оялудан кызарып чыктым. Нәрсәдер мыгырдандым бугай шунда. Барыбер сүзгә кушылып китә алмадым. Күрешү шуның белән тәмамланды. Гап-гади очрашу иде инде ул. Тик әллә нәрсә булды бит миңа. Күңелдә әллә нинди бер хис кабынды. Их, танышасы иде шул кыз белән! Озак уйлап тормадым – берүзем киттем янына! Дус кешегә әйтү юк.

Бу юлы да ул үзе генә иде. Укыган җиреннән бер генә күтәрелеп карады да тагын китабына чумды. Ә мин, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырап басып торам. Уңайсыз инде. Аннан... Каян килгәндер ул кыюлык?!

– Сез кирәк идегез миңа, – дидем...

Таныштык. Аңлаштык. Актаныш ягыннан, Агыйдел буйларында үскән сылукай икән. Шаян үзе. Көлеп кенә сөйләшә. Ул да беренче күрүдә үк ошаткан икән мине. Кыз бала бу хакта башлап әйтә алмый бит инде! Уйнап-көлеп сөйләшүдән әнә шулай йөреп киттек. Кайчак сүзгә килеп, үпкәләшеп тә бетә идек – тик тирәнгә җибәрмәдек. Яраттым мин аны.

Шулай матур гына йөргәндә, көннәрдән бер көнне ул тиз генә җыенып Актанышына кайтты да китте: абыйсы белән ниндидер күңелсезлек килеп чыккан ди. Көннәр үтте, атналар... Ә ул юк та юк! Ни хәбәре, ни үзе! Мин газапларга чумдым. Инде тәмам өметемне өзгән идем... Хаты килеп төшмәсенме! Минем хакта авыр хәбәр ирештергәннәр, ул кайдандыр егылып төшеп үлгән, дигәннәр. Һәм көтмәгәндә радиодан тавышымны ишеткән! Сөенечтән хат язарга утырган...

Бераздан ул кабат Казанга килде. Сагынышып күрештек. Бауман урамындагы «Балалар дөньясы» кибетендә эшли башлады. Минем студент тормышы, китаплар, шигърият ошый иде аңа. Университетка имтиханнар да тапшырып карады – укырга керергә баллары җитмәде... Ә мине университеттан соң Апас районы газетасына эшкә җибәрделәр. Очрашулар сирәгәйде. Берчак эш буенча Казанга бару җае чыкты. Ә миңа шул гына кирәк – йомышларны үтәп бетергәч, очтым гына кыз янына! Әнә үзе дә! Горур, чибәр!.. Чү, эше тыгызмы соң – рәтләп сөйләшми дә... Халык та байтак иде бугай. «Теге урында, сәгать сигездә...» – диде дә эшен дәвам итте.

Мин ул көнне Апаска кире кайтмаска булдым. Редактор сүксә сүгәр инде – түзәрмен. Әйткән вакытка барып бастым. Килде. Ике гашыйк бергә очрашкач нәрсә буласы билгеле инде... Аерылыша алмыйча, бер-беребезгә сыенып, озак йөрдек кичке Казан буйлап.

Танышларыма кайтып кундым. Иреннәрдә – аның җылысы, күз алдымда – сурәте...

Редактор бер тузынып алды да тынды. Кайчакларда гына: «Кылны кырыкка ярыр чакта», – дип ачуын чыгаргалады.

Мин – монда, ул – анда. Һәркем үз эшендә, үз дөньясында. Ул заманда тора салып Казанга да чыгып чабып булмый. Аралар ерак. Хәбәрләшкән дә юк. Ул матур кыз образы җанда гына күңелне ымсындырып яшәвен дәвам итә.

...Бераздан районны бетерделәр. Безнең газетаның да кирәге калмады – кире Казанга кайтырга туры килде. Мин аптырау хәлендә, эш эзләргә кирәк. Көч-хәл белән телестудиягә урнаштым. Һәм бер көнне эшкә барганда... Ул! Үзе! Мин тораташтай катып калдым. Кулына зур сумкалар күтәргән, үзе йончыган... Ике-өч адым алдан ире атлый. Мин гомер буе хыялланган кыз ир хатыны булып яннан узып бара. Ул да күрде мине – керфеге дә селкенмәде. Боздай салкын карашы белән коендырып, үз юлыннан китте...

Мин аны башка бер тапкыр да күрмәдем. Күңелне юатырлык бер җыр гына калды. Ул – минем «Беренче мәхәббәт» шигыремә Сара апа Садыйкова язган җыр.

ИГЪТИБАР

Җанга якын кадерле кешеләрегезне бөтен дөньяга ишетелерлек итеп котларга теләсәгез, «Сөембикә» журналы сайтында (www.syuyumbike.ru) моның өчен махсус котлау тәрәзәсе булдырдык. Якыныгызны сөендерәчәк сүзләрне язып, фотосы белән бергә редакция адресына юллагыз. Котлау хакы – 300 сум. Акчаны журналның исәп-хисап номерына күчереп, түләү кәгазенең күчермәсен хат белән җибәрегез.







НӘФРӘТТӘН МӘХӘББӘТКӘ... МАРАФОН

МИН БЕРКАЙЧАН ЙӨГЕРЕРГӘ ЯРАТМАДЫМ. МОНЫҢ СӘБӘБЕН БИК ЯХШЫ БЕЛӘМ, БИЛГЕЛЕ.

Үземне хәтерли башлаганнан бирле, әтием безне — энем Нариман белән мине иртән йөгерергә алып чыга иде. Бер көн калмыйча! Кышын да, җәен дә, яңгырда да, карда да... Йөгерәсе түгел, атлыйсы килмәгән чакларда да. Мәктәпне тәмамлап, өйдән чыгып киткәнче шулай булды... (Студент вакытта да кайчак иртәләрен йөгергәләдем анысы: «кирәк» дигән нәрсә башта нык утыра иде! Тик теләгәнгә түгел, моны батырлык дип санаганга, үз-үзем каршында азрак «үсеп» китәсе килгәнгә генә.) Энем йөгерүне яратып калды, ә мин юк. Бәлки, миңа йөгерүнең иртән булуы гына ярап бетмәгәндер? Кечкенәдән тазарак бала булсам да, гомер буе актив идем бит мин. 5 яшьтән 17 яшькә кадәр биедем – балет мәктәбен тәмамладым. Мәктәп данын яклап, чаңгы ярышларында катнаштым. Футбол уйнадым. Гомер буе аэробикага, фитнеска йөрдем.

Йөгерүнең нәрсә икәнен онытkan идем инде. Беркөнне энем эштән кайтты да яңалык сөйли: «Шундый мәктәп таптым, анда җиде атнада ярыммарафонда йөгерергә әзерлиләр», – ди. Бер кич сөйләде, ике... «Без дөрес йөгермибез икән, умыртка баганасына көч китермәс өчен чапканда үкчәгә түгел, аякның алгы ягына басарга кирәк», – ди, интернеттан роликлар күрсәтә. Бер көн тыңладым, ике көн... Өченче көнне түзмәдем. «Энем, әкият бу, гомер буе йөгердең, фәнни яктан якын килеп, өйрәнеп шөгыльләндең – сине әзерлисе юк. Күзең Казанда узган ярыммарафонда үз яшең төркемендә махсус әзерләнмичә дә беренче килдең! Менә бер йөгермәгән кешене, мине әзерләп карасыннар алар!»

Йокларга яттым, сизәм, йоклый алмыйм. Иртәгәсен эштә дә үземне һаман нидер борчыганга игътибар иттем. «Мине әзерләп карасыннар!» – дидем бит мин... Шул кичне үк энемә: «Мин синең теге клубың белән элемтәгә кердем, – дидем. – Акчаны түләдем. Беренче тренировка кайчан?» Энем шаккатканын сиздермәскә тырышты: үзе артыннан ияртергә теләсә дә, максатына шулай тиз ирешермен дип уйламаган иде бугай ул. Хәер, минем холыкны чамалый инде ул.

«ILOVERUNNING» – энем белән без язылган дөрес йөгерү мәктәбе шулай дип атала. «Мин йөгерергә яратам» дип тәрҗемә ителсә дә, аны... минем кебек үк йөгерергә яратмаучылар оештырган. Башта яратмаучылар! Беренче тренировкага безнең белән очрашуга килгән Максим Журило бу хакта бик кызык итеп сөйләде. «Мин гап-гади бер егет идем, – диде ул. – Тәмәке тарттым, эчкәли дә идем. Аннан кинәт бер көн: «Үземне формага кертергә кирәк», – дигән нәтиҗәгә килдем. Йөгерә башладым. Әмма ай ярым дигәндә ташладым. «Ихтыяр көчем шулай бер дә юкмыни икән минем?» – дигән уй үзалдыма максат куярга этәрде. Нью-Йоркта узачак марафонда йөгерәчәкмен! 48 мең катнашучы белән бергә! Әмма бу марафонга эләгү бер дә җиңел булмады, минем кебек теләк белдерүчеләр 300 меңнән артык иде. 2009 ел иде бу. Җиттем финишка! 17 килога ябыктым – югыйсә үземә мондый максат куймаган да идем. Нью-Йорктан кайткач, Мәскәүдә халыкның йөгерү белән бөтенләй шөгыльләнмәвенә игътибар иттем. Нидер үзгәртәсе килеп, дусларым белән Горький исемендәге паркта ярыммарафон оештырдык. Безнең белән 800 кеше йөгерде! Шул вакыт ун кешенең тугызы дөрес йөгермәвенә игътибар иттек тә инде. Дустым Владимир Пасекунов белән (йөгерергә ярату миннән аңа да йогарга өлгергән иде инде): «Без бит аларга ничек дөрес йөгерергә икәнен өйрәтә алабыз!» – дигән фикергә килдек. Хезмәттәшем Ирина Московкина да безгә кушылды. «ILOVERUNNING» клубы шулай туды. Безнең программа җиде атнага сузыла: кешегә шушы вакыт эчендә кайчан һәм нәрсә эшләргә тиешлеген күрсәткән календарь төзеп бирәбез. Ахырда һәркемне бер максат көтә – нинди дә булса бер ярыммарафонда катнашу. Хәзер клубыбызның уннан артык шәһәрдә филиалы да бар инде».

Максимның да, Володя белән Иринаның да күзләре янып, балкып тора. Буй-сыннары матур. Йөгерү аларның тормышын кискен үзгәрткән – «ILOVERUNNING» өчесе өчен дә төп эшкә әйләнгән.

Тренер белән дә таныштык. Ирина Борисовна Подъяловская – Дөнья чемпионы, Дөнья рекордсмены, кайчандыр йөгерү буенча Советлар Союзының җыелма командасына кергән. Сиксәненче елларда 800 метрга йөгерүдә дөнья күләмендә рекорд куйган, һәм аның бу рекордын бүгенгәчә яңарткан кеше юк! Менә кем безне йөгерергә өйрәтәчәк!

Группадагыларны күзәтәм: егерме биш кеше арасында мин иң олысы. «Безнең янда бу апа нишләп йөри инде?» – дип сәерсенеп караулары сизелмәде үзе.

Хыялсыз кеше, канатсыз кош кебек.

Беренче тренировкалар бик җиңел тоелды: 20 минут йөгерәбез, 5 минут ял итәбез. 25 минут йөгерәбез һәм тагын ял итәбез... Тренер бертуктаусыз: «Әкрен йөгерергә кирәк. Бер-берегез белән сөйләшеп барырлык булсын. Пульс 145 тән артмасын», – дип кабатлап тора. Безнең тренировкалар Олимпиада алдыннан 1979 елда төзелгән «Крылатское» велотрегында уза. Россиядә шуның кадәр кеше велоспорт белән шөгыльләнә дип күз алдыма да китерми идем моңарчы! Беренче мәлләрдә үзем йөгердем, үзем гел шул велосипедчыларны күзәттем. Аста балалар теннис уйный, өстә без йөгерәбез – велотрек казан кебек кайнап тора.

Атна азагында электрон почтама клуб исеменнән хат килеп төште: «Котлыйбыз! Беренче атна тәмам!» – дигәннәр. Һәм шунда ук икенче атнага бурычлар куелган, күнегүләр күрсәтелгән. Телефонымны исә «смс»-хәбәрләргә күмделәр: йөгерү турында бу кадәр афоризмны кайдан табып бетерәләр! Ә шулай да безне йөгерергә рухландырган иң зур мотивация, иң зур дәлил – җиде атнадан Барселона шәһәрендә (Испания) ярыммарафонда катнашу иде. Клубка йөри башлагач кына белдем – дөнья буйлап атна саен кайдадыр марафоннар уза икән: Барселона, Рим, Вена, Париж, Берлин, Будапешт, Нью-Йорк, Люксембург, Лиссабон... 2015 елда марафоннар узачак кайбер шәһәрләр исемлеге бу. «Безнең өчен түгел икән», – дияргә ашыкмагыз. Әлбәттә, бөтен кеше дә чит илгә барып йөгерә алмый. Безгә иң беренче дәрестә үк: «Барселонага бармый калучылар өчен шул көнне ярыммарафонны Мәскәүдә оештырабыз. Шул ук дистанцияне йөгерәсез», – диделәр.

Йөгерә башлагач, бер нәрсәне аңладым: мин үземә йөкләнгән эшне бик төгәл үтәүче кеше икән. Шулай икәнен чамалый идем анысы, ләкин бу дәрәҗәдә дип



■ Йөгерү – максат куярга һәм аңа ирешергә өйрәтә. Спорт белән физкультураның аермасы да шунда-дыр: физкультура белән максатсыз гына шөгыльләнәсең. Ә икенче очракта «кәеф юк» яки «яңгыр ява» дип йөгерми калып булмый – билгеләнгән ярышка санаулы вакыт калган.

■ Бүген клубтан «смс» килде: «Безнең төп кимчелегебез шунда, кайбер нәрсәләрне эшләү урынына, алар турында сөйләшүне өстенрәк күрәбез. Джавахарлал Неру». Миңа бик тә таныш бу. Йөгерә башлаганда: «Йөгерү умыртка бага-насына, буыннарга көч китерә. Шәһәрдә йөгерер өчен һава да бик начар, үзеңә зарар гына салырсың», – диючеләр күп булды. Минемчә, үзләре урыннан торып йөгерә башламас өчен сәбәп кенә эзли иде алар.

■ Йөгерү ул, әлбәттә, энергия чыганагы. Беренчедән, физик энергия: күпләребез тормышта аз хәрәкәтләнә; икенчедән, эмоциональ энергия: җиңү шатлыгы – иң көчле тәэсирләрнең берсе; өченчедән, менталь энергия: үзең генә калып, уй-фикерләреңне тәртипкә китерергә менә дигән вакыт.

уйламый идем. Эштә ул минем өчен зур плюстыр. Ә бу очракта... Тренер кушканның бөтенесен үтәп, хәтта артыграк та үтәргә тырышып, бер айдан аяксыз калдым. Әле берсе шешә, әле икенчесе... Табиблар: «Артыгын тырышкансың», – диделәр. Тренировкага барам, йөгерә алмыйм – аяклар сызлый.

Шактыйдан йөгергән, нәтиҗәләргә ирешкән кешеләр: «Фикерләү үзгәрә», – диләр. Күпләр, йөгерә башлагач, үз эшләрен оештыра.

Ирина Борисовна: «Тиз-тиз атлап йөр, йөри алмыйсың икән, күнегүләр яса», – диде. Берсендә тренировка вакытында түзә алмыйча елый-елый атлап барам шулай. Тренер туктатты да: «Нәрсә булды?» – ди. «Билетым алынган, ә мин Барселонага бара алмаячакмын. Шулкадәр аяныч!» – дим. «Ә нәрсә булган? Йөгерә алмыйсың икән, барабыз да ял итеп кайтабыз. Хәзер исә тыңла, мин сиңа «аяныч»ның нинди булганын сөйлим, – диде Ирина Борисовна. – Сиксәненче елларда рекорд куйдым. Мин дөньяның иң яхшы йөгерүчесе! 1984 елгы Олимпиадага әзерләнәм – анда беренче булырга тиешмен! Һәм шул вакыт бөтен социалистик илләр Лос-Анджелеста узачак Җәйге олимпиадага бойкот игълан итте... Спортчы өчен тагын дүрт елның ни икәнен күз алдыңа китерәсеңме?! Спортта карьерам шуның белән тәмамланды... Ә синең Барселона булмаса, башкасы булыр. Үзең өчен йөгерәсең ләбаса, моңардан рәхәтлек алырга тиешсең».

Рәхәтлек алырга... Уйланып калдым. Безнең тормыш шулкадәр бер эзгә салынган хәзер: эшкә барабыз, кайтабыз – яңа тәэсирләр юк диярлек. Ә монда яңалыклар бихисап минем өчен. Йөгерү – үзе яңалык! Укыган китаплар да хәзер йөгерү турында. Иртәгә марафон дигән көнне паста-пати оештырдылар. Углевод туплау дип атала ул. Ресторанга бергә җыелып макарон ашау, беләсезме, ничек күңелле булды?! Минем сәяхәт итәргә яратуыма да бу яңа мәгънә өсти: төрле илләрне йөгереп карап үтәсең – марафон трассалары шәһәрләрнең иң төп урамнарыннан уза.

Берьюлы 15 мең кешенең йөгерүен күз алдына китерәсезме? Моны ничек оештырып була дип аптыраган идем. Чын бәйрәм булды ул! Теркәлү узганда күпме вакыт эчендә финишка килеп җитәргә ниятләгәнеңне күрсәтәсең – группалар шуңа карап туплана.

Менә беренче группа стартка кузгалды! Музыка уйный, фейерверклар ата, диджей бертуктаусыз нидер сөйли... Эйфория! Күңел тулды! (Алга китеп булса да әйтим: бу ярыммарафонда өч Дөнья рекорды куелды! Һәм мин шул атаклы спортчылар белән бергә йөгердем!) Минем кебек беренче тапкыр катнашучылар иң соңгы төркемдә. Кызлар белән: «Тренер ничек өйрәтте, шулай әкрен генә йөгерәбез, ашыкмыйбыз», – дип сөйләштек. Ара-тирә пульсны караштыргалыйм. Тәртип! Трасса кырыенда барабанчылар тора, дәртләндерәләр – яннарыннан узганда кул чабам. Юл читендәге тамашачыларга кул болгыйм, балаларга кул кысам. «Нинди матур йортлар, нинди матур балконнар!» – дип кызларга күрсәтәм. Оркестр уйнап тора – аларны сәламлибез. Бер урында җырлыйлар – тагын кул чабабыз. Кызларның берсе марафонның кайдан килеп чыкканын сөйли... Беренче биш чакрымны шулай үттек. Кайберәүләр инде трассадан төшеп кала башлады. Беренче су эчү урыны оештырылган җиргә җиттек. Суны бер йотуга, икенче өстәлдә кола стаканнары күреп алдым. «Марафонны йөгерергә кола бик ярдәм итте», – дип укыган идем. Кулымдагы сулы стаканны ташладым, тик «кола» дигәнем нindидер зәңгәр су булып чыкты... Алдагы биш чакрымны сусыз йөгерергә туры килде. Чакрым саен дистанция-

не күрсәткән багана тора. Сигез чакрымнар бергә баргач, Полинага әйтәм: «Син безне көтмә инде», – дим. Ул алга йөгерде. Тугыз чакрым узгач, тагын бер кыз алга китте. Ун чакрымга мин үзем генә барып җиттем. Әллә үзем генә калганга, никтер авыр була башлады. Инде кулны да азрак болгыйм. Балконнарга да бик карамыйм. Унбиш чакрым булды дигәндә, бер таныш кызны куып җиттем. Шактый ара икәү бергә йөгереп бардык. Авыр... Хәл тәмам бетте... Унсигез чакрымга җиткәндә янымда Оляны күрми башладым. «Алга киткәндер», – дип уйладым. (Мәскәүгә кайткач телефоныма аннан хат килде: «Рәхмәт, Гөлнара! Беренчедән, күрәгәң бик ярдәм итте. (Дистанциядә ашыйсы килсә дип, күрәгәләр алган идем – кызларны да сыйлап бардым.) Икенчедән, синсез безгә күңелсез һәм кыен булыр иде. (Нишләтәсең, күп сөйлим инде мин...) Өченчедән, маршрут ахырында син алга йөгереп киткәч, шундый горурландым үзең белән!» Шунда гына белдем: ул мине түгел, мин аны узып киткән булганмын!)

Унтугыз чакрым... Йөгерәмме, атлап кына барам-мы – тоймыйм. Әмма алга таба хәрәкәтләнәм. Шул вакыт юл читендә басып торган бер бабайның: «Гуль! Гуль!» – дигәнен ишетеп алдым. Испанча нәрсәдер әйтә. Миңа дәшә бит ул! Күкрәктәге номерга язылган «Гульнара» дигән сүзнең аңа, мөгаен, яртысы гына күренәдер. «Гуль! Тагын бераз гына тырыш! Инде күп калмады!» – диюедер. Бер белмәгән кешенең шулай миңа көч бирүе хәл өстәгәндәй булды. Финишка чыккач, ниһаять, энемнең тавышын ишеттем: «Апаем! Апаем!» Финиш сызыгын ул биргән Татарстан байрагын күтәреп уздым. Группадашлар кул чабып каршы алды – соңгы айны аякларым белән ничек тилмергәнемне барысы да белә.

Булдырдым! Мин ярыммарафонны йөгердем! Егерме бер чакрым! Финишка килүгә кызлар чипны салдырды (аны тапшырмасаң, марафонны үттең дип саналмый). Икенче кордондагы кызлар муенга медаль кигертте – МИН ҖИҢҮЧЕ! Өченче кордонда – плащ бирделәр (тирләп йөгереп килгәннән соң, бик тиз туңа башлыйсың). Аннары иң тәмле кордонга җиттем: өстәл-өстәл җиләк-җимеш, сулар... «Саклау камерасы» урнашкан бинада – аны элеккеге вокзал, диделәр – бик күп өстәлләр куелган: теләгән һәркем массаж ясата ала. Кирәксенмәдем. Йөрсәң, аяклар языла, утырсаң – катып китә. Без энем белән ул кичне 100 мең халык сыйдырышлы стадионда узачак матчка билет та алган идек әле. «Барселона» төркеме уйный. Минем яраткан футболчым Лионель Месси!

Барселонага без ике группадан 30 кеше бардык. Ә Россиядән барлыгы 90 йөгерүче катнашты. Әлбәттә, зур ил өчен бу аз. Әмма йөгерү безнең тормышка яңа кереп килә генә. Йөз еллык тарихы булган атаклы Бостон марафоны бар: башта анда да 15 кеше генә йөгергән, ә хәзер кырык меңгә якын кеше катнаша. 500 меңнән артык җанатар гына була. Бик теләсәң дә эләгеп булмый әле аңа – моның өчен башка марафоннарда йөгереп нәтиҗә күрсәтергә кирәк.

Без ни өчен йөгерәбез? Һәркемнең үз максаты бугай. Мәсәлән, энем, ярыммарафонны билгеле бер вакытта үтәргә омтыла, ул аның өчен зуррак максатларга ирешергә ярдәм итүче бер баскыч кына. Мин үземә ошамый торган нәрсә белән дә шөгыльләнә алуымны үз-үземә исбат итәргә теләдем. («ILOVERUNNING»га бер ай йөргәннән соң, әтиемә әйтәм: «Мин әле һаман йөгерергә яратмыйм», – дим. «Кызым, утыз еллык нәфрәт алай тиз генә мәхәббәткә әйләнми инде», – диде ул көлеп.) Кызым Бану: «Быел укуны тәмамлыйм, Мәскәүдән китсәм, мондый атаклы тренерларда шөгыльләнергә мөмкинлек булмаячак», – ди. Миннән күреп, дөрес йөгерү мәктәбенә бер хезмәттәшем язылды. Максаты – тәмәке тартуны ташлау. (Киметте инде!) Ә аның бездән ишетеп Санкт-Петербургтагы мәктәптә шөгыльләнә башлаган дус кызының үз максаты: ул пар табарга тели. Һәм аны беренче тренировкадан ук озатып кайтканнар инде!

...Барселонадан кайтуга «ILOVERUNNING»га... кабат язылдым. Венада узачак ярыммарафонда катнашырга әзерләнүче төркемгә. Беренчедән, анда кызым Бану йөгерергә җыена – мин аңа терәк булып барырга тиеш. Икенчедән, соңгы айны тулы көчемә шөгыльләнә алмадым – үземне тагын бер кат сынап карыйсым килә. Аннан... ошап китте йөгерү!

Максатка ирешү күңелгә канат куя: «Алга таба тагын нишли алам икән?» – дип уйлыйсың. Әле интернеттан эзләп таптып – йөзүчеләрнең «Мин йөзәргә яратам» дигән мәктәбе бар икән...

Гөлнара ЗЫЯТДИНОВА.
Мәскәү.

РЕКЛАМА

Школа правильного бега
I LOVE RUNNING – это более глубокое погружение в мир бега: улучшение твоей скорости и спортивного результата!

I ❤ RUNNING

● Семь недель обучения в I LOVE RUNNING – это работа над силой, выносливостью и техникой бега с профессиональным тренером по программе лучших мировых специалистов в области биомеханики.

● С командой единомышленников ты поедешь в Европу, пробежишь яркий полумарафон или марафон и получишь медаль победителя.

● Во время марафона мы даем шанс городу показать нам самые красивые его места и достопримечательности всего лишь за пару часов.

ПРЕКРАСНАЯ ВОЗМОЖНОСТЬ УВИДЕТЬ МИР И НАЙТИ НОВЫХ ДРУЗЕЙ

+7 (960) 049 – 9498 / kzn@iloverunning.ru

16+

ХИСЛӘР ИХЛАС БУЛГАНДА...

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Газинур МОРАТ, шагыйрь; өйләнгән; гаилә стажы — 31 ел; бер малай атасы.

Ә мин сине яратмаска булдым

Ә мин сине яратмаска булдым,
Яңартмаска булдым үткәнне.
Мәңге әрнер яраң булып калсын
Күзләреңнән сөеп үпкәнем.

Мәңге әрнер яраң булып калсын
Иренемә тамган яшьләрең.
Син үзеңчә дөрес сөеп кара,
Мин үземчә дөрес яшәрмен.

Мине көтеп тик ялгыша күрмә,
Йөрәгеңнән ыргыт чыгарып.
Ходай сиңа сабырлыклар бирсен
Сак-Сок сагышына чыдарлык.

Мин дә сине сагынмаска булдым,
Табынмаска булдым мәңгегә...
Сөюгә мин ясин чыктым бүген,
Кем озата барыр кабергә?

Озатучы, беләм, табылачак,
Кем ябышыр, беләм, көрәккә.
Тик мин сине борчымаска булдым,
Мин Сөюне күмдем йөрәккә.

1 Иң элек син хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсең: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

Гәрчә халык әйтеме, чибәрлек туйда гына кирәк дип искәртеп торса да, ир-ат халкының күзе иң әүвәл барыбер да хатын-кызның йөзенә төшә. Нишлисең, табигать хатын-кызны гүзәл итеп яраткан шул. Шуңа күрә күпләребезнең гомере тышкы матурлыкка алданып уза да инде. Асылда, безнең бәхет тә, бәхетсезлек тә, чибәр чырайга багынып, аһ итүдән, башны югалтудан башлана бугай.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

Гафу итәрлек тискәре сыйфатлар һәркемдә дә тулып ятадыр инде ул. Әйтик, без беребез дә гел дөресен генә сөйләп тормыйбыз. Дөнья булгач, ара-тирә алдашырга да туры килә. Дөресен генә әйткәндә, адәм баласының табигате үк шуңа көйләнгән. Өстәвенә, гаиләнең иминлеген саклау өчен дә кирәкле шәйдер бу. Никахның нигезен какшатмый торган вак-төяк ялганга сабыйларча ышанып яши алу сәнгате хатын-кызны да, ир-атны да бизи генә, минемчә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идең?

Хатын-кыз, беренче чиратта, ир-атның тылын сакларга бурычлы. Хәрбиләрчә әйткәндә, әгәр ул, сакта торган килеш, үз белдеге белән «самоволка»га китеп бара икән, аны, билгеле, трибунал көтә. Бу очракта ярлыкауга исәп тоту да шактый кыендыр.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: җыештыручылар һәм пешерүчеләргә. Сиңа аның кайсы якынрак?

Күңелемә һәр икесе дә бик якын. Хатын-кыз һәм җыештырына, һәм пешерене белсә, тормыш та көйлерәк

барадыр. Әмма бу шөгыльләрнең берсен дә үз итмәүче ханымнар да юк түгел дип беләм.

5 **Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?**

Заманында бер язучыбыз, «хатыныма һәм дустыма» дип багышлау куеп, хикәя бастырды. Ул чагында бу янәшәлек безгә, ничектер, сәеррәк тоелган иде. Гомер чигә-чигә, күрәсең, хәләлең дә бервакыт, хатын булудан бигрәк, иптәшеңә һәм дустыңа әйләнәдер. Һәрхәлдә, яшьрәк чакта хатынны дуска тиңләмәү хәерлерәктер. Дус – ул мотлак тугрылык дигән сүз. Ә хатының көннәрнең берендә, киресенчә, дустыңнан дошманың булып китмәс дип һич тә кистереп әйтә алмыйсың.

6 **Хатыныңа ничек тәкъдим ясаганыңны хәтерлисеңме?**

Гомер буе бер хатын белән генә яшәмәгәч, бу сорауга тәгаен җавап бирә алмамдыр. Ә менә һәр икесенә дә шигырь багышлавым хак. Һәм алар альбом шигырьләре генә булып чыкмады бугай – барысы да китапта дөнья күрде.

7 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...**

Мин үзем әлеге фаразга ышанып бетә алмыйм. Әгәр без иш иткән ярлар гел әниләребезгә охшаса, илдә аерылышучылар саны кавышучыларныкыннан артып китмәс, дөньяда бу чаклы ятимнәр күбәймәс иде.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар...**

Бу очракта хатын-кыз үзенең күбрәк мал табуы турында иренә бертуктаусыз тукып, аның исенә төшереп торырга тиеш түгелдер. Бергә дөнья көтәргә ниятләгәнсең икән, ир-атның болай да авырткан җиренә кабат-кабат орынмавың хәерле. Үземә килгәндә, мин хатынымның күпме акча алып эшләве белән беркайчан да кызыксынмадым.

9 **Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсың?**

Бик уңай карыйм һәм биш куллап хуплыйм. Чөнки үзем әлеге мәсьәләдә мокыт дәрәҗәсендә оялчан булдым. Үсмер чакта ук гыйшык тоткан кызыйга да, телне әйләндереп, бер кәлимә сүз әйтә алмыйча, тәмам чаларып, олыгаеп барабыз менә.

10 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?**

Хатын-кыз иң башта ир-атның аяк киеменә һәм муен чокырына игътибар итә, диләр. Белмим, бу кадәресе ни дәрәҗәдә дөрестер, әмма һәр икесен дә чиста йөртергә тырышабыз.

11 **Хатын-кызлардан үзең игътибар көтәсеңме?**

Мин хәзер хатын-кызлардан игътибар көтеп утыру яшеннән узып барам инде, күбрәк үзләренә игътибар итәргә тырышам. Һәм бик еш кына:

Кызлар кызыклана барган саен
Кызыксызга чыга барабыз, –

дип авыр сулап куям.

12 **Ир-ат артык чибәр һәм көчле хатын-кыздан курка.**

Ихтимал, куркытадыр. Юкса үтә чибәр дә, акыллы да хатын-кызларның берсе дә ялгыз калмас иде. Ә парсыз гүзәлләр, нигәдер, һәрдаим очрап тора. Үзләренә яр табарга әллә чибәрлекләре, әллә акыллары комачаулый – белмәссең.

13 **Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.**

Икегә икене кушкач, дүрт икәнлеген ир-ат заты ачыклаган – бусы бәхәссез. Ә менә ике икең биш икәнлеген хатын-кыз гына дәлилли ала. Чөнки аның мантыйгында дөнья көтәр өчен бик тә кирәкле хәйлә микъдары зуррак. Бу сыйфат гүзәл затларыбызга тормыш авырлыкларын чагыштырмача җиңелрәк кичеп чыгарга да, сынмаска-сыгылмаска да булыша, аларны сабыр-түземле дә итә. Хәйләсез – дөнья файдасыз дигән тәгъбир дә әлеге «ике икең биш»не куәтли кебек.

14 **Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?**

Хатын-кызның хаксыз икәнлеген исбат итеп була, ләкин аның үзен шуңа ышандыру һич тә мөмкин түгел, дигән бер акыллысы. Мин үзем дә хатын-кыз белән сүз көрәштерүдән тыелам. Аз сүзленең гөнаһы азрак, ди безнең халык. Ул гаиләдәге һава торышына да турыдан-туры кагыла дип уйлыйм.

15 **Ир кеше, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатын, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора...**

Әлегә андый очракның булганын хәтерләмим. Булган тәкъдирдә дә, тиз генә бәрәңге яки йомырка кыздырып алу кулдан килмәслек эш түгел. Анысын студент чакта ук өйрәнгән идек.

16 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

Хатын-кызның төзәтенеп-ясанып беткәнен көтә-көтә көтек булганчы, үзеңә алдан киенеп куймау хәерле. Ул әрле-бирле әвәрә килгән арада хет газета караштырып, хет телевизор карап юан. Шул чагыңда ачуың да чыкмас, чәчең дә агармас.

17 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.**

Хатын-кыз кулыннан энәне дә, дөяне дә бердәй кабул итеп алам. Ә үзем, яшермим, бүләк сайлый белмим. Чөнки беркайчан да кибетләр буйлап сайланып йөрүне өнәмәдем.



ХЫЯНӘТ КАВЫШТЫРДЫ

Мәдинә КАШАПОВА

ӘЙТМӘДЕЛӘР ТҮГЕЛ, ӘЙТТЕЛӘР, КИСӘТТЕЛӘР. ӘММА УЛ БЕРСЕНӘ ДӘ ЫШАНМАДЫ. «КЕШЕ СҮЗЕ, – ДИДЕ. – УЛ АНЫ ГЫНА ЯРАТА, УЛ БЕРКЕМ БЕЛӘН ДӘ ЙӨРМИ».

Май урталары җитеп килә иде. Ул, ел да бер уянып, табигатьне кабатланмас сихри тылсымга күмгән матурлыкка сокланып бара торгач, тукталышын узып киткәнен сизми дә калды. Лекциягә соңга кала ич... Ай, исәр, дип, үзен тирги-тирги автобустан төште дә кире йөгерде. Институтка очып кына килеп керде, баскыч буйлап кабалана-кабалана икенче катка күтәрелә башлады. Шунда аягы таеп китеп, чак кына егылмый калды. Егыла иде инде. Тотып калдылар. Ул артыннан менеп килүче егетнең кочагына ауды. Шундук борылды һәм аның төпсез диңгездәй зәңгәр күзләренә карап, телсез калды. Егет кенә берни булмагандай: «Кая шултиклем ашыгасың, туташ?» – диде дә, Гөлчәчәкне минутында давыл булып купкан хисләре белән ялгыз калдырып, күздән югалды. Курсташ кызлары дәшмәсә, тора иде әле шулай тиле кебек.

– Кем ул? – дия генә алды кыз.

– Кемне әйтәсең? – диде иптәш кызы Айсылу.

– Әле генә, менә әле генә минем белән сөйләшкән егет...

– Ә-ә-ә, – дип сузып җибәрде кызлар берьюлы. – Сәлимне әйтәсеңме?!

– Башыңны катырма, синеке түгел ул. Ишетәсеңме?! – дип кырт кисте Айсылу. – Аны яратучылар күп монда...

Кыз аны әллә ишетте, әллә ишетмәде. Шул минуттан, шул мизгелдән үзгәрде дә куйды ул. Бер күрүдә гашыйк булдым, дигән сүзгә ышанмый иде. Хәзер дә ышанасы килмәде. «Ерунда!» – диде ул, яраткан сүзен кат-кат кабатлап. Тик кыз инде үзен алдар хәлдә түгел иде. Аның күзенә берни күренмәде: алда торган зачет-имтиханнар да, иптәш кызларының шаяртып әйткән кинаяле сүзләре дә... Күзләре гел шул егетне эзләде. «Сукырларча яраттым...» – дияр ул соңыннан, дистә еллар узып, аның белән булган көннәрнең бөтен михнәтләрен татып караганнан соң.

Һич көтмәгәндә алар тагын очрашты. Ашханәдә өстәлләре янәшә туры килде. Егет кызны күрде дә янына күчеп утырды. Сөйләшеп киттеләр. Дөресрәге, егет сөйләде. Ул сүзгә оста иде. Шул көнне ул аны өенә озата кайтты. «Үзең Казан кызы, үзең шундый кыюсыз», – диде Сәлим аның белән саубуллашканда. Гөлчәчәк күз төшмәслек кыз түгел иде. Сызылып киткән кара кашлар, куе кара чәчләр... Егетләр аңа карамады түгел, карады. Тик менә ул аны сайлады. Өч-дүрт айлап йөргәннәрдер. «Кияүгә чыгасыңмы соң миңа?» – дип кылларын гына тартып карамакчы иде егет. Ә ул шундук ризалыгын белдерде. «Мин сине бик яратам», – диде. Әнисе генә сагая калды: «Ошамый ул миңа, кызым, күзләре уйнаклап тора», – диде. Гөлчәчәк ишетмәмешкә салышты. Дөресе, ишетергә теләмәде. «Минем язмышым ул», – диде. Ә язмышы аңа хәтәр сынаулар әзерләп куйган иде.

Институтны алар бергә тәмамлады: Гөлчәчәкне кибеткә товаровед итеп җибәрделәр, ә Сәлимне, Гөлчәчәкнең гомер буе сәүдә эшендә эшләп чыккан әнисе ярдәме белән, зур сәүдә комплексына директор урынбасары итеп куйдылар. Ул карьера ясады, акча эшләде. Ә хатын, бер-бер артлы ике малай табып, балалар үстерде, өй мәшәкатьләренә чумды. Иренең эштән кайтканын сагынып көтеп торды. Хатын-кызга тагын ни кирәк, бер уйласаң?! Тик алай түгел икән шул... Тагын аңа иренең дә эштән сагынып кайтуы, яратуы, көнозын күрмәгән балаларын тезенә утыртып сөюе кирәк. Тик өйгә кунарга гына кайткан ирдән нәрсә өмет итәсең? «Әти!» – дип, каршысына йөгереп килгән малайларына да кул гына селти, аның өчен дип пешергән табын тулы ризыкка да исе китми. «Әтиегез арыган, борчымагыз!» Балалар, үсеп җиткәнчегә чаклы шул сүзне ишеттеләр. Әниләре әтиләренә җил дә тидертмәде, яман сүз дә әйттертмәде. «Ялгышканмын...» – ди хатын хәзер. Тик үкенүдән ни файда: гомер узган, буласы булган инде... Бүген ул искә төшергән саен күңелендә төзәлмәс җәрәхәт булып күтәрелгән вакыйгаларга, ниһаять, читтән торып бәя бирерлек хәлгә килгән.

Ул аны аэропортка каршы алырга килде. Сөяркәсе белән җитәкләшеп килеп чыккан иренә шунда да сүз әйтә алмады.

«Иргә ышанма, Иделгә таянма...»

– Синнән дә шушы сүзләрне ишетер көннәрне күрермен икән... Моны аңа туксан яшенә якынлашып килүче әнисе әйтә. Сәлим белән бергә яшәгән унбиш елның: «Өстеңнән йөри...» – дип өзгәләнмәгән бер генә көне булды микән әнисенең? «Шул эшкә урнаштырып үзем ялгыштым... – Әни кеше һаман үзен гаепли. – Шул нәрсә генә бозды арагызны. Белә идем бит аның Сәлимгә кадәр дә ике ир алыштырганын», – дип иренең җитәкчесен сүкте.

Ире Гөлчәчәккә «яратам» сүзен гомумән дә әйтми торган иде. Хатын моны аның кырыслыгы белән аңлата килде. Ярата, әйтми генә, имеш. Ялга да үзен генә җибәрде. Чираттагы ялына – Кара диңгез буена киткән көннәре иде Сәлимнең. Урамда Гөлчәчәкне таныш булмаган бер хатын туктатты: «Син ireңнең кем белән ялга киткәнен беләсеңме соң? – дип әйтте дә, шундук үзе җавабын да бирде, – Зөләйханың ире дә синең кебек пешмәгән бер нәрсә шунда. Ул да хатынына табынып яши». Хатынны ай күрде, кояш алды. Ә Гөлчәчәк озак вакыт аңына килә алмыйча, бер урында катып торды. Һәм кинәт, җитди карарга килеп, ире эшләгән сәүдә комплексына юл алды. Аны биредә беләләр иде. Махсусмы, кызганыпмы, шундук хатын кулына җитәкчеләренең өй адресын тоттырдылар.

Фото интернеттан алынды

– Йортларын тиз эзләп таптым, – дип сөйли Гөлчәчәк. – Төймәгә басам, җавап бирүче юк. Шактый вакыт басып торганнан соң, ишек ачылып китте дә бусагада ир уртасы кеше пәйда булды. «Кем кирәк?» – ди бу миңа. Кем икәнлегемне әйткәч, керергә рөхсәт бирде. «Хатыныңның минем ирем белән ялга киткәнен беләсеңме?» – дим. Шулай дигәч, ни өчендер хатынының өстәл тартмасын актарырга кереште. Һәм шуннан икесе төшкән фото тартып чыгарды. «Шушы, алайса...» – ди. Бер дә исе китмәгәндәй үзен шулкадәрле дә тыныч тота. Хәйран калдым. «Йә, ни әйтәсең, ни эшлик?» – дим. Югалып калдым: аны җәллим, үземне җәллим... Кычкырып елыйсы килә. Көчкә үземне тыеп торам. Ир минем атылырга җиткән вулкандай халәтемне сизеп алды бугай. «Иртәгә икәүләп каршы алырга барабыз», – диде ул һәм сәер итеп елмаеп куйды. Үзе миңа текәлгән. Нәрсә әйтермен дип уйлады микән инде?! Ә бәлкем, аның уенда бөтенләй башка нәрсә булгандыр.

«Күзләреңне йомганнар синең», – дип өзгәләнә иде әнисе. Ә ул аны тыңламады. Һаман гафу итә килде.

Шулай итеп, икенче көнне икәүләшеп аэропортка киттек. Самолет җиргә килеп кунды. Без көтәбез. Бер заман икәүләшеп җитәкләшеп килеп төшмәсеннәрме... Без борылдык та китеп бардык. Тегеләр дә безне күреп алды. Әйтәсе сүз әйтелгән иде инде. Кычкырышып, адәм мәсхәрәсенә калудан ни мәгънә?! Аның ире дә минем кебек сабыр булып чыкты. Ул да хатынын бик яраткан. Бу хакта ул миңа соңыннан әйтте.


Без аларга комачауламадык, юл бирдек. Шуннан соң ирем миннән китте. Балаларны кайгыртып торды дип әйтә алмыйм. Алимент түләде, әмма беркайчан да хәлләрен белешеп, аталарча киңәш-фәлән биреп тормады.

Шул көннән без – ике бәхетсез дип әйтимме, очраша башладык. Иремне оныттым дип әйтмим. Мин аны ярата идем әле. Ләкин минем өчен Ирек (Зөләйханың ире) шул вакытта олы терәккә әверелде. Без бер-беребезгә кирәк чагында таяныч була белдек. Ул чын ир-егет булып чыкты. Бер генә мәртәбә дә хатынын яманлап сүз әйтмәде. Миңа авырлык күрсәтмәде. Без аның белән 28 ел гомер кичердек. Әйе, безне хыянәт, чарасызлык кавыштырды. Мин аның гомер буе Зөләйхасын яратуын күңелем белән сизеп яшәдем. Аның каруы, ул балаларыма акыллы ата була белде. Иң мөһиме – Сәлимне оныттыра, үзен яраттыра алды. Ә бу минем өчен үзем дә аңлата алмый торган әллә нинди бер куркыныч бәйлелектән котылу иде. Шуннан «айнып» киттем дә күзләрем ачылгандай булды. Кемне сөйгәнмен, кемгә биргәнмен кайтарып ала алмастай яшьлек елларымны?! Әйе, без аның белән матур яшәдек, юкка берберебезне борчымадык, кирәкмәс сораулар биреп, бер-беребезне интектермәдек. Чөнки икебез дә бер үк хәлдәге кешеләр булуыбызны аңлый идек. Тик без тормышыбызны тамырдан үзгәртерлек көч таба алдык. Кызганыч, ул юк инде. Каты авырудан соң, мәңгелек йортка күченде. Вафатына биш ел, әмма мин аны бер генә минутка да исемнән чыгармыйм. Безнең очрашу – язмыш шаяруы. Ул миңа яңадан яшәп китү өчен канатлар куйды. Мин бернәрсәне яхшы аңладым: гаилә мәхәббәт, ярату белән бара, дисәләр дә, иң элек ул бер-береңә ышанычка, тирән хөрмәткә корылган. Алдау-йолдауларга урын юк анда. Югыйсә хисләр дә, уртак тормыш та бер мизгелдә янып юкка чыга, көлгә әйләнә.

Чиләгенә күрә капкачы...

«Кеше күз яшьләре, кеше бәхетсезлеге өстендә беркайчан да бәхет корам димә». Чәчләренә чал кунса да, элеккеге матурлыгын һаман да югалтмаган алтмыш яшьләр тирәсендәге бу ханымга карыйм да, ул кичергәннәрне янә бер күз алдымнан үткәрәм. Ә бит ул хаклы. Тормыш аккан судай алга-артка карамый дәвам итә. Яшьлектә кичергән тойгылар да әкренләп сүнә димим, башкачарак – җылырак, яктырак төсмер ала. Шуңа ир белән хатын картайган көндә бер-берсенә тагын да якынрак, бер-берсенә кадерлерәк була. Җиңгәчәем: «Ир белән хатын башта аркадаш, аннары бүлмәдәш, аннары, картайган көндә, фатирдаш була», – дип шаяртса да, әле күптән түгел генә мәңгелеккә күченгән абыебыз турында сөйләмәгән, аны искә алмаган бер генә көне түгел, бер генә сәгате дә юк. Тигез картаерга язсын, дип, тикмәгә генә теләмибез ич теләкләрне.

– Зөләйха белән Сәлим ничек? – дип сораштыра башлыйм да, әңгәмәдәшем мине ярты сүздән бүлә: «Ышанасыңмы-юкмы, алар аерылышты, – ди ул әйткәненә үзе дә ышана алмыйча. – Биш ел да тормадылар, тагын икесе ике якка карый башлады. Ни дисең инде – чиләгенә күрә капкачы... Икесе дә бертөрле. Бүрене ничек кенә ашатма, барыбер урманга карый диләр бит... Болар да шулай. Ни җитмәгәндер? Байлыклары баштан ашкан. Күрмәгән илләре, йөрмәгән җирләре калмады. Балалар белән күрешкәләп тора ул. Инде менә өченче мәртәбә өйләнгән. Күпкә-озаккадырмы, анысын әйтә алмыйм. Малайлар: «Әти эчүгә сабышты, хатыны өйдән куа», – дигән сүзләрне ишеттергәләп тора. «Гомер буе зур-зур урыннарда утырган кешенең үз фатиры кая булган?» – дим, гаҗәпләнәм. Бервакыт кечесе: «Әллә кушыласызмы?» – дигән сүзләрне дә ычкындырып куйды. «Мине кадерләп, минем турыда кайгыртып торган бер генә ир бар иде. Ул да юк инде... Әтиегез дә минем өчен күптән бу дөньяда юк кеше», – дидем. Кайчандыр башымны югалтып яраткан кешемә хәтта нәфрәтем дә калмаган минем.



Камила ДИМӨХӘММӘТОВА

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты (2013)

Кияүдә

Карьера:
«Сәләт» Тел мәктәбе» проекты җитәкчесенең ярдәмчесе.

Кредо: «Үзгәрешләр ясау өчен иң кирәге – аның чыннан да кирәклегенә ышану»
(Э. Толле)

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Балалар инглизчә аралаша!

Күптән түгел без ирем белән «Сәләт» фонды каршында чит телләр өйрәнү мәктәбен ачып җибәрдек. Балалар белән аралашу өчен өйрәнеләсе тел гамәлдәге илдән килгән кешене, ягъни, безнең очракта, чын американны җәлеп итә алдык – безнең өчен зур уңыш һәм сөенеч булды бу! Пол белән аралашу балалар өчен тел чарландыру мөмкинлеге генә түгел, ул аралашу мәктәбе дә. Мин беренче очрашуга панкейк (американ коймагы) пешердем. Полга панкейгым бик ошады! Аның үзен дә бик яратып калдык. Мондый очрашулар даими булыр дип торабыз.


Космос үзе булышыр!

Күптән түгел «Сәләт» Халыкара укыту технологияләре үзәге ачылды. Аның төп бурычы – кешеләргә аларны кызыксындырган юнәлешне таба алырлык ачык мәйдан булдыру. Үз проектларын эшләү, камилләштерү. Шундук күңелне рәхәт бер канәгатьлек биләде – бүген яшьләр өчен никадәр мөмкинлекләр ачыла! Үзәк проектларының берсе – Selet Prague School. Мәктәпнең бер этабы – Прагага бару, анда катнашучылар көн саен тренингларда катнаша. Бу дөньяга ачыл, мөмкинлекләреңне тап, офыкларыңны киңәйт, максатлар куй гына – Selet Prague School кебек проектлар ярдәме белән Космос үзе сиңа борылачак.

Бэнкси таң калдырды

Мине Лондонда яшәүче Бэнкси исемле егетнең социаль граффити эшләре таң калдырды. Мәсәлән, кочаклашып торган егет белән кыз һәркайсы үз дөньясында – һәрберсе үз телефонына капланган (соңгы вакытта шул тенденцияне күзәтәбез түгелме?); кибет арбасы белән аска томырылып төшүче кыз (бөтенесен үзенә йоткан шопинг). Бу эшләр кәефне дә кыра бераз. Ләкин аларның асылы – матурлык аша социаль проблемаларны күрсәтүдә бит. Бэнкси аларга җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә алган – шунысы сөендерде. Сәнгать сокландырсын да, уйландырсын да ул.


сөендерде 



көендерде 


сөендерде 



көендерде 

сөендерде 



көендерде 

Җинаять – табигый хәл?

Троллейбуста салмыш ир белән хатынның үзара сөйләшүе колакка керде. «Киләсе тукталышта ук төшик, анда урамнар караңгы, берәрсен аулак почмакка кысу берни тормас», – дип, бер-берсен куәтлиләр. Урта яшьләрдәге бу пар башкалардан аерылып тормый, мондыйлардан сакланып та тормас идең. Алар тозагына эләгәчәк таныш булмаган кешеләр өчен дә куркудан шок хәлендә калдым. Сүзләрен башкалар да ишетүенә исләре китмичә, явыз ниятләре турында ничек ачыктан-ачык сөйләшә ала болар? Күңелсез уйлар һаман тынгы бирми миңа...

Һәлакәткә илткән... әни?!

Башкортстанга ике баласын ияртеп таулар белән хозурланырга китеп, бәлагә тарыган хатын турындагы хәбәр күпләрне сискәндерде.
Иң аянычы – 13 яшьлек кызы һәлак булу. Бүген заманча технологияләр кешегә хезмәт күрсәтә торган чорда, интернетка кереп, хәтта ки якын көннәргә һава торышын гына да карамаган бит! Һич башыма сыймый шул әйбер... Гаилә сагында торырга тиешле ананы балалары белән шундый хәвефле сәфәргә чыгарга нәрсә этәргән? Минем әле балаларым юк. Әмма бу әни кешенең гамьсезлеге мине чиксез тетрәндерде.

Кайгының теле уртак

Франциядә булган коточкыч авиакатастрофа бөтен дөньяны тетрәндерде. Лайнер пилоты турындагы уй һич тынгы бирми. Аның аркасында килеп чыкты бит бу һәлакәт! Яшь егет бит ул, бөтен тормышы алда, кызыклы һөнәре бөтен дөньяны гизәрлек мөмкинлекләр ача... Ә ул үзенең һәм тагын 150 кешенең гомерен кисәргә карар кыла. Әлеге фаҗига бездәгесен кабат искә төшерде – һәлак булучылар арасында кызы белән безгә туган тиешле бер апабыз да бар иде.
Андый вакытта яшең дә мөһим түгел, тәннең төсе дә – без һәммәбез бер телдә, кайгы телендә хәсрәтләнәбез.

ТАТАРЧА CASUAL



Рәмзия КАШАПОВА

CASUAL — көндәлек киенү рәвеше. Ул XX гасырда Европада барлыкка килгән. Бу стильнең үзенчәлеге — уңайлы булуда. Кием артык купшы да, артык классик яки артык традицион да булырга тиеш түгел. Кэжуал стилендә киенгәндә, итәк — бер, блузка икенче фирмадан була ала, һәм алар гүя «очраклы» гына шулай бербесенә ярашкан шикелле тәэсир калдыра.

Милли кием дизайнерларының халыкара конкурсын Казанда 2009 елдан уздыра башладык. Ул чакта ук дизайнер буларак катнашучы студентларыбызның игътибарын үзебезнең традицион милли киемнәребезгә юнәлтергә тырыштык.

Кызганыч, еш кына студентлар сәхнә образы белән милли үрнәкләр кулланып тегелгән заманча киемнәрне бер-берсеннән аера алмый. Югыйсә заманча көндәлек киемнәрне дә татарча милли бизәкләр, милли рәвешләр белән тегәргә бик мөмкин бит.

Заманча мода нәрсә ул? Барыннан да битәр, ул – уңайлылык. Нәкъ менә киемнең уңайлылыгы Мода атлы уенга үз кагыйдәләрен кертә.

Милли кием ул – мәдәният чагылышы. Борынгы әби-бабаларыбыздан безгә бик бай мирас – татарча милли кием-салым калган. Гасырлар дәвамында аның үзенә генә хас үзенчәлекләре барлыкка килгән, һәм бу үзенчәлекләр халкыбызның эстетик идеалын чагылдыра.

Нәрсәләр хас соң безгә? Бүтән бер генә халыкта да кабатланмас нәкышбизәкләр. Ул бизәкләр безнең күлмәкләребездә, читек-кәвешләребездә, көндәлек көнкүреш әйберләрендә – һәркайда! Нәрсәне генә алсаң да, һәркайсында детальләр өстенлек итә!!!







Фотолар tatarchacasual.com сайтыннан алынды.

Яшь татар хатын-кызының (авыл кызымы ул, шәһәрнекеме) заманча образы ул – иң элек уңайлы тукымалар һәм җайлы кием!

Хәзер кием күргәзмәләрендә изүенә милли бизәкләр чигелгән күлмәкләр күбебезнең игътибарын җәлеп итә. Туган тел, милли гореф-гадәтләребез, милли йолалар, Сабантуй, Нәүрүз кебек милли бәйрәмнәребез яшьләребезне торган саен күбрәк кызыксындыра. Бик куанычлы хәл бу. Ә тагын да куанычлысы – яшь егет-кызларыбызның хәтта иң гади генә кием-салымнарын да милли бизәкләр белән бизәп, башкалардан аерылып торырга омтылуы. Узган ел Казанда беренче тапкыр үткән Халыкара «Turkvision-2014» җыр фестивалендә Төркмәнстан, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан һәм Алтайдан өлкәсеннән килгән катнашучыларның милли киемнәренә булган мөнәсәбәтен, ихтирамын, мәхәббәтен күреп таң калган идек. Төркмәнстан җырчысы Зөләйха Какаева чын мәгънәсендә мода өлгесенә әверелде ул көннәрдә. Яшь кызларның аның киеменә, йөзкыяфәтенә сокланууларын ишеттек.

Әйе, милли үрнәкләр белән бизәлгән матур һәм уңайлы кием-салымны күпләп җитештерү сәнәгате бездә әлегә юк. Ләкин яшьләрне әкренләп кенә «Татарча casual» стиленә өйрәтүче тәүге карлыгачлар күренә башлады инде. Бу зур проект безгә Мәскәүдән килде, кызганычкамы, куанычкамы, башкалабызның мөмкинлекләре зуррак. Яшьләр арасында «Татарча casual» проекты милли киемгә карата яңача караш тудырды, һәм ул илебез киңлекләрен көннән-көн күбрәк яулый бара.

Яшьләребезне бу проект нигә шулай җәлеп итә соң? Барыннан да бигрәк, үзенең заманчалыгы, уңайлылыгы һәм теләсә кайсы киемне бер-берсе белән, аксессуарлар белән яраштыра алу мөмкинлеге өчен һәм, әлбәттә, матурлыгы өчен үз итә аны яшьләр. «Татарча casual» бренды коллекциясен үз итәсе бар әле!

Яшь талантларның эзләнүчәнлеге безне һәрвакыт куандыра. Менә кайда ул фантазия иреге. Нәкъ менә яшь дизайнерлар көнбатыш агымын татарларның борынгыдан килгән мәдәни традицияләре белән (әлеге очракта киемдә) бергә бәйли алды.

Яка очларына милли бизәкләр чигелгән мәктәп формасы кигән укучылар нинди күркәм булыр иде югыйсә. Хәзер никах күлмәкләрен милли итеп тектерү гадәткә кереп китте, һәм монда төрле стильләрне, төрле юнәлешләрне бергә бутыйлар. Болай бутау дөрес түгел. Шуңа да дизайнерларга, җиңел сәнәгать белгечләренә киңәш итеп әйтәм: иренмәгез, беренчел чыганакларны өйрәнегез, фәнни хезмәтләргә күз салыгыз, тарихчылардан сораштырыгыз, шул чакта гына сезнең хозурыгызга үз милли мәдәниятебезнең кабатланмас гүзәллеге ачылыр.

Инде менә ничә еллар буе үз киемнәремдә татарча милли стильне кулланып кына калмыйм, ә тегү осталары белән киңәшеп, аны камилләштерергә омтылам. Бервакыт каюлы читекләремне киеп Рим урамнарын гизгәндә, Европаның мода индустриясе вәкилләренең – бүгенге көндә мода диктаторлары булган итальян хатын-кызларының хәтта һушын алган идем. Шул чакта үзебезнең татарларыбыз өчен ничек горурланганымны белсәгез! Шушы горурлык хисен яшьләребезгә дә йоктырасы иде бит. Аларга әйтәсе килгән сүзем шул: акыл иясе булган талантлы борынгы бабаларыбыз калдырган мирасыбыз белән горурланыгыз һәм ул мирасны сакларга, көндәлек тормышыбызга кире кайтарырга тырышыгыз.

Милли кыйммәтләрне киемнәрдә дә чагылдыра башлау, милләтебезнең йөзен ачуда мөһим роль уйный. Чөнки кием – шәхеснең дәвамы. Аннары бит, безне акылыбыздан алда киемебезгә карап бәялиләр дә.

ИРТӘНГЕ ДЕСЕРТ

Без җырчы Айгөл Хәйридә кунакта. Ул безне җиңел генә әзерләнә торган бананлы эремчек шаңгәсе белән сыйламакчы. Ярдәмчесе дә янында гына — икенче яше белән баручы кызы Җәмилә. «Туган ил», «Тәфтиләү» кебек халык җырларына чит ил тамашачыларын да гашыйк иттерә алган Айгөл, җырчы булып китмәсә, рәссам булыр иде, мөгаен. Әмма, язмыш диген... Яше җитмәү аркасында сәнгать мәктәбенә укырга керә алмаган кыз музыка мәктәбенә юл тота. Тыңлап карау белән үк, шанлы киләчәк юрый аңа укытучы апалары, һәм ялгышмыйлар. Бүген Айгөл Хәйри консерваториядә булачак җырчыларны укыта. Г. Камал театрында артист-вокалист булып эшли, Мәйсәрә ролен (К. Тинчурин. «Зәңгәр шәл») башкара.





Кирәк:

(4 кешелек гаилә өчен):

• 200 граммлы өч кап эремчек (бер кабы – катнашмасыз, ике кабы – төрле катнашмалы эремчек массасы);
• 2-3 банан;
• 3-4 аш кашыгы манный ярмасы;
• 1 йомырка;
• 200 г караҗиләк (бүтән җиләкләр дә ярый);
• 3-4 чәй кашыгы кунжут (сим-сим) орлыгы;
• кашык очында гына чәй содасы, аш серкәсе.

Эш барышы:






■ эремчекне зур савытка бушатып, чәнечке белән яхшылап изәбез. Йомырканы бер савытка сытып, бераз күпертәбез һәм эремчеккә кушабыз. Манный ярмасы һәм аш серкәсе тамызылган чәй содасын да салып, яхшылап туглыйбыз. Гади эремчектән генә әзерләсәгез, шикәр комы да кушарга кирәк булыр.

■ Табаны үсемлек мае белән майлап, аз гына манный ярмасы сибәбез. Бананның кабыгын әрчеп, тәгәрмәчләп турыйбыз һәм таба төбенә бер кат итеп тезәбез. Банан өстенә эремчекне салып, чәнечке белән тигезлибез. Икенче бананны да турап, эремчек өстенә тезеп чыгабыз.

■ Банан өстенә каражиләк түшибез. Без туңдырылган җиләк кулландык. Җәй көне исә бакчадан гына җыеп алып кергән кара карлыган, кура җиләге, виктория белән пешерергә була. Җиләкләр әчерәк булса, бераз шикәр комы кушарга мөмкин.

■ Каражиләк өстенә бер уч сим-сим орлыгы сибеп, 180–200 градуска кадәр җылытылган мичкә тыгабыз. Берáздан утны киметеп, 160–170 градуска гына калдырабыз. Ярты сәгатьтән иртәнге ашыбыз әзер. Десертыбыз кайнар килеш тә, салкын килеш тә бик тәмле.

■ Мастер-классның видеоязмасын сайтыбыздан карарга мөмкин.

ЯБЫКТЫРУЧЫ ЧӘЙЛӘР

Ябыктыручы чәйләрне даими эчкәндә бер айга 2-5 кило авырлыктан котылып була.



Сасси эчемлеге

1 зур лимон, бер учма яшел бөтнек, 1 яшел кыяр, 1-2 чәй кашыгы кипкән имбир тамыры.

Бөтнекне кул белән генә ваклыйбыз, лимон белән кыярны юка телемнәргә кисәбез. Барысын бергә кушып, 2-2,5 литр кайнамаган чишмә суы өстибез. Эчемлекне суыткычта төнәтәбез. Икенче көнне көн дәвамында шуны эчеп бетерергә кирәк.

Ябыктыручы чәйләр хакында тулырак мәгълүматны сайтыбыздан укый аласыз.

Хачапури



Без сеңлем Алисә белән Казандагы 12 нче кызлар гимназиясендә укыйбыз. Миңа — 12, сеңлемә 9 яшь. Өйдә үзебез генә калсак, без пешеренергә тотынабыз. Яраткан «Сөембикә» журналыбызда өр-яңа бәйге игълан ителүен укыдык та, катнашып карарга булдык. Без тәкъдим иткән ризык бик гади, тиз пешә, тәмле була. Әниебез катламнар арасына суган һәм томат белән кыздырган ит фаршы да куша. Ә без сыр белән пешерергә яратабыз.

Кирәк

- 2 әрмән ләвәше;
- 150 мл сөт;
- 1 йомырка;
- 300 г каты сыр.

Эш барышы:

■ Сөткә йомырка сытып туглыйбыз. Сырны эре угычтан уабыз. Табаны үсемлек мае белән майлап, бер кат ләвәш салабыз, аның өстенә уылган сыр сибәбез. Янә бер кат ләвәш, аның өстенә янә сыр. Иң өстә ләвәш калырга тиеш. Ләвәш өстенә сөт белән туглаган йомырканы агызып, ярты сәгатькә 180 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз. Мичтән алгач, өстен томалап, чак кына парландырып алабыз.

Энҗе РӘХМӘТУЛЛИНА.
Казан.

Көнбагыш чиртеп үтте инде безнең балачак. Бер безнең генәме? Көнбагыш кешеләрнең гомерлек юлдашы ул. Элек аны матурлык өчен үстергәннәр. Бай кешеләр сары чәчәкле көнбагыш белән өйләрен бизәгән. Тора-бара аның матур гына түгел, бәлки, тәмле дә икәнен белеп алганнар. Табиблар көнбагышны ашказаны авыруларына, тешләр кителүгә сәбәпче була ала, дип, ничек кенә кисәтеп тормасын, көнбагыш безнең илдә гаять популяр булып кала бирә. Бу орлык нинди матдәләргә бай соң? Бәлки, анда кешене «сихерле» торган ниндидер үзлекләр бардыр?



КӨНБАГЫШ ТА СИХӘТЛЕ

Көнбагыш «сихере»

Әлбәттә, иң элек көнбагыш кешене тәме белән кызыктыра.

Көнбагышта D витамины шулкадәр күп ки, хәтта тәрәч (треска) балыгы бавыры да бу җәһәттән аңардан нык калыша. Каротиноидлар һәм дуплаучы матдәләр көнбагыш яраткан кешене һәртөрле паразитлардан һәм инфекцияләрдән саклый. Көнбагыш төшендә антиоксидант саналучы, димәк, яман шеш авыруларына каршы торучы A һәм E витаминнары да бар. Бу витаминнар күз күремен яхшырта, яман шеш чирләре килеп чыгу ихтималын кисәтә, атеросклероз, тырнак кителү кебек күңелсез нәрсәдән дә беркадәр коткара, ә составында цинк булганга күрә көнбагыш төше чәч структурасын яхшырта. Төшендәге май кислоталары кешенең май күзәнәкләрен яндырганга күрә, кирәкмәгән урыннарга май ягылмый кала. Көнбагыш төше шулай ук кремний, калий, фосфор, магний кебек минералларга, клетчаткага да бай.

Шул сәбәпле, ашказаны һәм эчәк юллары эшчәнлеге яхшыра. Кояшлы үсемлекнең орлыгында баш миендә серотонин ясалуны стимуллаштыра торган триптофан дигән матдә бар. Серотонин исә нервлар киеренкелеген киметү үзлегенә ия.

Көнбагыш дәвалый

Көнбагыш төше бик туклыклы. Хәтта ит, ипи кебек туклыклы ризыклар да бу җәһәттән көнбагыштан калыша. Көнбагышның файдалы сыйфатлары озак вакыт саклана ала, чөнки көнбагыш кабыгы төшне бозылудан һәм зарарлы тәэсирләрдән саклый.

Диетологлар исә көнбагышны дәва чарасы итеп карый. 100 грамм көнбагыш орлыгы ашау кешене йөрәккан тамырлары системасы, бавыр чирләреннән аралап калырга мөмкин, дип саный медиклар. Авыр физик хезмәт яки спорт белән шөгыльләнүче кешеләр дә көнбагыштан баш тартмасын. Аның төше зарарланган тән тиресен төзәтү өчен дә ярап куя. Шуңа күрә каты авырудан соң яки сөяк-санак сынганда көнбагыштан файда табарга мөмкин. Кыздырылмаган көнбагыш төше чиртү белән мавыккан яшүсмерләр бетчә, сыткыч кебек нәрсәләрдән җәфа күрмәс. Симерүдән чара таба алмаган кешеләргә дә табиблар чи көнбагыш төше ашарга киңәш итә.

Косметологлар уалган көнбагыш орлыгын тән чистарту чарасы итеп файдаланырга да кушалар. Көнбагыш төше хатын-кыз сәламәтлеге һәм иммунитет өчен бик кирәк. Андагы магний белән тимер аларга әле озак вакыт яшь күренергә ярдәм итәр.

Кемгә ярамый

Көнбагыш төшенең гаять туклыклы, дидек бит. Шуңа күрә аны 100 граммнан артык ашарга киңәш ителми. Әгәр болай да подагра, ашказаны җәрәхәте белән интегәсез икән, көнбагыш сезнең өчен түгел. Стоматологлар да пациентларын көнбагыштан тыярга тырыша. Әгәр инде бик тә, бик тә сыйланасыгыз килсә, кул белән чистартып ашарга тырышыгыз.

Ә менә җырчылар өчен көнбагыш – тыелган азык.

Сак булыгыз: кадмий

Көнбагышның озын көпшәсе җирдән файдалы матдәләрне генә түгел, бәлки зарарлы катнашмаларны да суырып ала. Шуларның берсе – кадмий. Көнбагыштагы кадмий микъдарын кем санап караган? Организмга үлчәнмичә кергән кадмий бөерләрне, нерв системасын зарарламаган, дип, кем ышанып әйтә ала?

«Дөрес» көнбагыш

Әлбәттә, үзең чәчеп үстергән көнбагышта күңелсез сюрпризлар булмас. Кибеттән сатып алганда саклану вакыты дигән нәрсәгә игътибар итегез.

Кибет көнбагышын 75 градуста кыздыралар. Мондый температурада файдалы майлар таркала, зарарлы ирекле радикаллар барлыкка килә.

Халык табиблары киңәш итә

■ **Катарактадан һәм күз күремен яхшырту өчен.** 250 г кабыклы көнбагышка өч литр су коеп, 20 минут кайнатып алыгыз. Суынгач, сөзегез. Шушы суны көн саен теләгән кадәр эчегез.

■ **Бума ютәлдән.** Көнбагыш төшен табада яки духовкада кыздырып алгач, аны он сыман хәлгә китерегез. 2-3 кашык онны ярты литр шикәрле суда кайнатыгыз. Су яртылаш кайнап беткәч, кайнатманы сөзегез, аннары ашар алдыннан көнгә өч мәртәбә берәр аш кашыгы чамасы эчә торган булыгыз.

■ **Простатиттан.** Көн саен бер-ике уч көнбагыш төше ашагыз. Әле шуңа өстәп, көн саен берәр аш кашыгы җитен, көнбагыш яки соя мае эчеп куйсагыз да әйбәт.

■ **Холестеринны киметү өчен.** Бер стакан кабыксыз чи көнбагыш төшен шыттырыгыз. Моның өчен иртән көнбагышны дымлы тастымалга таратыгыз, өстеннән дә дымлы тастымал белән ябып куегыз. Дымны күзәтеп торыгыз – кипмәсен. 12-15 сәгатьтән яшел «борыннар» күренер. Шыткан орлыкларны термоска салыгыз, өстенә 1 литр кайнап торган су коегыз.
3-5 минут кына ачык килеш тотыгыз да томалап куегыз. Төнне чыксын. Шушы төнәтмәне көнгә 3-4 мәртәбә, ашарга 20 минут кала, 3-6 ай дәвамында эчәсе.

■ **Депрессиядән.** Борынгы дәва китапларында да көнбагыш чиртергә киңәш ителгән. Гаҗәп түгел, B, C витаминнары, фолий кислотасы җитмәгәндә килеп чыга бит инде ул депрессия дигәннәре.

Җитен маеның тәме бөтен кешегә дә ошап бетми. Ләкин бу кечкенә генә минус майның файдасы янында тагын да кечерәеп кала. Җитен маеның кыйммәте аның составында файдасы бәһаләп бетергесез май кислоталарының күплеге белән билгеләнә. Аларны кеше организмы үзе эшләп чыгара алмый, фәкать ризыктан гына ала. Шушы кислоталар җитеш булганда биохимик процесслар дөрес үтә, шунлыктан кеше озак вакыт матур, сәламәт һәм яшь булып яши ала.

Файдасы нидә?

Әгәр озак вакыт ризык сыйфатында җитен мае куллансаң, организм үзеннән-үзе яшәрүгә көйләнә:

- кан тамырларын тыгылдыра торган начар холестерин микъдары кими;
- канның ябышкаклыгы кими төшә, димәк, тромблар ясалу, инфаркт, инсульт ихтималы да азая;
- яман шеш авырулары, бигрәк тә күкрәк бизе, туры эчәк рагы барлыкка килү куркынычы кими;
- ашказаны җәрәхәте тизрәк төзәлә;
- гормоннар тәртипкә килә;
- ирләрнең ирлек белән бәйле проблемалары уза;
- күрем алдыннан була торган халәт һәм ярудан калу (климакс) җиңелрәк кичерелә;
- организмның чирләргә каршы торучанлыгы, иммунитеты ныгый;
- аяк-куллар, буыннар яхшырак эшләп китә, әкренләп артрит билгеләре дә югала;
- организмның аллергиягә бирешүчәнлеге кими төшә;
- өлкән яшьтәге кешеләрнең баш мие эшчәнлеген яхшырта;
- нерв системасын тынычландыра;
- организм матдәләр алмашу калдыкларыннан җиңелрәк арына; агулы матдәләрдән, зарарлы утырымнардан чистарына;
- май катламы әкренләп сыза башлый; ябыгу механизмы эшләп китә;
- күзәнәкләрнең яңаруы тизләнә.

Ничек кулланырга?

Салкын ысул белән сыгылган май гына файдалы. Тәүлеклек норма ике аш кашыгы тәшкил итә. Майны фәкать ач карынга гына эчәргә кирәк. Иртәнге ашны ашарга ярты сәгать кала, беренче кашыкны һәм кичке ашны ашаганнан соң, ике сәгать үткәч, икенче кашыкны кабып куясы. Майны үзен генә эчә алмасагыз, җылы су белән йотып җибәрегез.

Майны башта иртәнге якта бер чәй калагы гына кабып куюдан башлагыз. Бернинди дә җайсызлык сизмәсәгез, икенче иртәдә майны бер аш кашыгы кабып куегыз. Өченче көнне инде кичке якта да май кабыгыз. Аннары майны аз-азлап салатларга, боткаларга өсти башларга ярый.
Җитен маеннан балык мае тәме килгән кебек тоелса, тагын да әйбәт. Кем дә кем майны болай гына каба алмый, андыйлар өчен аптекаларда желатин капсуладагы майлар бар. Җитен маен бөкеләнгән тонык пыяла шешәләрдә суыткычта сакларга кирәк. Җитен мае тиз бозыла. Шуңа күрә файдалану вакытын карап алыгыз.

Кемгә ярамый?

Бавырлар авыртканда, ашказаны бизе ялкынсынган, холециститлы, энтероколитлы кешеләргә, кан оешу җәһәтеннән проблемалар булганда җитен мае киңәш ителми. Депрессиягә каршы дарулар, вируsларны баса торган дарулар эчкәндә дә җитен мае килешми. Бала имезә торган хатыннарга, өч яше тулмаган сабыйларга майны табиб белән киңәшкәннән соң гына кулланырга ярый.

Алина — югары белемле инженер, ә менә рухы белән — рәссам. Бу сәләте аңа әтисеннән күчкән. Кибернетика-информатика факультетында укыганда ук интерьерлар бизәү белән дә мавыккан. Гап-гади савыт-сабаларга милли бизәкләр төшереп, карап туйгысыз сәнгать әсәре ясый белә ул. Аның берсен-нән-берсе матур тәлинкәләре, чәйнекләре, көзгеләре шәһәребезне күрергә килгән туристларның бүлмә түрендә Казаныбыз ядкаре булып яши.





Мастер-классны Алина БАССАРИЕВА үткәрә.

КӨЗГЕМ — ӨЕМ БИЗӘГЕ







Кирәк:

- төрле төстәге акрил буяулар;
- пыяла өчен махсус контурлар (бронза, алтын һәм зәңгәрсу төсләр);
- нечкә пумала (№ 2);
- калын кысалы көзге;
- савыт белән су;
- тастымал.

Эш барышы:

■ гади карандаш белән кысага бизәк төшерәбез. Рәсем ясарга осталыгыгыз булмаса, әзер трафарет белән дә төшерергә мөмкин. Мондый трафаретлар сәнгать салоннарында сатыла. Күңелегезгә ошаган бизәкне интернеттан да табарга мөмкин.

■ Пумаланы буяуга манып, рәсемне бер читеннән буйый башлыйбыз. Мәсәлән, без пумаланы зәңгәр төскә манып, бизәкнең зәңгәргә буяласы бар өлешләрен буядык. Аннан соң, пумаланы юып, башка төскә күчтек. Төсләрне үзегез теләгәнчә сайлагыз.

■ Кысадагы бизәкләрнең барысын да буяп бетергәч, 15-20 минут кипкәнен көтәбез. Буяулар кулга йокмый башлагач, алтын төстәге контур белән төртке артыннан төртке төртеп, һәр бизәкне читләп чыгабыз. Төрткеләрнең икенче рәтен бронза контур белән ясыйбыз.

■ Зәңгәр төстәге чәчәкләрнең уртасын зәңгәрсу контур белән бизибез. Кысаның буш калган урыннарына алтынсу контур белән төрле бөтеркәләр ясап чыгабыз. Почмактагы лалә чәчәкләрен алтынсу бөҗралар белән бизибез.


КУЧКАР. Айның беренче көннәрендә финанс эшләрен башламый торыгыз, акчагызны югалту ихтималы бик зур. Яшәү көчегезнең артуын үзегез дә тоймый калмассыз. Хроник авыруларны дәвалау өчен уңай вакыт, организмыгыз үз-үзен сәламәтләндерергә омтыла.


ҮГЕЗБОЗАУ. Яңа эшләр башлар өчен кулай ай. Кем белән эш итәсегезне бик яхшылап сайлагыз. Көчкуәтегезнең ташып торуы тирә-юньдәгеләрнең ачуын кабартырга мөмкин. Боларга гына каршы торырлык көчегез булса да, компромисска бару яхшырак.


ИГЕЗӘКЛӘР. Айлык план төзеп куйсагыз, ялгышмассыз. Бу айда тәртип һәм оешканлык соралачак. Ай башында күңелегез кителергә генә тора, шуңа күрә дә җаныгызга хуш килмәгән кешеләрдән ераграк булырга тырышыгыз. Әлегә яңа эшләргә алынмый торыгыз.


КЫСЛА. Эшлекле очрашулар өчен яхшы вакыт, ышандыру көчегезгә күпләр кызыгырлык. Әмма ашыгып, эшне бозып куюдан гына сакланыгыз. Киләчәктә файдасын күрердәй яңа танышлар очратырсыз. Бу айда кызыклы сюрпризларга юлыгырсыз.


АРЫСЛАН. Эшегезне менә дигән итеп башкаруыгызны расларга форсат чыгар. Бу исә киләчәктә дәрәҗәгезне үстерү өчен яхшы нигез булачак. Әмма үтә дә игътибарлы булыгыз, сезнең абынганны көтеп кенә йөрүчеләр бар. Ай ахырында ерак юлга чыкмагыз.


КЫЗ. Кызыклы идеяләргә юлыгырсыз һәм аларны тормышка ашыру юлларын табарсыз. Бу табышларыгыз җитәкчеләр алдында абруегызны күтәрер. Ә бу исә үз чиратында финанс хәлегезне яхшыртуга бер адым булыр. Артык сүз сөйләшүдән сакланыгыз.


БИЗМӘН. Күп вакытыгызны эштә уздырганлыктан, хезмәттәшләрегез белән яхшы мөнәсәбәтләрне саклар өчен тырышырга туры килер. Гайбәтләргә катнашмагыз, ахыры хәерле булмас. Шәхси тормышта бар да үз җае белән барыр. Ялгызларны яңа танышулар көтә.


ЧАЯН. Теләсә кайсы авырлыкны җиңеп чыгарсыз. Әмма бу үтә дә сабырлык сорала торган ай. Хезмәттәшләрегез ярдәм тәкъдим итсә, баш тартмагыз. Үз-үзегезгә артык ышануыгыз зыян китерергә мөмкин.


УКЧЫ. Яңа эш башласагыз, уңышка ирешәчәксез. Кызыксынучанлыгыгыз, хәбәрдарлыгыгыз эшегездә ярдәм итәчәк. Ирешкән нәтиҗәләрне күрсәтүдән тартынып тормагыз, югыйсә эшегезнең әҗерен тоймассыз. Шәхси тормышта күңелле яңалыклар көтелә.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Тырышып эшләвегезнең әҗерен күрә башларсыз. Хезмәт баскычы буйлап югарырак менү ихтималы зур. Бу айда сезне яңа проектлар, премия һәм хезмәт хакының артуы көтә. Көчегез мулдан.


СУКОЯР. Күптән көтелгән карьера үсешенә ирешерсез. Авырлыклардан курыкмагыз, ихтыяр көче күрсәтсәгез, барысын да җиңеп чыгарсыз. Финанс эшләрен тәртипкә салу мөһим. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр куаныч китерер.


БАЛЫК. Бу айда мөһим карарлар кабул итми торыгыз. Көндәлек эшләр белән мәшгуль булыгыз. Тирә-юньдәгеләр ачуыгызны китерергә мөмкин, түземлек сорала. Гел бертөрлелектән туюыгызны сизсәгез дә, яңа эшләргә алынмагыз.

апрельдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Заһирә Гомәрова (12.04.1930–4.01.2002) – **шагыйрә, балалар язучысы.**
Арча районы Чөмә-Елга авылында туа. 1959 елда Казан педагогика институтын тәмамлап, авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Балалар өчен иҗат ителгән ике дистәгә якын проза һәм шигырь китабы авторы. 1964 елда басылып чыккан «Яшьлек таңы» дип аталган беренче шигырь китабы балаларга багышланган. 1968 елда «Чын герой», бераз соңрак «Нәни врач», «Әнисенең алмалары», «Йөгерек елга» исемле җыентыклары дөнья күрә. 1985 елдан гомеренең соңгы көненә кадәр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә. 1995 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Россия



Ирина Хакамада (13.04.1955) – **сәясәтче, дәүләт эшлеклесе, язучы.**
Мәскәүдә туа. Әтисе – 1939 елда Россиягә күчеп килгән япон коммунисты. Әнисе – укытучы. Халыклар дуслыгы университетын тәмамлап, хезмәт юлын 1980 елда РСФСРның Госплан фәнни институтында башлый. 1990 нчы еллар башына кадәр фәнни эш һәм укытучылык белән шөгыльләнә. 1992 елда Икътисадый бәйсезлек фиркасы оештыра. 1993 елда РФ Дәүләт Думасы депутаты булып сайлана. Хәзерге вакытта китаплар язу белән мәшгуль. «SEX в большой политике», «Любовь вне игры. История одного политического самоубийства» дигән китаплары басылып чыкты. Радио һәм телевидениедә тапшырулар алып бара.

Чит илләр



Ума Турман (29.04.1970) – **актриса.**
Тамашачыларга күбрәк «Криминаль әдәбият» һәм «Биллга үлем» фильмнары аша таныш. Әтисе – Колумбия университеты профессоры Роберт Турман. Индус алиһәсе хөрмәтенә кушылган исеменнән оялып, үзен Дайана дип йөрткән кызга актерлык карьерасы баскычыннан күтәрелү бик ансат булмый. Башта ул кафеда савыт-саба юучы булып эшли. Соңрак модель булып урнаша. Кинорежиссерлар аңа Терри Гиллиямның «Барон Мюнхгаузен маҗаралары» фильмында уйнаганнан соң гына игътибар итә. Ә чын-чынлап танылу «Генри һәм Джун» фильмыннан соң килә. Өч бала анасы. «Криминаль әдәбият» фильмында уйнаган роле өчен «Золотой глобус» премиясе ала (2003).






КАЗАН ҺӘМ ТУКАЙ




Габдулла Тукай музеенда Татарстанның халык рәссамы Ирина Колмогорцеваның «Казан һәм Тукай» дип исемләнгән шәхси күргәзмәсен карап йөрим. Рәссамның балачактан ук таныш исеме күңелдә уйдык-уйдык хатирәләрне яңартып ала: «Гөлчәчәк» әкиятен, Бари Рәхмәтнең «Сара мәктәпкә бара», Абдулла Алишның «Койрыклар» китапларын бизәгән рәссам бит бу! Иҗатының башлангыч чорында анималистика жанрында аеруча күп эшләгән... Аның «Мин Казанда яшим» дип аталган «Үзең буя» альбомындагы рәсемнәргә бик мавыгып төсле карандашлар белән «җан өреп» утыруларым да исемдә... Соңрак мин аның Львов полиграфия институтын тәмамлавын, ире – рәссам-сынчы Георгий Зяблицев белән Казанга кайтуын, биредә яраткан эшен табуын белдем. Ул – пейзаж, натюрморт, портретлар, китап графикасы остасы, искиткеч гравер. Һәм, әлбәттә, Е. С. Тейс дигән атаклы рәссамнан офорт ысулын үзләштергән сирәк рәссамнарның берсе. Татарстан китап нәшриятында кырык елдан артык эшләү дәверендә дистәләгән балалар китабын бизәгән, шуңа күрә аның күп эшләре әдәби юнәлеш алу да гаҗәп түгел. Иҗатында Пушкин, Цветаева, Дурова һәм, әлбәттә, Тукай – иң түрдә! Тукай дөньясы аны тәмам сихерли! «Тукай-Кырлай» офорт циклы, шагыйрьнең төрледән-төрле портретлары, әсәрләренә багышланган күпсанлы иллюстрацияләр... «Тукай. Шәкерт белән очрашу» композициясендә шагыйрь образы яраткан Казаныбыз күренешләре белән тыгыз үрелеп бара. Ә менә «Тукай. Уйлану» портретында – шагыйрь уйга чумган яшь егет сурәтендә. Аның романтик кичерешләре динамик штрихларда бик төгәл чагыла. «Шагыйрьнең балачагы» литографиясендә исә эчкерсез уйчан малай халык әкиятләре дөньясында. «Авыру Тукай» композициясе шагыйрьнең соңгы көннәрен, аны югалту хәсрәтен соры-караңгы төсләр гаммасында тагын да көчәйтә. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» дигән күләмле офорттагы катлаулы композицияне күргәч, ихтыярсыз көлеп җибәрәсең. Төрле төсләр белән чуарланган шәрык келәмен хәтерләтә ул: поэма геройлары нинди генә кыяфәткә кермәгән!..


Ирина Колмогорцева картиналарындагы әкияти Казан мине тәмам сихерли: урамнары, җыйнак ишегаллары, борынгы шәһәргә бизәк булып калыккан заманча яңа йортлар, чал Кремль, тылсымлы замокларны хәтерләтүче Кекин йорты, Сынлы сәнгать музее, зәңгәр Әҗем мәчете... Бөтенесе таныш, әмма мин аларны яңача ачам. Динамика, ирекле штрихлар, ракурстан оста файдалану, төсләр, кұр, ничек үзгәртә икән һәммәсен! Кремль янында апрельнең алсу сыек томаны аша яфракка бөреләнгән тупыллар, октябрь паркларындагы алтын төсләр дуены, җәйге җылы төн зәңгәрлеге... Идел буендагы бакчасында үзе үстергән алмалар, күз явын алырдай чәчәкләр – аларын да рәссам пумаласы иркәләп узган... Рәссамга рәхмәтләр укып, рәхәт бер халәттә картиналарны кабат күздән кичерәм. Сокланам. Тиздән 85 яшьлек юбилеен каршыларга әзерләнүче зур талант Ирина Колмогорцева һаман тынгысыз иҗатта!

Суфия ХӘМИТОВА











ИРИНА КОЛМОГОРЦЕВА




2015 ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Исегезгә төшерәбез: хәзер «Сөембикә» журналының электрон версиясенә дә язылырга мөмкин. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен «Сөембикә»гә язылу өчен бердәнбер мөмкинлек бу! Россиянең ерак регионнарында һәм БДБ илләрендә яшәүче укучыларыбызга журналны PDF-форматта алдыру арзангарак төшәчәк, чөнки моңа почта чыгымнары өстәлмәгән.

- Электрон версиягә язылганда, почта бүлегенә барып, чиратлар тору мәшәкате дә читләп үтә: үзегезгә кайчан җайлы, шул вакытта интернет-сайтка керәсез, банк картасы яки «электрон акча» белән тиешле сумманы күчерәсез. Компьютерның нибары берничә төймәсенә генә басасың! Һәм яңа саннар укучыга күпкә тизрәк барып җитә – чөнки язылучының компьютерына алар, урау юллар үтмичә, журналның басма варианты типографиядән чыгып өлгергәнче үк килеп ирешә.
Чит төбәкләрдә яшәүче укучылар өчен монысы бигрәк тә мөһим булыр.

- Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала. Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтындагы «Язылу» бүлегендә күрергә мөмкин.

- Сайтыбызда журналның басма вариантына да язылып була.
Бергә булыйк!



16+